PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№11 (299) – НОЯБРЬ 2016

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Җирле булмаган бренд

Җукәтау: читтәрәк калган тарих

Милли тойгы, яки Үз юлыбыз

ЕВГЕНИЯ ЛОЗА:

— МИН ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ ҺӘМ ТЫНЫЧЛЫК ЯКЛЫ!

4 612750 670011

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Троицкая
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская
Линар Закиров
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская,
bond@tatmedia.com
Авторлар: Гөлүсә Закирова, Алинә Идрисова,
Катерина Котова, Наил Нәбиуллин,
Айсылу Хаҗиева, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Әхмәрова
Тышлыкта – Евгения Лоза, кино һәм театр актрисасы.
Александр Эшкинин фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**:

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-2950

Басарга кул куелды: 18.11.2016

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Юлия Фәсәхова, тел. (843) 222-06-05

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ӨЧ ҮЛЧӘНЕШТӘ

Әйе, бүген гаджетыбызның бер төймәсенә басып кына да теләсә нинди мәгълүмат, фото, видеоны табарга мөмкин, ләкин беркем дә аның дөреслегенә гарантия бирә алмый. Менә шуннан шикләнүләр, борчылулар, кыскасы – авырулар башлана да.

Шул ук вакытта бүген кулыгызга кергән «Татарстан» журналы, моннан ун, егерме ел элек булган кебек үк, тормыштан тәм табып яшәү, уйланырга мәҗбүр итү һәм аудиториягә карата ихтирамлы мөнәсәбәт шикелле, безгә, «Татарстан»га гына хас ракурс аша эксклюзив, тикшерелгән материаллар тәкъдим итә. Өстәвенә, без янәшәбездә генә яшәгән кешеләр турында язабыз – кул сузарга гына кирәк, һәм менә – алар синең янында. Тормышыбызда булган вакыйгаларны яктыртабыз – борылып карыйсы гына бар – алар күзгә күренеп тора. «Татарстанныкын ал» дип язылган кибет киштәләре яныннан узып без йөрибез ләбаса. Әйе, йөрибез. Ләкин сатып алабызмы-юкмы? Бүгенге санбыз әлеге сораудан башлана. Өйгә кайтып керүгә, телевизорны кушып җибәрәбез һәм, шартлау-атышлар яңгыраган чираттагы бер сериалны күреп, ял итәсе урынга, хәвефләнәбез. Безнең матур киноларыбыз кайда соң дип, тагын бер мәртәбә аптырашта калабыз. Ә журналыбыз, барысы да әйбәт булачак, дип, мәхәббәт һәм тагын шундый мәңгелек темалар турындагы Татарстан киносын карар өчен кинотеатрларга халык агылган көннәр җитәчәк, дип раслый. Әлбәттә, карагач, канәгать калачагыбызны беркем дә гарантияләми, әмма алар өчен аксакаллар киңәше бар – күтәренке кәеф белән саулык-сәламәтлектә ничек озын гомер кичерергә. Коррупция белән көрәшүчеләр өчен дә үрнәк бар – күренекле драматургыбыз Мирхәйдәр Фәйзинең урамда тапкан акчасын милиция хезмәткәре белән бүлешмичә, хокук органнарына илтеп бирүе турындагы язманы укыгыз. Ә бит драматургның театрдан гонорарын ала алмыйча, бик ярлы яшәгән чоры була бу. Милләттәшебез өчен горурлык хисләре кичерерлек! Гонорар темасы күңелне кытыклап җибәрсә дә, журналыбыз, тутырма кебек бик тәмле татар ризыгын тәкъдим итеп, безне башка дулкынга көйли. Ә инде тамагы тук, көндәлек ыгы-зыгыдан бераз арынып торган кеше, һичшиксез, мәңгелек темаларга уйлана башлый: без кем, тамырларыбыз кайдан? Үз-үзенә шундый сораулар биреп, укучы янәдән активлаша, энергиясе уяна һәм ул, журналга үрелеп, бөек, ләкин оялырлык дәрәҗәдә онытылып барган татар шәһәре Җүкәтау, аның тарихындагы данлы да, урта гасыр сугышлары аркасында күп хәсрәтләр кичергән авыр да көннәре турында укый ала.

Үткәнебез, бүгенгебез, киләчәгебез – укучыларына матур уйлар гына уйларга, тормыш тәмен тоеп яшәргә, бирелеп укырга тәкъдим итеп, журнал үзенә әнә шул өч үлчәнеш аша җәлеп итә.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
864 сум 24 тиен

КАЗАН. ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ КӨНЕ

ТАТАРСТАН. НОЯБРЬ.

Ната Смирнова фотосы

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Стратегик әһәмияттәге объектлар.
Авылда кышка әзерлек ничек бара

8. Сабак алу.
Авыл җирлеге башлыкларын нәрсәгә өйрәтәләр

10. Сыйфат билгесен эзләү.
«Милли сәүдә маркасы» үсешен нәрсә тоткарлый

18. Татарстанча Голливуд.
Кинематографистларыбызның күптәнге хыялы кайчан тормышка ашар

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

24. «Галиябану» ничек туган.
Мирхәйдәр Фәйзи легендар пьесасын язар өчен илһамны каян алган

28. Озак яшәүнең сере нидә?
Аксакаллар киңәше

30. Ирек биргән яшь.
«Картлар гаскәре башкомандующие» белән әңгәмә

32. Дөньяда иң матур җир.
Париж белән Мамадыш арасы ничә чакрым

38. Татар аш-сулары.
Тутырма тутыруның борынгы рецепты

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

44. Татар авыллары.
Кызылкүлдә балык ни өчен беткән

46. Татар авыллары.
Карганың каргалары кая киткән

50. Тарих сәхифәләре.
Җукәтау нинди серләр саклый

54. Балалар, яшәгез!
Хоспистан репортаж

60. Казан ир-атлары төрекләрдән нигә яхшырак.
«Восток-Запад» сериалы йолдызы фикере

62. Ерактагы кардәшләребез.
Үзбәкстан татарлары ничек яши

66. Тормыш линиясе.
Резидә Галимова ник Мәскәүдә калмаган

70. Китап киштәсе.
Ни өчен без төньякка юл тоттык

74. Бөек Болгар күләгәсендә.
Татарстанның Спас районы турында

96. Татарстан риваятьләре.
Сертотмас хатын кайда яшәгән

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:

www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

29.10

Владимир Королев, Россия Хәрби-диңгез флоты башкомандующие, – Санкт-Петербургта Татарстан делегациясе белән очрашу вакытында:

– Хәрби корабльләр төзү тармагы буенча без тыгыз хезмәттәшлек итәбез. Татарстанда төзелә торган хәрби корабльләр Хәрби-диңгез флоты составына тиешле вакытында, ышанычлы һәм нәтиҗәле рәвештә тапшырыла. Алга таба да Хәрби-диңгез флотын яңартуда бергәләп эшләячәкбез.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18.10

Александр Лукашенко, Белоруссия Республикасы Президенты, – Минскида Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашу вакытында:

– Без Татарстанның икътисад, сәнәгать, инвестицияләргә тарту өлкәсендә ирешкән уңышларына сөенәбез. Бүген сезнең тәбәк – күпләр өчен үрнәк.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

24.10

Чулпан Хамматова, актриса, – «Бизнес-онлайн»га биргән интервьюсында:

– Әйе, һичсүзсез, миндә туган ил тойгысы һәрвакыт бар. Иделгә җиткәндә бөтенләй тынсыз калам. Әле менә бу юлы да Казанга кичке рейс белән очтым. Самолет ничектер шулай борылды: еракта Идел күренде. Елап җибәрдем – ни өчен икәнен үзем дә белмим. Елганың иллюминатордан күренгән бер кисәге генә бит инде, югыйсә. Поездда кайтканда, Яшел Үзәнне узганнан соң, Идел аша салынган күпердән чыкканда да елыйм. Мөгаен, балачагым үткән туган илем булгангадыр, мөгаен, мин ул – мин булгангадыр. Казан – исеме дә ничек матур яңгырый бит...

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Районнарда кышка әзерлек **НИЧЕК** бара

«Милли сәүдә маркасы» үсешен **НӘРСӘ** тоткарлый

Милли кинематограф үсешенә Татарстан киносы **НИНДИ** йогынты ясый

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Сыер абзарларын капиталь төзекләндерү Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау Спорт мәйданчыклары төзү «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү **Машина-трактор паркларын һәм яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзекләндерү** Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ.
НӘТИҖӘЛӘР

«ТИМЕР АТ»НЫ КЫШЫН ӘЗЕРЛӘ

Машина-трактор паркларын һәм яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзекләндерү программасы импортны алыштыру хәрәкәтен көчәйтеп җибәрергә ярдәм итә. Әйтик, дистәләгән мең тонна бәрәңгене эре сәүдә челтәрләренә бер көндә генә таратып чыгып булмый. Шуңа да, бозылмасын өчен, аны тиешле шартларда сакларга кирәк. Машина-тракторларны да никадәр тиз ремонтласаң, эшең шулкадәр тизрәк башкарылачак.

БӘРӘҢГЕГӘ ТАЛӘП – ЮГАРЫ

Тәтештә эреле-ваклы иллеләп фермер хуҗалыгының берсендә – «Нур» агрофирмасында гына яшелчә белән бәрәңге саклагыч бар. Калган эшкуарлар чөгендер һәм бөртекле культураларга өстенлек бирә.

Радик Нургалиев Тәтештәге «Нур» агрофирмасын 12 ел җитәкли. Анда йөзгә якын кеше эшли. Биш мең гектардан артык мәйданда ни генә үсми: бөртекле, кузаклы культуралар, көнбагыш, кукуруз, рапс, кәбестә, бәрәңге һ.б.

– Соңгы еллардагы корылык аркасында, сөрүлек җирләрендә яшелчә үстереп карарга булдык. Эшчеләргә хезмәт хакын вакытында түләргә кирәк, салымнар исә тагын да хәтәррәк. Чыгымнар кимеми, шуңа да табышны арттырырга кирәк. 2012 елда мелиорация программасына кереп, су сиптерү җиһазлары сатып алдык. Акча

Фото: Александр Эшкинин

Автор:
Линар Закиров

Бәрәңге белән кәбестәне озаграк саклап, ел дәвамында сату өчен, махсус бина кирәк. «Нур»да элеккеге машина-трактор паркы бинасын, төзекләндереп, яшелчә саклагычка әйләндергәннәр. Бу эш 6,5 миллион сумга төшкән, шуның 1,1 миллион сумын дәүләт каплаган. Бинаның түбәсе алыштырылган, диварлары җылытылган, тәрәзәләр куелган, идән бетонланган.

– Бәрәңге кышын 2 градус җылыда саклана, моның өчен вентиляция системасы кирәк. Быел көз яңгырлы булды, бәрәңге җирдән юеш чыкты, аны вентиляциядән башка гына киптереп булмый. Март-май айларында суыткычның кирәге чыга. Вентиляция белән суыткычны икесен бергә хуҗалыгыбызга урнаштыру 25 миллион сумга төшә. Безнең эш домино принцибына нигезләнгән, беренче адым ясагач, калган 100 адымны ясамый хәлең юк, – дип аңлатты «Нур»лы җитәкче.

Тәтеш район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ринат Хәкимов әйтүенчә, үсемлекчелектә нәтиҗә тиз күренә, ә терлекчелектә күп көч куярга кирәк. Сөтчелеккә дә игътибарны арттырырга кирәк, ди ул үзләре турында.

– Район авыл хуҗалыгы тармагында бер меңгә якын кеше хезмәт куя, уртача хезмәт хакы – 17 мең сум. Кайбер хуҗалыклар үз эшчеләренә 25–30ар мең дә түли. Президент программалары гамәлгә ашырыла башлагач, кешеләрнең эш шартлары яхшырды, – дип бәя бирде идарә башлыгы.

тотмый гына нәтиҗәгә ирешеп булмый. Быел «Нур»да 400 тонна кәбестә белән ике мең тонна бәрәңге алдык. Аларны ярминкә-базарларда сату үтемле түгел. Эре сәүдә челтәрләре белән хезмәттәшлек итә башладык, – дип аңлатты Радик Нургалиев.

Аның әйтүенчә, кибет киштәләренә чыгарыласы продукциягә югары таләпләр куела. Бәрәңгене сортларга аеру һәм капчыкларга тутыру өчен аерым складлар булдырырга кирәк. Җитмәсә, продукцияне кибетләргә илтәсе дә бар. Чөнки сәүдә челтәрләренең иномарка фуралары «Нур»ның яшелчә саклагычына килеп туктый алмый, моның өчен керү юлларына бетон түшәргә кирәк.

Зурлыгы ягыннан бәрәңге 70–120 миллиметр калибрына туры килергә тиеш. 70тән кечерәк яки 120дән зуррак булганы инде кабул ителми.

– Быелгы ашлыкны элеватор белән хуҗалыкта саклап, сатмыйча торабыз. Базар бәясе безне әлегә канәгатьләндерми. Кәбестә белән чөгендерне яхшы алалар. Былтыр бәрәңгене нибары биш сумнан сатарга мәҗбүр булдык, хәтта үзкыйммәтеннән дә кимрәк булды, – диде әңгәмәдәшебез.

PRESSA.RU

Машина-трактор паркларын капиталь төзекләндерү программасы

2016 елда башланды

Корылмалар саны:	**112**
Акча лимиты:	**270,7 млн сум**
Республика бюджетыннан:	**81,2 млн сум**
Хуҗалыкларның үз акчалары:	**189,5 млн сум**

ЧЫЛБЫРЛЫСЫ КИТӘ, ТӘГӘРМӘЧЛЕСЕ КИЛӘ

Республикада иң алдынгы хуҗалыкларның берсе – Чүпрәле районындагы «Цильна» хуҗалыгында 140лап кеше хезмәт куя. Тәтештәге ниятне монда инде тормышка да ашыра башлаганнар: соңгы өч елда сыерларның баш саны 500дән 750кә кадәр арттырылган. Быел сөтне дә былтыргыга караганда ун процентка күбрәк җитештерергә хыялланалар.

Шунысы гаҗәп: 2015 елда кредит алмый гына эшләгәннәр биредә. Юкса, быел гына да «Цильна»да яңа техника алуга 12 миллион сум тотылган, булганын төзекләндерүгә – 10 миллион.

Хуҗалыкның баш икътисадчысы Тәлгать Бохаров әйтүенчә, банклар кредитны югары процент ставкасы белән бирә (20–22% чамасы). Алар хуҗалыкларны батыра гына, дигән фикерен җиткерде ул.

Хуҗалыкның нәтиҗәлелеген арттыру өчен, «Цильна»да машина-трактор паркларын төзекләндерү программасыннан файдаланганнар. Бу эш 2 миллион 100 мең сумга төшкән, шуның 950 меңен Хөкүмәт үз өстенә алган. Силос-сенаж базын да 1 миллион 50 мең сумга ремонтлап, дәүләттән 450 мең сум кире кайткан. Республика программасы ярдәмендә сыер абзарлары да яңартылган.

– Республикадагы машина-трактор паркларының күбесе һаман да «буржуйка»лар белән җылытыла, ә безнекенә газ кертелде. Ел әйләнәсе эшләү өчен шартлар тудырылды. Паркта ремонтны чылбырлы тракторлардан башлыйлар. Алар, музей экспонаты буларак, бик аз калды инде. Хәзер тәгәрмәчле тракторларга күчеп барабыз. Чөгендер җыю өчен генә транспортны читтән яллыйбыз, калган эшне үзебезнең техника белән башкарабыз. Берничә ел элек 16 миллион сумга чөгендер комбайны сатып алдык. Ул 20 төрле техниканы алыштыра, – дип, заманча техниканың куәте турында сөйләде Тәлгать Бохаров.

ҮЗЕ ЙӨРИ, ҮЗЕ РӘТЛИ

Ремонтка башта тракторлар, аннары чәчкечләр, культиваторлар кебек агрегатлар кертелә. Соңгыларын махсус эшчеләрдән төзелгән бригадалар караса, механизатор үз техникасын үзе рәтли, андый вакытта техникага караш та бүтән төрле, ремонт та сыйфатлырак башкарыла, дип аңлатты «Цильна» белгечләре. Механизаторга моның өчен тариф буенча өстәмә акча түләнә. Катлаулы тракторны ремонтлауга ике атна чамасы китә, гадиләрен «тәртәгә кертергә» бер атна да җитә. Яңа елга кадәр тракторларга игътибар бирәләр, ә аннары комбайннарны рәтлиләр.

Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь төзекләндерү программасы

	2015 елда башланды	2016 елда планлаштырылган
Корылмалары саны:	36	29
Акча лимиты:	166,7 млн сум	166,7 млн сум
Республика бюджетыннан:	50,0 млн сум	50,0 млн сум
Хуҗалыкларның үз акчалары:	116,7 млн сум	116,7 млн сум

– Кыр эшләре вакытында берәр җайланма сафтан чыкса, эретеп ябыштыру агрегаты урнаштырылган трактор җибәрелә. Бер төн эчендә двигательләрне дә ясаган чаклар булды. Запчастьләр белән ягулык-майлау материаллары бик кыйммәт хәзер. Двигатель сафтан чыкса, аның күп өлешен алыштырырга туры килә, – дип аңлатты әңгәмәдәшебез.

«Цильна»да 42 трактор бар. Паркның буш торганы юк. Яздан – җәйгә, көздән кышка күчкәндә техниканы тулысынча карап чыгалар. Хәзер республика хуҗалыкларында «тимер ат»ларны кышка саклануга куялар. Һәр районга Казаннан комиссия килеп, техниканың торышына бәя бирә. 1 һәм 2 урынны алган хуҗалыкларны республиканың Авыл хуҗалыгы министрлыгы акчалата бүләкли.

ТУЗГАН ТЕХНИКА

Сүз дә юк, «Цильна» аягында нык басып тора, ә менә район авыл хуҗалыгы өлкәсенең хәле шәптән түгел. Чүпрәледәге техниканың 68 проценты тузган. Республикада бер чәчүлек гектарына 153 ат көче туры килсә, районда бу күрсәткеч – 149. Шуңа да район җитәкчелегенә һәм хуҗалыкларына машина-трактор паркларын төзекләндерү программасына теше-тырнаклары белән ябышырга кирәктер.

Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары Җәмил Шәрипов сөйләвенчә, быел машина-трактор паркын төзекләндерүгә районда алты хуҗалык дәгъва кылган. Лимит чикле булганга, матди хәлләренә карап, дүртесен сайлап алганнар. Төшеп калган ике крестьян-фермерлык хуҗалыклары бәхетләрен киләсе елда сынап карый ала.

ШИКӘР ЗАВОДЫНДА ЧИРАТ

Тәтеш белән Чүпрәле якларына барып, чөгендернең бик тә табышлы яшелчә икәнлегенә төшенеп кайттык. Тәтешнең авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ринат Хәкимов әйтүенчә, районда сәнәгать предприятиеләре юк, бөтен өмет – терлекчелек белән үсемлекчелектә. Быел 457 мең центнер шикәр чөгендере алып, якындагы Буа заводына тапшырып баралар. Яңа елга чаклы эшне төгәлләргә ниятлиләр.

Былтыр Тәтештә чөгендерне 3600 гектар мәйданда чәчсәләр, быел – 4600 гектарда. Киләсе елда «шикәрле» мәйданны 6000 мең гектарга кадәр киңәйтмәкчеләр.

– Бездә чөгендерне чәчүдән башлап җыюга кадәр технология җайга салынган. 45 миллион сумга чөгендер комбайны сатып алдык. Районда шундый дүрт техника бар, хуҗалыкларга уңышны җыеп алырга бердәнбер инвесторыбыз – «Ак барс» агрофирмасы да алты комбайнын биреп торды, – дип сөйләде Ринат Хәкимов.

Чүпрәле районындагы «Цильна» хуҗалыгында елына 700 гектарда 25 мең тонна чөгендер җитештерелә. Баш икътисадчы Тәлгать Бохаров зарланып та алды: «Буа заводында чират зур, эшкәртергә өлгермиләр. Үз район җитештерүчеләрен чиратсыз кертәләр, ә безнең бер рейсыбызны гына кабул итәләр». Шунлыктан «Цильна» үз продукциясен Ульяновскидагы заводларга илтеп тапшыра.

– Без алар белән 40/60 программасы нигезендә эшлибез: әзер шикәрнең 40 процентын завод үзенә калдыра, 60 процентын безгә бирә. Былтыр чөгендерне 65 миллион сум күләмендә җитештереп, шуның 60 проценты – 46 миллион сумы кайтты. Бер тонна чималдан 80 килограмм шикәр чыга, – дип сөйләде ул.

Кайвакыт «Цильна»да башка төрле дә эшлиләр: заводка, башкарылган хезмәте өчен акча түләп, шикәрне тулы күләмдә үзләренә алып калалар. Ә аннары шуны саталар яки орлыкларга, гербицитларга алмаштыралар.

Былтыр бу хуҗалыкның еллык кереме 260 миллион сумны тәшкил иткән. Исәпләп чыгарсак, шикәр чөгендере хуҗалык бюджетының биштән бер өлешен тәшкил итә. Быел еллык керемнәрен 350 миллион сумга җиткермәкчеләр.

PRESSA.RU

АВЫЛ КРЕАКЛЛАРЫ

– Менә сез: «Асфальт-бетон заводы төзибез», – дисез. Кем төзесен аны сезгә?!

– Дүрт авылга – бер мәктәп! Нинди яшьләр турында сүз булырга мөмкин?

– Газлаштыру программасы үтте, ә сезнең йортларыгызга газ кертелмәгән. Нишләргә җыенасыз?

Кискен сораулар Илдарга явып кына тора. Юк, аны «батырырга» җыенмыйлар. Иске проблемаларның яңа чишелешен табарга булышалардыр, мөгаен. Биредә һәм хәзер иң кызыклы, әһәмиятле вакыйга бара: үз кече ватаннары белән нәтиҗәле идарә итә алырлык шәхесләрнең яңа креатив классы – креакллар туып маташа.

Автор:
Катерина Котова

КЫРДАН – ПАРТА АРТЫНА

Үз ярдәмче хуҗалыгын белән идарә итү җиңелләрдән түгел, ә инде берьюлы берничә авыл белән идарә итү тагын да катлаулырак. Халыкка үзара салым салу, рөхсәт ителмәгән чүплекләр, карьерлар эше, урамнарны яктырту кебек һәм башка мең төрле мәсьәләдән хәбәрдар булу сорала. Бу һәм калган бик күп сорауларга җавап табу өчен, авыл җирлекләре башлыклары Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенә җыелды.

– Безгә укырга килүчеләрнең актуаль сорауларына җавап бирү генә түгел, бәлки тулаем грамоталылыкны күтәрү, идарәче күнекмәләрен булдыру, гомуми проблемаларның хәл ителү юлларын бергәләп эзләү мөһим, – ди КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директорының беренче урынбасары Галина Маштакова. – Безнең программа нәкъ менә шуның өчен төзелде дә. Бу курсның идеясен Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының Территорияләрне үстерү идарәсендә дә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советында да хупладылар.

БАШЛЫК – БАРЫСЫНА ДА БАШ

– Безнең авыл трассадан ике чакрым ераклыкта урнашкан. Әйдәгез, ягулык салу станциясе төзү турында килешик. Шиномонтаж ачарбыз...

– Ә бу нәрсә бирәчәк?

– Эш урыннары һәм җирле бюджетка 4 процент НДФЛ!

Аудиториядә авылны коткару буенча чын «акыл атакасы» бара. Әлегә – уйлап чыгарылган авылны гына. Әмма, аралашуның беренче сәгатьләре үк күрсәткәнчә, башлыкларның авыллары – төрле, ә проблемалар – бөтен җирдә бер үк.

– Дөресен әйтим, без катнашучылар актив булмас һәм аларны үзара аралаштыру кыен булыр, дип курыккан идек, – дип сөйли Галина Маштакова. – Һәм үзебез дә шаккаттык! Алар шунда ук катнашып китте һәм инициатива күрсәтә башлады.

– Галина Юрьевна, авыл җирлекләре башлыклары үз авылларындагы бөтен кешене һәм бөтен нәрсәне белә. Сезнең мәктәптә аларны тагын нәрсәгә өйрәтеп була?

– Авыл җирлеге башлыкларының һәркайсы уникаль тәҗрибәгә ия, һәм без аларга тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгы да булып торабыз, территорияләр белән идарә итү буенча белемнәрен тулыландыру мөмкинлеге дә бирәбез. Моннан тыш, без булган мәгълүматны авыл җирлеге башлыкларына бирелгән вәкаләтләр призмасы аша системага салырга булышабыз. Шунлыктан иң җиңел нәрсәдән – «Россия Федерациясендә җирле идарәне оештыру принциплары турында» дигән законнан башлыйбыз. Алар нәрсә өчен җавап бирә, нәрсә белән идарә итә. Җир, мөлкәт, торакка кагылышлы мәсьәләләрне, авыл хуҗалыгын үстерү проблемаларын тикшерәбез. Коррупциягә каршы эшчәнлек турында сөйләшәбез – бу да бик мөһим. Хуҗалык кенәгәләрен дөрес алып барырга өйрәтәбез, кирәкле нотариаль гамәлләрне практикада күрсәтәбез. Сүз уңаеннан, башлыкларга җирле үзидарә нигезләрен Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсагыйть Закир улы Шакиров үзе өйрәтә.

– Практикага басым ясау – сезнең мәктәпнең визит карточкасы. Җирлек башлыклары өчен программа да бу кагыйдәдән чыгарылма түгелдер?

– Беренче лектордан соң теоретик өлеш тәмамлана да инде – без тренингларга күчәбез. Бу чын «акыл атакасы», аның ярдәмендә тыңлаучылар стандарт булмаган бик күп чишелеш таба. Сүз уңаеннан, әлеге программа өчен практик ситуа-

цияләр уйлап табу безгә дә җиңел булмады. Без бу эшкә җәлеп иткән экспертлар тиз генә бер фикергә килә алмады. Башта тыңлаучыларның бу категориясе өчен бүген аеруча актуаль мәсьәләләрне ачыклау бәхәс уятты, аннары дәресләрдә тикшерергә планлаштырган конкрет мәсьәлә һәм проблемаларны хәл итүдә консенсуска килергә тырыштык. Һәм бу урыннарда карар кабул итүнең никадәр катлаулы булуын безгә тагын бер тапкыр тоярга мөмкинлек бирде – таянырлык кеше юк, ресурслар чикләнгән, закон һәм карарларның күпсанлы төзәтмәләрендә буталырга мөмкин.

ҮЗМЕ, ӘЛЛӘ ЧИТМЕ?

Үзара салым мәсьәләләре хәлне соң чигенә кадәр кискенләштерә. Бөтен башлыкларга да мәгълүм: уртак финанслау программасы буенча җыелган акчаның бер сумына республика дүрт сум акча куша.

– Ә миңа «дачниклар» белән нишләргә? – дип сорый аудиториядән Рәмис һәм шунда ук ачыклык та кертә. – Авылда яшәп, шәһәрдә теркәлгәннәрне әйтүем, ди. Аларның кертемнәре уртак финансланмый.

– Минем карамакта – өч авыл, – дип сөйли Леонид. – Аларның кайсына юл салырга дип, һаман талашабыз...

– Дәүләт хезмәткәрләре өчен программаларның барысына да сез стресска чыдамлылык буенча тренинглар кертәсез. Сезнеңчә, мондый тренинглар авыл башлыкларына кирәкме? – дип үземне борчыган сорауны бирәм Галина Маштаковага.

– Әлбәттә. Аларның эше зур психологик чыгымнар таләп итә. Еш кына кешеләр авыл башлыгының нинди мәсьәләләр өчен җаваплы булуын аңламый. Нәтиҗәдә, аңардан хәленнән килмәгән нәрсәләрне дә таләп итәләр. Шунлыктан без программага халык белән аралашу буенча тренингны керттек, анда низагларны хәл итү һәм стрессны басарга өйрәтү кебек блоклар бар.

ХӨКЕМДАРЛАР КЕМ СОҢ?

– Онытып торыгыз әле шул авыл туризмын! – дип мөрәҗәгать итә башлыкларга бүген эксперт сыйфатында чыгыш ясаучы Югары мәктәп директоры Игорь Привалов. – Үзегезнең муниципаль берәмлекнең керем базасын чынбарлыкка якынрак ысуллар белән арттырырга тәкъдим итәм...

– Игорь Анатольевич күп еллар дәвамында район башлыгы булган кеше, – дип сөйли Галина Маштакова. – Авыл җирлекләре башлыкларын борчыган һәр мәсьәлә аңа таныш, бу аудитория белән уртаклашырлык тәҗрибәсе хәттин ашкан. Шулай булса да, ул программа кысаларында чыгыш ясаучы бердәнбер эксперт түгел. Барлык идея һәм проектлар республика министрлыклары һәм ведомстволарының күпчелеге, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре тарафыннан бәяләнә. Әле башка бер генә программабызның да шулкадәр күп эксперты булганы юк иде. Димәк, курста катнашучыларга үз җирлекләре проблемаларын иң югары классны белгечләр белән тикшерү мөмкинлеге бирелә. Безнең программаның максаты да шунда бит: наданлыкны бетерү генә түгел, бергәләшеп проблемаларны хәл итү юлларын эзләү мәйданчыгына әйләнү. Безнең дәресләрдә катнашучылар инициатива күрсәтә һәм үзләренең практик тәҗрибәсе белән уртаклаша.

– Сезнең барлык программаларыгыз да зур уңыш казана. Моның сыннан нинди кайтаваз көтәсез?

– Былтыр без уңай фикерләр ишеттек инде. Безнең өчен иң яхшы сүз – «Эш өчен файдалы булды», һәм мин быел да безнең тыңлаучыларыбыз өйләренә яңа белем һәм практикада кулланырлык әзер карарлар белән кайтып китәр, дип өметләнәм.

– Татарстанда барлыгы 900дән артык җирлек башлыгы бар. Барысын да укытырга җыенасызмы?

– Быел ун төркем – барлыгы 300 кеше җыябыз. Үткән программада 400 кешене җәлеп иткән идек. Димәк, киләсе елга да җитәрлек эш кала әле. Аннары нәрсәме? Яңа баскыч! «Алга киткәннәр» өчен аеруча катлаулы курс. Тыңлаучыларның бүгенге активлыгы ихтыяҗ һәм уку теләге булуны күрсәтә. Җирлек башлыклары киләсе елга да яңа сораулары һәм тәкъдимнәре белән килсен өчен, безгә бу кызыксынуны саклау мөһим. Ахыр чиктә, бу әкренләп башта безнең авылларда, аннары инде бөтен республикада тормыш шартларының яхшыруына китерәчәк бит.

Реклама

PRESSA.RU

ҖИРЛЕ БУЛМАГАН **БРЕНД**

Безнең редакция, экспертлар белән берлектә, «Милли сәүдә маркасы» Татарстан проекты үсешен тоткарлаучы проблемаларны ачыклады.

Автор:
Алинә Идрисова

Редакция бимеремнә кадәр мәкаләнең авторы «Милли сәүдә маркасы» бренды турында белгәнме соң? Әйе, әлбәттә! Эшчәнлеге буенча туры килгәнгә. Әмма гаилә әгъзаларын һәм якын-тирәдәгеләрдән сораштыру капма-каршы нәтиҗәгә китерде – бренд турында беркемнең дә ишеткәне юк диярлек. Шуңа күрә иң башыннан башлыйк…

НӘРСӘ СОҢ УЛ?

2014 елда ТР Президенты күрсәтмәсе буенча, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән бергә, «ТР Милли сәүдә маркасы» ТР ДУП төзелә. Ул, сатып алучы «Милли сәүдә маркасы» билгесе астында сатыла торган товарның сыйфатында шикләнмәсен

Фото: Александр Эшкинин

Татарстан җирле товар җитештерүчеләр продукциясен алга этәрү ягыннан караганда уникаль түгел: Россия субъектларының 70%тан артыгы моңа охшаш проектларны тормышка ашыра. Ә кайбер төбәкләр, үз бренд-программаларын алга этәрүдә стандарт булмаган ысуллар кулланып, әлеге юнәлештә күршеләреннән уздырып та җибәргән.

өчен, лаборатория анализларын, органолептик күрсәткечләрне тикшерү, белгечләр экспертизасын үз эченә алган продукциягә бәя бирү системасын булдыра. Шуны билгеләп үтик: мондый продукциягә куелган таләпләр дәүләт стандартларында билгеләнгәннәреннән күпкә катгыйрак.

Шәп фикерме? Һичшиксез! Тик менә әлеге таләпләргә җавап бирә алырлык продуктларның саны күп түгел икән шул. Һәрхәлдә, кибетләрдә һәм супермаркетларда без көткән билге төшерелгән продуктлар юк диярлек. Сәбәбе нидә? «Милли сәүдә маркасы» ТР ДУП генераль директоры Илсур Сафиуллин үз вакытында билгеләп үткәнчә, сәбәпләрнең берсе – җирле товарлар сыйфатының кабул ителгән бренд дәрәҗәсенә туры килмәвендә. Янәсе, шуның аркасында проект планлаштырылган үсешкә ирешмәгән дә.

Критерийларны йомшартыргамы? Әмма планканы төшерү, асылда, идеядән баш тарту, диген сүз, ә бит баштан ук бик югары сыйфатлы продукцияне генә маркировкаларга диген фикер аермачык билгеләнгән иде. Җитмәсә, көндәлек сатып алу тәҗрибәбез дә шуны исбатлый: үз юнәлешләрендә, ким дигәндә, башкалардан калышмаучы, еш кына әле көндәшләреннән өстен чыгучы Татарстан товарлары «сыйфат билгесе» төшерелгәннәреннән күбрәк. Димәк, проектны башка сәбәпләр дә тоткарлый булып чыга?

Дәүләт унитар предприятиесендә дә моны аңлыйлар, дип уйлыйм. Юкса «Милли сәүдә маркасы» бәйгесен уйлап табу нигә кирәк иде? Сүз уңаеннан, катнашучылар өчен җитди преференцияләр каралган. Киләчәктә аларның продукцияләре эчке һәм тышкы сәүдә базарына кертеләчәк, ташламалы шартларда сертификацияләнәчәк, ә җиңүчеләр товарларын «МСМ» бренды астында сатарга хокуклы булачак.

ФЕРМЕРЛАР СӘҮДӘ ЧЕЛТӘРЕНӘ КЕРЕРГӘ ТЕЛИ

«МСМ»ның төп максаты – Татарстан җитештерүчеләренә сәүдә челтәрләре ритейлерларын үтәргә, сатып алучыларны табу юлын җиңеләйтергә булышу, аларның көндәшлеккә сәләтле продукцияләрен сатуны җайга салу. Кечкенә фермер хуҗалыкларына зур сәүдә базарына чыгу аеруча авыр. Аларга азык-төлек ритейлерларының югары таләпләренә җавап бирү кыен, аерым алганда, товарның күләме һәм тапшырылуы ягыннан. Эшкуарлар өчен югары керү бонуслары, түләү срокларын кичектерү, зур уенчылар гына ия була алган бәя демпингы да каршылык булып тора.

Практикада күренгәнчә, сәүдә челтәрләренә озак сакланучы арзан продуктлар кызыклы. Ритейлерлар өчен федераль контрактлар өстен, ә җирле җитештерүчеләр белән хезмәттәшлек соңгы чиратта гына карала.

Безгә «Милли сәүдә маркасы» ТР ДУПндә сөйләгәннәргә караганда, «МСМ» брендын үстерү өчен, продукцияне эре азык-төлек ритейлерлары кибетләре аша алга этәрү белән беррәттән, якын-тирәдә урнашкан «Үзебезнең продукт» дип аталган кибетләр челтәре дә булдырыла. Алар эшкуарларга башкарма комитет тарафыннан ташламалы шартларда арендага бирелгән муниципаль биналарда ачылачак. Товарларын сәүдә челтәрендә сатарга теләүчеләр өчен сертификация узу мәҗбүри – барлык таләпләргә җавап биргән очракта гына продуктларга «Милли сәүдә маркасы» лейблы төшереләчәк.

Бик әйбәт фикер. Тик «Үзебезнең продукт» кибете Казанда әлегә берәү генә. Ләкин ДУП киләчәктә әлеге челтәрне киңәйтергә ниятли.

БАШКА ТӨБӘКЛӘР ТӘҖРИБӘСЕ

Татарстан җирле продукциясен алга этәрү ягыннан караганда уникаль түгел. Россия субъектларының 70%тан артыгы үз товар җитештерүчеләренең сәүдә-имидж проектларына булышлык күрсәтә.

Күпчелек субъектларда мондый бренд-программаларны үткәрү идеологиясе бездәге кебек үк – төбәк сәүдә челтәрендә продукциянең сыйфаты өчен көрәш. Моннан, кагыйдә буларак, төбәкләргә кагылышлы атамалар да туа: «Ставропольнекен сатып ал», «Пермьнекен сатып ал», «Төмәннекен сатып алабыз!» һ.б. Шулай ук күпчелек программаларга продукцияне бердәм сәүдә билгесе белән маркировкалау да хас. Хәер, кайбер төбәкләр ти-

PRESSA.RU

плаштырылган таныту вакытында үз «фишкаларын» уйлап табып, үзенчәлекле ысул белән үз брендларын алга этәрүгә ярдәм итә.

Түбән Новгород өлкәсендә максатчан программаларны тормышка ашырганда, башка нәрсәләр белән бергә, реклама һәм маркетинг өлкәсендәге грамоталыкны үстерүгә игътибар бирелгән: эшкуарлар өчен сәүдә маркаларын булдыру, төрү материалларының дизайнын ясау, реклама акцияләрен үткәрү буенча белем бирү семинарлары һәм конференцияләре үткәрелгән. Параллель рәвештә урыннарда җитештерелгән азык-төлекне күмәртәләп сата торган компанияләрнең санын үстерү буенча эш алып барылган, логистика инфраструктурасы төзелгән. Өлкә тәҗрибәсен уңышлы дип санарга була: программаны өч ел дәвамында тормышка ашыру вакытында ваклап сатудагы товар әйләнешенең гомуми күләмендә Түбән Новгород товарлары өлеше 15% тан 60%ка кадәр артты.

Капма-каршы тәҗрибә дә булды: Краснодар крае, сәүдә челтәрләрендә җирле товарларны танытырга омтылып, «Енисей-продукт» дип аталган билге астында сату өчен, 500ләп махсус сәүдә ноктасы булдыра. Күпмедер вакытка край продукциясенең сатылуы артуын-арта, ләкин җирле тәэминатчыларның күпчелеге товарның күләме һәм товар китерү ешлыгы ягыннан челтәрнең шартларын үти алмый.

Пермь крае белгечләре үзенчәлекле, яңача эшләгән. Монда, мәсәлән, «Сәламәт туклану мәктәбе» проекты гамәлгә ашырыла, проект укучыларга төбәктә үстерелүче һәм җитештерелүче продуктлар турында сөйли. Ә җирле телевидениедә «Без нәрсә ашыйбыз?» дип аталган атналык телевизион программа күрсәтелә. Хәер, акция көтелгән нәтиҗәләр бирми: крайда җитештерелгән ашамлыкларның сатылу күләме көтелгән кадәргә артмый. Шуңа күрә, программаны үзгәртергә, кече товар җитештерүчеләргә ярдәм итүнең яңа ысулларын табарга карар кылына.

АГРОФРАНШИЗА ҺӘМ САТЫЛУ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Шундый яңа ысуллар арасында: бердәм интернет-кибет оештыру, субсидияләр бирү, агрофраншизалар булдыру кебек тәкъдимнәр яңгырый. Соңгысы – иң кызыгы, аның турында җентекләбрәк сөйләп үтик.

Агрофранчайзинг Россия территориясенең ике субъектында гына актив үсеш алган: Пермь краенда һәм Төмән өлкәсендә. Асылда, бу әзер бизнесны сатып алу дигән сүз. Хуҗалыкка җиһаз һәм инвентарьлар, яшь терлек яисә яңа үсентеләр бирелә, җитештерү технологиясенә дә өйрәтәләр.

Әлеге технологияне үзләрендә кулланып эшләгән эшкуарлар әзер продуктны база хуҗалыгына кайтара ала. Бу, үз чиратында, иң зур проблема – сатуны дөрес итеп оештыруны хәл итә, чөнки барлык мәшәкатьләрне үз өстенә агрофранчайзер ала.

Франшиза алганда, Пермь краенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы эшкуарның технологиягә тоткан чыгымнарының 50%ка кадәрен край бюджеты хисабына субсидияли. Крайның Авыл хуҗалыгы министрлыгында белдерелгәнчә, әлеге программа буенча эшли башлаган барлык кече хуҗалыклар да табыш ала.

КАБИНЕТ ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ МЕДИАПЛАНЛАШТЫРУ

Төбәк сыйфат билгеләрен таныту буенча реклама кампанияләрен үткәрү тәҗрибәсе шуны күрсәтә: барлык компанияләр, реклама йо-

гынтысының традицион методлары аша сатып алучыларда лояльлек формалаштырырга тырышып, тегеяки бу дәрәҗәдә танытуның берничә моделенә тартыла.

Волгоград бизнес институты хезмәткәрләре төбәк сыйфат билгеләрен таныту буенча оештырылган реклама кампанияләрен, реклама тарату өчен сайланган каналларның, ысулларның файда китерү дәрәҗәләрен анализлаган һәм күпчелек төбәк программаларына хас йомшак якларны ачыклаган.

Шулар арасында, мәсәлән, «иҗади» реклама идеяләре һәм стратегияләренең бер типта булуы. «Билгенең» визуаль кабул итү өчен җаваплы адекват, оригиналь һәм нәтиҗәле сәнгати формасы юк.

Аудиториягә тәэсир итү ысулларының да чикле булуы ачыкланган: еш кына бу, «Үзебезнекен ал!» кебек бер типтагы лозунгларны кабатлап, товарны көчләп сатуга омтылуга кайтып кала.

Төбәк сыйфат билгесе еш кына киңәйтелгән бренд буларак кузалланыла, чөнки ул азык-төлек сәнәгате продукциясенә генә түгел, башка төр җитештерү продуктларына да бирелә. Бу күпчелек очракта билгенең беренчел мәгънәсен үзгәртә, концептуаль рәвештә эшләнеп бетерелмәгәнлеге һәм мондый форматта танылу өчен аңлаешлы объект сыйфатында тәкъдим итеп булмаячагы хакында сөйләргә урын калдыра.

Моннан тыш, берән-сәрән үткәрелгән һәм вакыт ягыннан бер-берсеннән ерак булган реклама акцияләре уртак максат, идея, эшләнеш ягыннан бәйләнешсез булып чыга. Авторлар фикеренчә, нәтиҗәләрнең начар булуы мондый реклама кампанияләрен медиапланлаштыруның, нигездә, җирле чиновниклар тарафыннан үткәрелүенә бәйле: брендинг буенча квалификацияле белгечләрне җәлеп итмичә, үз көчләренә таянып кына.

Волгоград белгечләре фикеренчә, җирле товарларны максималь рәвештә алга этәрү өчен, төбәк брендларын рекламалау буенча алып барыла торган кампанияләргә яңа реклама алымнары рәвешендә төзәтмәләр кертергә генә түгел, бәлки кайбер очракларда аларны үткәрүне яңадан үзгәртеп корырга кирәк.

Илсур Сафиуллин,
«Милли сәүдә маркасы» ТР ДУП генераль директоры:

– Безнең бурыч – үзебездә җитештерелгән сыйфатлы продукцияне сайлап алу гына түгел, аны төрле сату челтәрләрендә «озата бару» да. Ягъни һәр юнәлешне үстерү, сатып алучыларның теләкләрен күзәтеп тору, продуктны көндәшлеккә сәләтле итү белән беррәттән, бөтен кеше ала алырлык итеп җитештерү дә. Социаль программалар булдыру да планлаштырыла.

Миллион кешелек шәһәрләрдә, ярминкәләр уздырудан кала, без башка юнәлешләрдә дә эшчәнлек алып барабыз. Кооператив хәрәкәтен үстерәбез: «Милли сәүдә маркасы» ТР ДУП химаясе астында «Үсенте» кооперативы оештырылды. Аның төп максаты – сыйфатлы продукция җитештерүчеләрне берләштерү. Кооператив партнерларына сәүдә челтәрләре белән килешүләр төзүдә ярдәм күрсәтелә, ритейлерлар белән очрашулар, киңәшмәләр оештырыла.

Касса аермасын каплау фондын булдыру да планлаштырыла. Эш шунда ки, сәүдә челтәрләре белән килешүләр төзегән вакытта продукция белән тәэмин итүне түләүдә 40 көнгә кадәр аерма барлыкка килә. Тәэминатчылар һәм җитештерүчеләрнең әйләнештәге акчаларындагы җитешсезлекләрне касса аермасын каплау фонды юк итәргә тиеш.

Сәүдә челтәрләре белән килешүләр төзү өчен товарларның зур өлешен складларда саклау кирәк. Шул сәбәпле, кече һәм урта производстволар өчен бүленеш үзәге төзергә кирәк. Хәзерге вакытта без моны эшлибез дә.

Василий Юзенчук,
«Райзмейкер» ҖҮА идарәче партнеры, «Брейнстор» креатив агентлыгы директоры:

– «Милли сәүдә маркасы» проекты идеясе, минемчә, дөрес. Әлеге бренд Татарстан фермерлары өчен сату базарын киңәйтүгә һәм Татарстан продукциясен, ким дигәндә, Россия базарында уңышлы танытуга шәп мөмкинлек булып тора.

Төп проблема – стратегия: нәрсәгә омтылабыз, нәрсәгә ирешергә телибез, нинди ресурслар бар һәм ниндиләре кирәк? Әлеге базар сегменты клиентларыннан мондый сорауларны еш ишетәм мин. Әлегә бу барлык проблемалары белән глобаль стартапка охшый: продуктны базарга урнаштыруда интуитив юл, төп ресурсларның булмавы, тупас итеп әйткәндә, траншеяны кашык белән казырга тырышу.

Иң кызыгы, Татарстаныбызда, проектта катнашып, аны лаеклы югарылыкта башкарып чыга алырдай әйбәт белгечләр күп: стратеглар, дизайнерлар, веб-уйлап табучылар – барысы да бар. Профессиональ җәмәгатьчелеккә турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә генә кирәк. «МСМ» үстерү белән шөгыльләнүче команданың җитәрлек бюджеты булмаса да, ахыргы чиктә сайтлар ясый, бренд уйлап табып, аларны популярлаштыра белүчеләр белән элемтәгә чыгып, шулардан тәкъдимнәр кабул итәргә була. Бу бит масштаблы мәсьәлә, ярдәм итәргә теләүчеләр барыбер табылачак. Портфолиоларын тулыландырырга ниятләүчеләр, Татарстан абруе белән кызыксынучылар табылачагына шикләнмим.

Бер сүз белән әйткәндә, мондый проектларны максималь ресурслар кулланып ясарга кирәк. Бу зур куәтле старт алырга, ритейлга керү мөмкинчелеге табарга һәм үзебезнең кибет челтәрләрен булдырырга ярдәм итәчәк. Бу локаль стартап түгел, «МСМ» – барлык битараф булмаган Татарстан белгечләрен җәлеп итәргә, катнаштырырга тиешле проект.

PRESSA.RU

ИРТӘГЕГЕ КӨН ПРОЕКТЛАРЫ

Август аенда узган «АКТО-2016» авиакосмик күргәзмәсе «хэдлайнерлары»ның берсе «Казан Гипронииавиапром» АҖ булып чыкты. Быел нигезләнүенә 75 ел тулуны билгеләп үтүче институт күргәзмәдә, башка килешүләрдән тыш, Кытай хөкүмәте каршындагы дәүләт компаниясе белән уртак җитештерү булдыру турында гаять мөһим килешү төзеде.

Синхрон рәвештә, ә кайчагында соңгы сәнәгать трендларыннан алга китеп тә хәрәкәт итәргә институтка традицион мәктәпнең нәкъ шул 75 еллык тәҗрибәсе булыша, ул проектлаштыруга карата өр-яңа, күп очракта – инновацион карашларның базасы булып тора. Бүгенге көндә «Казан Гипронииавиапромы» үз тармагында әйдәп баручы урыннарның берсен били. Шул ук вакытта, ул күптән гадәти проект оешмасы статусын узып китте инде. Үз базасында берничә тикшеренү лабораториясе һәм махсуслаштырылган филиаллар төзеп, институт төрле тармак һәм билгеләнештәге объектлар өчен комплекслы карарлар эшләп чыгарырга сәләтле уникаль предприятиегә әйләнде.

Әйтик, яңа офыкларны үзләштерә барып, 90нчы елларда институт гражданлык төзелеше өлкәсендә берничә проект эшләп чыгарды. Бүген, ике дистә елдан соң, «Казан Гипронииавиапромы» проектлары буенча үзгәртеп корылган яисә төзелгән объектлар арасында – Татарстан кешеләренә генә түгел, республиканың күп кунакларына да билгеле биналар бар. Болар аның «һава капкалары» – «Казан» халыкара аэропортының 1, 1а, 2 терминаллары да, «Иннополис» инновацион иярчен шәһәре дә, мәдәният, мәгариф һәм сәнәгать билгеләнешендәге башка күп кенә объектлар да.

Институт эшенең географиясе үз эченә илнең күптөрле шәһәрләрен сыйдырган. Институт эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып технологик һәм архитектура-төзелеш проектлаштырулары кала, шул исәптән аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм уникаль объектларны, оборона-сәнәгать комплексы, авиация һәм космик инфраструктура, машина төзү, приборлар төзү, энергетика сәнәгате объектларын һәм башкаларны проектлаштыру.

2011 елда институт сынау стендларын проектлаштыруга заказлар үти башлады. Озакламый мондый эш өчен технологик системаларның стандарт булмаган җиһазларын эшкәртү номенклатурасын киңәйтү зарурлыгы ачыкланды. Керә торган заказларның күләмнәрен һәм техник катлаулылыгын искә алып, «Казан Гипронииавиапромы» җитәкчелеге, сынау стендларын җитештерүне үз мәйданнарында максималь туплау өчен, институт базасында аерым тәҗрибә-конструкторлык бюросы (ОКБ) төзергә карар итә. Бүгенге көнгә бюро белгечләре заказны һәм җиһазның макетын заказчының техник биреме белән килештереп башкаралар. Технологик системаларның макет җыелмасы, заказчының вәкиле белән үзара килештерелеп, кабул ителгәч, ул төргәкләнә һәм заказчы мәйданына проект хәлендә монтажлауга озатыла. Перспективада – өлешчә җитештерүдән башлап, эшкәртүгә, төзүгә, әзерләүгә, монтажлауга һәм заказчы мәйданында сафка бастыруга кадәр – сынау стендларын төзүнең тулы циклын диярлек мөстәкыйль башкару мөмкинлеге биргән үз җитештерү егәрлекләрен булдыру. «КНИАТ» ААҖ җитештерү мәйданында Surpass («Сёрпасс») Кытай компаниясе белән уртак җитештерү булдыру – шушы юнәлештәге беренче адым булып тора.

Реклама

Авиация оешмаларына стендлар эшләүдән тыш, бюро аерым җитештерүләр өчен дә сынау стендлары эшкәртү белән шөгыльләнә. Бу эшчәнлекнең нигезендә – авиация проектлары кысаларында ясалган эшләнмәләр, югары төгәллек, ышанычлылык һәм нәтиҗәлелек белән аерылып торган технологик чишелешләр. Заказчыларның географиясе төрле һәм заказлар Татарстаннан еракларга да тарала. Әле күптән түгел генә институт «ОДК-Газовые турбины» ААҖ базасында (Рыбинск) блок-контейнерлардан эшләнгән газ-турбина энергетика һәм газ суырту агрегатларына завод контроль сынауларын үткәрү өчен универсаль сынау стендын төзү эшләре комплексын башкарды. Бу елның ахырына Самараның авиация һәм космик двигательләр төзүдә махсуслашучы «Кузнецов» ГАҖнең двигательләрне (шул исәптән, керү юлында һавасы җылытыла торганнарын да) тулысынча сынау спектрын үткәрә торган стенд базасын үзгәртеп кору һәм техник яктан яңадан җиһазландыру буенча эшләрне төгәлләү күздә тотыла. Предприятие мәйданнарында НК-32 (ТУ-160 стратегик бомбардировщикларына урнаштырыла) һәм НК-25 (шул исәптән, тавыш тизлегеннән югары очу имитациясе белән) двигательләренә сынау үткәрелә.

Институт эшенең тагын бер перспективалы юнәлеше – төрле җитештерү сынауларының тискәре нәтиҗәләреннән булган каты тавышны киметү һәм башка технологияләрне минимальләштерү белән бәйле проектлар. Бу юнәлешнең перспективалылыгы технологик эволюция, һәм шулай ук сәнәгать объектларында даими рәвештә экологик куркынычсызлык таләпләре арта бару белән бәйле. Илебездәге бик күп двигательләр төзү предприятиеләре сынау мәйданнарының үзгәртеп корылуына мохтаҗ, чөнки алар яңа буын двигательләрен сынау вакытындагы тавыш һәм температура басымына чыдамый. Предприятиеләргә, соңгы елларда двигательләрнең техник характеристикаларына таләпләрнең аеруча кырыслануын да күздә тотып, двигательләргә минималь аэродинамик каршылыклы һава кертү һәм эшләп чыгарылган газларны һәм реактив агымны чыгару системаларын үзгәртеп кору зарур.

Институтның бүлендек структурасы – «Казан Гипронииавиапромы» инжиниринг компаниясе, сынау җиһазларыннан тыш, җитештерү проекты линиясен эшләү һәм аның компонентларын куюдан башлап, заказчының персоналын өйрәтү белән бергә, аны куллануга тапшырганчыга кадәр – гальваник җитештерү белән бәйле эшләрнең тулы комплексын тормышка ашыра. Компания шулай ук комплекттагыларны кую һәм аларга сервис хезмәте күрсәтү, аларны чыгым материаллары, шул исәптән, гальваник җитештерү өчен каралган химик реактивлар белән тәэмин итүне дә башкара.

Бүгенге көндә, үзенең юбилее алдыннан, «Казан Гипронииавиапромы» – динамик, күпкырлы һәм, әйтергә кирәк, яшь предприятие. Аның хезмәткәрләренең 35% ка якынын 35 яшькә кадәрге яшь белгечләр тәшкил итә. Шул ук вакытта, үзенең җитәкчесе Борис Тихомиров тырышлыгы белән, институт совет конструкторлык бюроларының – хәтта радиодан учреждениенең барлык кабинетларына трансляцияләнә торган зарядкадан башлап – иң яхшы традицияләрен саклап кала алган. Буыннарның бер-берсе белән бәйләнеше, үткәннәр һәм киләчәкнең сирәк очрый торган балансы оешмага бүгенге көнендә көндәшлеккә сәләтле булып калырга, төрле социаль-икътисадый каршылыкларга уңышлы җавап бирергә мөмкинлек тудыра. Һәм бу нәкъ менә 75 яшьтә әле барысы да башлана гына, дип әйтергә мөмкин булган бәхетле очрак.

420127, Казан ш.,
Дементьев ур., 1 йорт.
Тел. (843) 571-95-48,
Факс (843) 571-96-56

75 КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ

PRESSA.RU

15 ЕЛ ДӘВАМЫНДА – ЮГАРЫ КӨЧӘНЕШ ӨЛКӘСЕНДӘ

ЭЛЕКТРОЩИТ

«Электрощит» АҖ белгечләре тарафыннан компаниянең 15 еллык тарихы эчендә 500дән артык подстанция, көчәнеше 220 кВ ка кадәрле 1000 км дан артык электр тапшыру линиясе һәм башка бик күп объектлар эшләнде, проектлаштырылды, җиһазланды һәм төзелде. Инжиниринг компаниясенең тел тидермәслек эшен аның төп партнерлары – «Татнефть» ГАҖ, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ, «ТАНЕКО»АҖ, «Аммоний» АҖ һәм башка бик күпләр югары бәяли.

– Предприятиебез тәҗрибәсе күрсәткәнчә, объектларны ахырына кадәр төзеп тапшыру – заказчы өчен иң уңайлы инструмент, – дип сөйли «Электрощит» АҖ генераль директоры Дмитрий Рослов. –Проектын безгә ышанып тапшырганнан соң, заказчыга башка борчылыр сәбәп калмый. Проектлаштыру, төзү, җиһазлар белән тәэмин итү, аларны монтажлау һәм эшләтеп җибәрү... – бер сүз белән әйткәндә, объектны эксплуатацияләүгә тапшырганчы, барлык этапларны да үз өстебезгә алабыз. Заказчы объектны тулысынча әзер хәлендә кабул итеп ала – «тотын да рәхәтләнеп эшлә генә». Предприятие 0,4 кВ тан алып 220 кВ ка кадәрле электртапшыргыч линияләр, ачык типтагы трансформатор подстанцияләре һәм капитальясә блоклы-модульле бинадагы трансформаторлы подстанцияләрне төзеп, җиһазлап бетереп тапшыра, алдынгы технологияләр кулланып, предприятиеләрнең электротехник инфраструктурасын реконструкцияләүне дә башкара.

ТР базарында эшләү дәвамында «Электрощит» АҖ электр белән тәэмин итү системасы инфраструктурасын үстерүгә зур өлеш кертте. Компания 200 дән артык проектны тормышка ашырды, аерым алганда, болар:

– Smart Grid (акыллы челтәрләр) технологиясе буенча тормышка ашырылган Иннополисны эчке яктан электр белән тәэмин итү системасын проектлаштыру;

– 110 кВ лы «Зәй ГРЭСы – ТАНЕКО» ЭТЛ; «220 кВ лыҮзәк – ТАНЕКО» ЭТЛ; «Татнефть» ГАҖнең Әшәлчәдәге үтә үзле нефть чыганагында 110,35 һәм 10 кВ лы ЭТЛ; «ТАНЕКО» АҖнең 124/39 Бүлү трасформатор подстанциясен ахырына кадәр төзеп-җиһазлап тапшыру;

– суммар электр куәте 24 МВт булган «MWM» газ-поршеньлы генератор установкалары базасында өч мини-ҖЭҮ төзелешендә катнашу;

– «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖндә (ТРнда беренче категорияле куллануычыларны электр энергиясе белән сыйфатлы тәэмин итү өчен хезмәт итә торган иң эре бүлү пунктларының берсе) 110 кВлы 1,2 Бүлү подстанцияләре объектларын бүлү пунктлары белән тәэмин итү, аларны техник җиһазлау буенча инженерлык чишелешләрен эзләү, проектлаштыру;

– Германия инвесторлары Татарстан компаниясенең тәҗрибәсен югары бәяләделәр һәм «Мефро уилз Руссиа завод Заинск» көпчәк цехын реконструкцияләүне: проектлаштыруны, электр җиһазларын эшләү һәм алар белән тәэмин итүне, монтажлау һәм эшләтеп җибәрү-көйләү процессын ышанып тапшырдылар.

Үзенең 15 еллык тарихы эчендә «Электрощит» АҖ тормышка ашырган проектларның барысын да санап бетерү, кызганыч, мөмкин эш түгел – аларның саны шактый күп. Шулай да иң мөһимен билгеләп үтик: әлеге проектларның барысы да югары сыйфатлы итеп, кыска вакыт эчендә башкарылды. Моңа аптырыйсы да юк: сыйфат, ышанычлылык һәм өлгерлек – болар барысы да компания эшчәнлегенең нигезен тәшкил итә.

423450, Әлмәт шәһәре,
Заслонов ур., 4а йорты
Тел.: 8 (8553) 45-70-30, 45-64-46
Факс: 8 (8553) 37-35-77
www.elecshield.ru

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ:

Гамәлгә куючы 2001 елда, «Электрощит» АҖ төзегән вакытта, компаниянең миссиясен болай билгеләгән:

«Энергия куәтен үзләштереп, дөньяны ышанычлырак һәм яктырак итәргә». Әлеге фәлсәфә компания үсешенең төп юнәлешләрен билгеләргә ярдәм итә:

- комплексды проектлар белән идарә итү һәм аларны ахырына кадәр тормышка ашыру;
- проектлау һәм инжиниринг;
- электротехника җиһазларын җитештерү;
- электротехника җиһазлары белән тәэмин итү;
- шеф-монтажлау һәм шеф-көйләү хезмәтләре күрсәтү;
- өзү, монтажлау һәм эшләтеп җибәрү-көйләү процессын башкару;
- гарантия буенча, гарантиядән соң хезмәт күрсәтү, даими сервис;
- заказчының эксплуатацияләү хезмәтләре өчен укулар оештыру һәм аларны үткәрү.

Компания, һәр клиентка шәхси якын килеп, мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә теләсә нинди катлаулылыктагы бурычларны оптималь дәрәҗәдә үтәргә омтыла.

Реклама

Язылһәм телевизор от!

1 Языл
30.12.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!

Акцияне үткәрү вакыты: 20.10.2016 - 20.03.2017

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84, өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

PRESSA.RU

ГОЛЛИВУДТА **МОНДЫЙНЫ ӨШЕРМӘСЛӘР!**

Кино елы ахырына якынлаша. Менә кайда бөтен нәрсәне чыннан да кадрлар хәл итә ул. Бүген Татарстан кинематографы нәрсәгә сәләтле? Сезнең игътибарыгызга Tatllywoodны тәкъдим итәбез – фактлар, фаразлар, эксперт фикерләре.

Автор:
Ольга Туманская

ЯКУТИЯДӘН КҮПКӘ КАЛЫШАБЫЗМЫ?

– Минем Хакасия, Бурятия, Башкортостан, Якутиядә төшерелгән күп кенә картиналарны караганым бар. Хәзерге вакытта Мәскәүдә һәм Санкт-Петербургта төшерелә торган фильмнар белән чагыштырганда, аларны карау күпкә кызыграк. Әйе, кайвакыт алар бераз «кытыр-шырак», тик бу – тере, җанлы кино, чөнки аны төшерүчеләр үз якташларына үз ана телләрендәниндидер бик мөһим нәрсәне җиткерергә тели.

Россиянең абруйлы кино тәнкыйтьчесе Сергей Лаврентьевны Татарстан кинематографы белән күптәнге элемтәләр бәйли. «Ника» Россия кино сәнгате академиясе академигы, Россия Оскар комитеты әгъзасы быел да XII Казан Халыкара мөселман кинофестиваленең сайлап алу комиссиясен җитәкләде.

Фотолар И. Рәхимбайдан, Р. Рәшитовтан, А. Барыкиннан, Казан мөселман кинофестивале матбугат хезмәтеннән алынды.



Илшат Рәхимбайның «Представь» фильмы

Аның фикеренчә, бүген Россиядә милли кинематографның гадәттән тыш көчле үсеше күзәтелә. Татарстан исә әлегә бу «дөнья картинасына» туры килеп бетми: күп өлкәдә лидер булырга күнеккән республика кино тармагында арттанрак сөйрәлә. Ә инде күптән түгел Якутиядән килеп ирешкән хәбәрләр фонында безнең кәеф тагын да төшә: аларның «Мой убийца» лентасы… «Алтын глобус»ны дәгъвалый!

– Минем уйлавымча, Якутиядә моңа этәргеч булырлык шартлар бар – ул, бөтен дөньядан аерылган булганга, шул рәвешле үзен җиһанга танытмакчы була, – дип, үз дәлилләрен китерә Лаврентьев. – Татарстан исә болай да бөтен җиһанга мәгълүм, үзе турында оран салуга мохтаҗ түгел. Бәлки, эш нәкъ менә шундадыр?

КИНОНЫ – СТУДИЯГӘ!

Кино сөюче Сталин гомеренең соңгы елларында инде бөтен яңа чыккан леңталарны карарга өлгерми башлаган. Шунлыктан ул сан артыннан кумаска, бары тик шедеврлар гына төшерергә боерган. Нәтиҗәдә 1951 елда гигант илдә нибары өч фильм һәм тагын алты фильм-спектакль чыгарылган. Әмма бу картиналар арасында бернинди шедевр да булмаган. Һәм бары тик соңрак, кино төшерү арткач кына, «Сорок первый», «Баллада о солдате», «Летят журавли», «Неотправленное письмо», «Застава Ильича» кебек мәшһүр леңталар пәйда булган…

Сергей Лаврентьев миңа бу хәлне диалектиканың төп законнарыннан берсенә – «санның сыйфатка күчүен» – ачык иллюстрация буларак сөйли.

– Ниндидер гайре табигый, мәшһүр нәрсә пәйда булсын өчен, индустрия эшләп китәргә тиеш, – ди ул. – Татарстанга инде үз киностудиясен төзергә вакыт. Бу турыда ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин белән очрашу вакытында Александр Прошкин (совет һәм Россия киносы классигы, Казан мөселман киносы фестиваленең жюри рәисе – ред.) сүз кузгаткан иде. Мин аны хуплыйм. Сездә кинематографның асылын аңлаган режиссерлар бар, тик аларның гамәлдәге кино индустриясе бирә торган тәҗрибәсе юк. Мәсәлән, картинаны караганнан соң: «Вася, тамашачы барысын да күптән аңлады инде. Бу эпизод сигез минутка сузылырга тиеш түгел, бер минут та җитә!» – дип әйтерлек редактор юклыгы сизелә.

Шул ук Якутия тәҗрибәсенә килсәк, андагы эшләп торган киностудияне һәм үз ана телләрендә елына 10–12 шәп фильм төшерүче энтузиастларны атарга кирәктер. Һәм алар барлык жанрларда да эшли – анда автор киносы да, триллер, хоррор, боевик һәм хәтта эротика да бар.

Кино белгече, тәнкыйтьче, Казан театр училищесы укытучысы Әдилә Хәйбуллина да Лаврентьев фикере белән килешә.

– Татарстанның үзенең оста режиссерлары бар: Фәрит Дәүләтшин, Илдар Ягъфәров, Алексей Барыкин, Салават Юзеев. Яшьләр дә калышмый – Илшат Рәхимбай, Рөстәм Рәшитов һәм башкалар. Мин аларга ышанам. Әмма аларга осталыкларын чарлар өчен база кирәк. Үзенең белгечләр командасы булган киностудиябезне оештыру бу проблеманы хәл итәр һәм Татарстанда кинематографның үсешенә этәргеч булыр иде. Тик бу әлегә хыялда гына кала бирә. Бу турыда сүз әллә ничә ел бара инде…

ФАРАЗМЫ? ОПТИМИСТИК!

Кино белгечләре һәм тәнкыйтьчеләренең фаразлары артык сак булуга карамастан, Татарстан кинематографчыларының үзләрендә энтузиазм ташып тора.

– Тиздән безнең кинематографта алга китеш кенә түгел, ә шартлау, бомба булачак! – дип ышандыра режиссер һәм продюсер, Казан мәдәният институтының кино сәнгате кафедрасы мөдире Алексей Барыкин. – Ихтимал, бу ыргылыш безгә үсеш дәрәҗәсе буенча якут кинематографын куып тотарга һәм хәтта узып китәргә дә мөмкинлек бирер. Ел дәвамында Казанда берьюлы сигез тулы метражлы нәфис фильм төшерелә, һәм алар барысы да кинотеатрларда прокатка чыгарырлык дәрәҗәдә булырга тиеш. Аларның барысында да диярлек кызыклы «фишка» бар, һәм шул тамашачының игътибарын җәлеп итәр, дип ышанам.

– Татарстан кинематографы үсешенә элегрәк нәрсә комачаулаган соң?

– Прокат өчен яраксыз бик күп документаль һәм кыска метражлы фильмнар төшерелде, ә менә тулы метражлы картиналар бөтенләй юк иде диярлек, – дип саный башлады Барыкин. – Беркем дә кечкенә бюджет белән тулы метр төшерергә ризалашмады, моның сыйфатлы буласына ышанмады. Бездә прокат өчен махсус төшерелгән жанрлы фильмнар юк иде. Коммерция кинотеатрлары да җирле картиналарны прокатка чыгарырга атлыгып тормады.

– Әйбәт фильм хата һәм ялгышлар туфрагында үсеп чыгарга тиеш, – ди Әдилә Хәйбуллина. – Бүген мин нәрсә дә булса төшергән һәркемне хуплыйм – кайчан да булса нәкъ менә шул базада Татарстанның үзенең Тарковские үсеп чыгачак. Ә инде бернәрсә дә эшләмичә, финанс агымнарыннан яки кеше ресурсларыннан файдаланмыйбыз икән, – бездә беркайчан да бернәрсә дә булмаячак.

Кино индустриясе детальләрдә

2015 елда Россиядә үзендә төшерелгән 123 уен фильмы прокатка чыккан.

2016 елда кино тармагына дәүләт ярдәме 7,6 миллиард сумны тәшкил иткән.

ТР Мәдәният министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 ел азагына Татарстанда дәүләт ярдәме белән 9 фильм төшереләчәк: 4 – документаль, 4 – уен, 1 анимацион картина.

БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧ

Быел Татарстан кинематографы өчен бик зур вакыйга булды: үзебездә әзерләнгән картина республика кинотеатрларында

PRESSA.RU

1

2

1. Алексей Барыкин Руслан Вәлиевка кыска метражлы «З/К» (Татарстан) өчен диплом тапшырды.

2. Владимир Мединский «Семейные хлопоты» фильмын карый.

3. XII Казан Халыкара мөселман киносы фестиваленең ябылу тантанасы.

күрсәтелде. Бу беренче карлыгач – тулы метражлы «Семейные хлопоты» комедиясе.

– Дөресен әйтегез әле, зинһар, беренче коймак төерле булмадымы? – дип сорыйм фильмның режиссеры һәм продюсеры Алексей Барыкиннан.

– Фильм прокатта биш шимбә-якшәмбе буена сакланды – яхшы күрсәткеч бу. Картинаның чыгымнары Татарстандагы прокат белән генә капланмады, әмма бу куркыныч түгел, чөнки хәзерге фильмнар шул рәвешле бюджетларының бер өлешенең чыгымын гына каплый. Хәзер без икенче этапка күчтек – башка шәһәрләрдә күрсәтүгә, телевизорда һәм интернетта күрсәтү өчен хокукларны сатуга. Алай гына да түгел, Мәскәүдәге бер компания бездән сценарийны сатып алырга һәм инде Россия күләмендә танылган йолдызлар белән ремейк төшерергә теләи. Әгәр бу барып чыкса, безнең фильм төшерүгә киткән чыгымнарыбыз капланачак, һәм яхшы табыш та керәчәк.

Алексей Барыкин әйтүенчә, картина мөһим прецедент тудырган: бюджеты нибары 1,2 миллион сумлык һәм прокат хронометражына ия жанрлы фильмны республиканың барлык коммерция кинотеатрлары диярлек прокатка алган. Шул рәвешле, ул Татарстан кинематографы үсешенең якутныкына охшаган моделен тәкъдим иткән, аны шунда ук эләктереп тә алганнар.

– Үзегез уйлап карагыз: 2016 елда бөтен режиссерлар диярлек, бик аз бюджетлы (500 мең сумнан алып 3–4 миллион сумга кадәр) булуга карамастан, үз проектларын тулы метражга җиткерергә омтыла. Күпчелеге тамашачы яратып карый торган жанрларны – мажаралы фильм, мюзикл, комедия, куркыныч фильм, мелодраманы сайлый. Һәм, әлбәттә инде, алар барысы да «Семейные хлопоты» схемасы буенча коммерция мультиплексларында прокатка чыгарга ниятли. Мөгаен, Татарстан кинематографының бер генә җитди проблемасы калгандыр – республика тамашачысының җирле кинофильмнарга шикләнеп каравы. Тик, вакыты җиткәч, монысы да хәл ителәчәк.

«РОДИНА» КИНОТЕАТРЫН ШТУРМЛАУ

Мин өченче залда идәндә утырам. Миңа әле бәхет елмайды: фойе тулы кеше Габдрахман Әбсәләмовның атаклы романын экраннан карарга керә алмый калды бит. Бу 2015 ел хатирәсе. Ул чакта «ТНВ» телеканалы заказы буенча Ренат Әюпов төшергән «Ак чәчәкләр» картинасы XI Казан мөселман киносы фестивалендә конкурстан тыш программаның ябылу фильмы итеп күрсәтелгән иде. «Родина» кинотеатрының биш залын тамашачылар штурм белән алды.

«ТНВ» каналы бүген дә татар классикасын экранлаштыруны дәвам итә. Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» бестселлеры буенча сериал төшерүне Татарстандагы иң сәләтле яшь режиссерларның берсе Рөстәм Рәшитовка ышанып тапшырганнар. Ул повестьтагы вакыйгаларны безнең көннәргә күчергән.

– Миңа республикабыздагы бүгенге вазгыять ошый, – ди Рөстәм. – Хәтерләсәгез, безнең кино төшерүчеләребез арасында упкын барлыкка килгән иде: өлкән буын белгечләре эшли, ә алардан соң – беркем дә юк... Берничә ел элек мәдәният институтында кино сәнгате факультеты ачылды, һәм анда яшьләр бик теләп укый башлады. Аз гына вакыт үтте әле, ә инде быел ук берничә тулы метражлы проект гөрләп эшли, аларда яшь режиссерлар гына түгел, яшь операторлар, рәссамнар да катнаша. Аларга 20–25 яшь. Безгә ышаналар, һәм бу бик сөендерә. Дәүләт заказы линиясе буенча төшерелә торган картиналарны да ышанып тапшыралар хәтта. Без хәзер әзер материалдан трейлер монтажлыйбыз, һәм инде телефильм түгел, чып-чын кино килеп чыкканлыгы күренә.

Бүген продюсерлык тармагында мохтаҗлык сизелә – Татарстан киносына яшь креатив профессионаллар җитми. Ә алар, мәгълүм булганча, кинематограф үсешенең хәрәкәтләндергеч көче булып тора:

Рөстәм Рәшитовның «Тапшырылмаган хатлар» фильмын төшерү.

кинофестивальләрдә «Иң яхшы фильм» өчен бүләкне дә нәкъ менә продюсерның алуы сер түгел. Хәер, берничә елдан бу проблема да хәл ителер дигән өмет бар – Казан мәдәният институтында профильле юнәлеш эшли башлады.

Кино? Менә ул
Татарстан – тулысынча булмаса да, кинопрокат системасын саклап кала алган сирәк төбәкләрдән берсе. ТР Мәдәният министрлыгы мәгълүматлары буенча, «Татаркино» дәүләт учреждениесе, Чаллыдагы һәм Бөгелмәдәге ике филиалы белән бергә, ел саен 100 дән артык фильм сатып ала, биредә 1 дәүләт һәм 9 муниципаль кинотеатр, 34 кинозал, 27 күчмә кинозал эшли. Федераль үзәк белән уртак финанслана торган 10 муниципаль кинотеатр заманча кино җайланмалары белән җиһазландырыла, алардан дүртесе – Буа, Тәтеш, Әгерҗе һәм Менделеевскида – инде эшли башлаган.

МИЛЛИ КИНОПРОКАТ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Телевидение өчен «Тапшырылмаган хатлар» картинасы татар телендә төшерелә, әмма кинопрокат өчен тулы дубляж ясау фикере дә бар. Ә менә яңа тулы метражлы «Айсылу.фильм»ны Рөстәм Рәшитов тәрҗемә итәргә җыенмый.

– Башта аның җирле прокатта нинди нәтиҗәләр күрсәтүен карарга кирәк, – ди сценарий авторы һәм картинаның продюсеры Алексей Барыкин. – Бу безнең кино өчен менә дигән хөкем, һәм безнең татар телебез һәм татар телле тамашачыларыбыз булуы зур бәхет ул. Чөнки милли телләрдәге фильмнарга мәскәүлеләр дә, америкалылар да көндәш була алмый.

Шул ук вакытта, Барыкин әйтүенчә, мәсьәләнең тискәре ягы да бар – мондый фильмнарның потенциаль тамашачысы күп түгел. Гәрчә дөньяда җиде миллионнан артык татар яшәсә дә, аларның бер өлеше генә татарча сөйләшә, ә ул өлештән кайберләре генә җирле киноны карарга тели, аларның да бик азы кинотеатрга килеп, билет сатып алырга әзер.

– Минем исәпләүләрем буенча, татар телендәге фильм иң күбе 4–5 миллион сумлык яки аннан да кимрәк бюджетта гына үзенең чыгымнарын каплый алачак, – дип нәтиҗә ясый Барыкин.

АКЧА КАЯН ТАБАРГА?

«Представь» фильмына сценарий язылу тарихы сер белән өретелгән. Былтыр Казан кино фестиваленең ябылу тантанасында Россия мөфтиләр советы һәм РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Рушан Аббасов сәхнәгә күтәрелә. Ул аклы-каралы киемнән була, һәм залда арттагы рәтләрнең берсендә утырган яшь режиссер Илшат Рәхимбайга хәзрәтнең ак якасы еректан католик рухание образын хәтерләтә.

– Минем күз алдыма бер үк вакытта мулла да, священник та булган шәхес килеп басты, – дип сөйли Илшат. – Бу соңгы тамчы булды: дөнья һәм кешеләр турында әллә кайчаннан бирле башымда йөрткән фикерләрем бер мизгелдә сценарий идеясенә әйләнде дә куйды.

Теләсә кайсы кино төшерүченең бөтен башлангычларына аяк чала торган беренче проблема финансларга килеп тоташа. Акча каян табарга? Үзенең тулы метражлы фильмы бюджетын Илшат кимендә 5 миллион сумга бәяли – «дөньяга оялмыйча күрсәтә алырлык картинаны шуннан да кимрәк акчага төшереп булмый».

– Ничек уйлыйсыз, кино индустриясенә дәүләт ярдәм итәргә тиешме? – дип сорыйм Сергей Лаврентьевтан.

– Минем фикеремчә, аңа дәүләт әллә ни ярдәм күрсәтә алмый, чөнки акчасы болай да юк. Билгеле, коммерция рельсларына басарга кирәк. Картиналар кинотеатрларда күрсәтелергә һәм үзләре акча эшләргә тиеш.

– Тик бу коммерция стратегиясе кинодагы бөтен милли колоритны үтермәсме соң?

– Якутиядә үтермәде бит. Билгеле, аларның фильмнары Россиядә зур прокатка чыгарылмый, тик бу

PRESSA.RU

Илшат Рәхимбайның «Представь» фильмы.

аларга җирле прокат хисабына чыгымнарын капларга комачауламый. Якутиядә миллион кеше яши, Татарстанда исә – тагын да күбрәк! Менә «бомба» чыкса, бөтен кеше аны шунда ук карарга теләячәк. Чөнки кешегә үзе турында, үзенә янәшә, якын булган нәрсәләр турында карау һәрвакыт кызык.

ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Шәрипова әйтүенчә, фильмнар төшерүгә республикада ел саен 7-9 миллион сум акча бүленә.

– Кемдер моны бик аз дияргә мөмкин, әмма Россиянең 49 төбәгендә дәүләт ярдәме бөтенләй күрсәтелми, – ди ул. – Иң мөһиме, бездә бу системалы рәвештә, ел саен эшләнә. Татарстан кинематографчылары дәүләт ярдәменә таянып буласын белә. Шуның белән бергә, кино җитештерүгә инвестицияләр һәрвакыт хәвефле – дөнья практикасы барлык төшерелгән фильмнарның нибары 10 процентының гына 90 процент касса җыюын күрсәтә. Дәүләт финанславының күләме кино җитештерүчеләрнең финансларга булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерерлек түгел.

КЫСКА АДЫМНАР БЕЛӘН

Илшат Рәхимбай үз хыялына гадәти булмаган юл белән барырга карар кылган. Кыска «Представь» фильмының бюджеты ярты миллион сум тәшкил иткән. Шуның 300 мең сумын бөтен дөнья белән җыйганнар: фильм төшерүчеләр финанс эзләүнең заманча ысулын – краудфандингны кулланырга җөрьәт иткән.

– Бу чыннан да эшли торган система! – дип ышандыра Илшат. – Әгәр син ахмак түгелсең һәм идеяң чыннан да бик шәп икән, әгәр син үзең өчен түгел, кешеләр өчен тырышасың икән, барып чыгачак. Ә менә ничек тагын да күбрәк җыеп булуы инде икенче мәсьәлә. Шунлыктан калган акчаны инвесторлар, иганәчеләр, министрлыклар аша эзләргә кирәк – бүген монысы да мөмкин эш, бары тик тырышу, кешеләр белән очрашу, ә иң мөһиме, аларны илһамландыра торган сюжет табу зарур.

Иҗат төркеменең креативлыгы моның белән генә бетми әле. Кыска метражлы «Представь» – тулы метражлы фильмның озын тизеры гына әле ул.

– Бу бик уңайлы, – ди Илшат. – Без аны конкурс-фестивальләргә җибәрә, инвестор һәм продюсерларга – барлык кызыксынган затларга күрсәтә алабыз, чөнки безнең тулы метр өчен сценариебыз инде әзер.

Егетләрнең планнары чыннан да җитди. Кыска «Представь» фильмы тиздән Канны фестиваленә китәчәк.

– Үтүе икеле, тик бу безнең максат та түгел, – ди Рәхимбай. – Шунлыктан техник якка басым ясадык, фильмның стилен җентекләп уйладык. Бүген халыкара базарда милли кинога ихтыяҗ зур. Мегаполис кинематографы кызыксызга әйләнә: шәһәр кешесенең драмасы, аның фикерләре, проблемалары – болар инде барысы да таныш һәм икенче планга күчә. Беренче планга яңа авторлар һәм рәссамнар чыга, алар үзләренә генә хас үзенчәлекләр белән әр-яңа сюжетлар кора. Бу яктан караганда, безне ишетерләр дигән өмет бар.

Бүген Рәхимбай командасы тагын бер кыска метражлы фильм – Камал театры актерына гашыйк кыз турында комедия төшерә.

– Кыска метр үзен төшерүгә киткән чыгымнарны каплый аламыни? – дип сорыйм режиссердан.

– Әйе, проблема нәкъ менә шунда шул. Тик безнең үз планыбыз бар. Биш кыска метражлы фильм төшерәсең, бер-икене дус режиссерлардан алып була – нәтиҗәдә бер үк темалы, карарга кызыклы сәгать ярымлык программа барлыкка килә. Мәсәлән, «Казан, мин яратам сине!» идеясе белән мин ел буена әвәрә килеп йөрдем, аннары, бу проект өчен җитәрлек сумманы беркем дә бирмәячәген аңлагач, хыялыма адымлап кына барырга булдым.

– Ә бүген кино төшерергә сезгә нәрсә комачаулый? – дип сорыйсы иттем Рәхимбайдан.

– Мин төшерәм. Миңа бернәрсә дә комачауламый, – дип җавап бирде ул.

Ә минем уйлавымча, Татарстанда Кино елының нәтиҗәләре кызыклы һәм көтелмәгәнчә булу ихтималы зур. ▪

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» әсәре **КАЙДА** язылган

Озак яшәүнең сере **НИДӘ**

Сталин **НИ ӨЧЕН** совет балаларының иң яхшы дусты булган

Дөньяда иң матур җир **КАЙДА**

Тутырманың иң борынгы рецепты **КЕМДӘ** саклана

Мирхәйдәр Фәйзи
1891–1928

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

«ГАЛИЯБАНУ»НЫ БАР ИТКӘН МИРХӘЙДӘР

Атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзи Оренбург губернасының Күкшел авылында туа. Балтач районы Шода авылында яшәүче абыйсында кунак булырга ярата ул. Шул якның сихри табигате аны беренче татар музыкаль драмасы – «Галиябану» әсәрен иҗат итүгә илһамландыра. Шоданың ни дәрәҗәдә җырлы-моңлы икәнлеген ачыкларга теләп, шунда юл тоттык. Һәм көтмәгәндә-уйламаганда Галиябануны очраттык. Берне генә дә түгел, ә берьюлы берничәне.

Автор:
Линар Закиров

ШОДАГА ИЛТҮЧЕ ЮЛЛАР

Беренче ноябрьдә Мирхәйдәр Фәйзигә 125 яшь тулган булыр иде. Шодада аның музей-утары урнашкан. Янәшәдә генә сары төстәге мәчет балкып утыра, аның беренче имамы итеп кайчандыр Мирхәйдәрнең абыйсы – Сәетгәрәй билгеләнә. Мондый утарлар авылда икәү генә була, тагын берсе – бай сәүдәгәрдә.

Безне каршы алган музей мөдире Фәрхәт Рәшитов сөйләвенчә, Мостафа белән Зәйнәб Фәйзуллиннар 11 бала тәрбияләп үстерә, Мирхәйдәр – иң кечкенәсе. Аның апасы Шода авылыннан ерак түгел Түнтәр авылы егете Камал Мозаффаровка кияүгә чыга. Апа кеше энеләренең берсен – Сәетгәрәйне Түнтәргә чакыра. Ул анда атаклы Ишми ишан мәдрәсәсенә шәкерт булып керә. «Галия» белән «Хөсәения» мәдрәсәләре белән дан тоткан Оренбург һәм Уфа Күкшелгә якынрак булса да, Сәетгәрәй Түнтәрне сайлый.

Атаклы Ишмөхәммәт хәзрәт Динмөхәммәтав (Ишми ишан) үзенең кызы Фатыйманы Сәетгәрәйгә кияүгә бирә дә, киявен мәдрәсәдә мөгаллим итеп билгели.

1897 елда танылган меценат Зәйнетдин хаҗи Таҗетдинов Шодада мәчет төзергә ниятли. Биш елдан соң бер катлы гыйбадәтханә әзер була. Халык, кемне имам итеп билгеләргә дип Ишмөхәммәт хәзрәткә киңәш сорап бара. Ул, озак уйлап тормыйча, бу урынга Сәетгәрәйне билгели.

– Халык сүзенә ышансак, меценат Зәйнетдин төзелеп беткән мәчетне карарга килгәч: «Мондый акчага мәчет тоткалары алтыннан булыр, дип уйлаган идем», – ди. Боларны безгә музей мөдире сөйли, әлбәттә.

Сүз уңаеннан, Сәетгәрәйнең унбер баласы була. Иң олысы – Сәгыйть Фәйзуллин – журналист, ул В.Ленин, К.Маркс, рус язучыларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Мирхәйдәр Фәйзи беренче тапкыр абыйсына 1901 елда кунакка килә. 1916 елда аларның апалары авырып китә. Мирхәйдәр әнисе Зәйнәб абыстай белән бергә аның хәлен белергә бара. Юллары шактый озын була: Оренбургтан Самарага поездда баралар, Самарадан Кама Тамагына кадәр – пароходта, ә аннан апасы яши торган Малмыжга атларда барып җитәләр.

Сәетгәрәй энесен үзе янына авылга алып китә. Шодада яшь драматург шундагы яшьләр, гореф-гадәтләр белән таныша. Ул гомеренең ахырына кадәр көндәлекләр алып бара. Бүгенге көндә алар КФУның Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә сирәк кульязмалар һәм китаплар бүлегендә саклана.

Сәетгәрәй Фәйзуллинның оныгы Диләрә Мөхәммәдьярова сөйләвенчә, Мирхәйдәр көндәлекләрне иске татар телендә язган, шуңа да туганы аларны укый алмаган. Диләрә ханыма борынгы язуларны заманча татар теленә тәрҗемә итәргә китапханә хезмәткәрләре ярдәм иткән.

– Кульязмалар арасында Сәетгәрәй бабамның улы – Хашыйм Фәйзуллин 1941 елда фронтка китәр алдыннан сурәтләнгән фотоны таптык. Аңа сугыштан әйләнеп кайту насыйп булмый, - дип сөйләде ул безгә.



«ГАЛИЯБАНУ» НИЧЕК ТУГАН?

Музейдагы бүлмәләрнең берсендә төрледән-төрле балалар рәсемнәре эленгән. Аларның һәммәсендә Галиябану сурәтләнгән. Мирхәйдәр Фәйзинең бу әсәре татар телендә иҗат ителгән беренче музыкаль драма буларак билгеле.

Шоданың гаҗәеп табигате Мирхәйдәрне бик илһамландыра. 1916 елда ул көндәлегендә болай дип яза: «Шодада көннәр бик-бик күңелле уза. Авыл минем күңелемнең кагъбәсе булганга, Шоданың авыллыгы мөкәммәл булып, күптән көткән бәхетемә юлыкканга бик шат идем. Һәм алданмадым. Берничә көннән үк иске фикеремне тагын ныграк беркетәм. Дөньяда авыл мужигыннан бәхетле кеше юктыр. Ләкин бу бәхеткә ирешү безнең өчен университет бетерүдән дә авыр. Мужиклык кулдан килми».

Шул ук елның 8 октябрендә ул болай дип теркәп куя: «Казан ягы авылларында йөреп кайттым, бу яктагы авылларда күргән күренешләрдән файдаланып, «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды».

Ике ай дигәндә драматург ниятен тормышка ашыра да. Көндәлектән өзек: «Декабрьдә «Сәгадәтбану» исемле биш пәрдәле пьеса яздым. Баш каһарман Хәлил Юлык егете Вафа Әдһәмовның тибы аркылы сөзелеп чыкты. Пьесаның язылуына да Вафа сәбәп булды. Моңарчы татар әдәбиятында булмаган бер таразда җырлар, уеннар белән язган вә идеалымның көзгесе булган пьесамны тәнкыйтьчеләр аяусыз тибеп җибәрерләр инде. «Гасыр» да «Авыл бәйрәме»мне шулай итте бит. Һәрхәлдә бу тәҗрибәм үземә рух бирде».

Пьесаны язып бетергәч, Мирхәйдәр аны режиссер Вәлиулла Мортазин-Иманскийга җибәрә. Режиссер исә драматургны мактый, шул ук вакытта әсәрнең кимчелекләрен дә күрсәтә. Мирхәйдәр килешкәннәрен төзәтә.

Өстәвенә, «Сәгадәтбану»ның исеме «Галиябану»га алыштырыла. Эш шунда: әсәр фаҗигале тәмамлана, шуңа да төп каһарманны «сәгадәт» дип атау дөрес булмас иде. Бу сүз гарәпчәдән «бәхет» дип тәрҗемә ителә, ә «галия» «бөек» дигәнне аңлата.

«Галиябану»ны тәүге тапкыр 1916 елда Орскида һәвәскәр труппа куя, 1917 елда ул Оренбургта сәхнәләштерелә. 1918 елда спектакльне Казан тамашачысына күрсәтәләр. Галиябану ролен төрле елларда Бәдәр Йосыпова, Мәрзия Миңлебаева, Рокыя Кушловская, Галия Кайбицкая, Роза Хәйретдинова кебек артисткалар башкара.

Шундый кызыклы бер факт та мәгълүм: 1923 елда татар язучысы Гадел Кутуй Мирхәйдәр Фәйзинең «Адашкан күңел» спектаклен карарга керү өчен, театр тирәсендә контрамарка эзли, аптырап кемнән һәм ничек юнәтергә белмичә йөргәндә, озын буйлы, чандыр гына бер егетнең үзе кебек билет эзләгәне күзенә чалына. Кутуй аның белән танышырга теләп, сүз ката. Аның Мирхәйдәр Фәйзи икәнлеген белгәч, язучы ышанмый. Ничек инде автор үз спектакленә билет эзләп йөрсен, дип уйлап куя ул. Шик-шөбһәсен тарату өчен, ул спектакльдән соң: «Автор сәхнәгә чыксын!» – дип кычкыра. Бу теләкне тамашачылар да күтәреп ала. Мирхәйдәр Фәйзи сәхнәгә күтәрелгәч, Гадел Кутуй һушсыз кала.

Диләрә Мөхәммәдьярова сөйләвенчә, бервакыт шулай Мирхәйдәр, пьесасын сәхнәләштергәннәре өчен, гонорар сорап театрга килә. Әмма анда «түләмибез» дип, аны кире борып җибәрәләр. Драматург, кәефсезләнеп, урамнан барганда, берзаман акча янчыгына юлыга да кулына алып: «Кем югалтты?» – дип сөрән сала. Эндәшүче табылмагач, Мирхәйдәр милиция хезмәткәренә мөрәҗәгать итә. Тегесе исә драматургка акчаны дәшми-тынмый гына үзара бүлешергә тәкъдим итә. Әмма Мирхәйдәр, ризалашмыйча, табылдыкны участокка илтеп тапшыра.

PRESSA.RU

«ЙӨРӘГЕМ КАЗАНДА КАЛА»

Утарның икенче бер бүлмәсендә XX гасыр башы интерьеры чагылыш тапкан. Биредә Фәйзуллиннарның берничә шәхси әйбере саклана. Бүлмәнең бер почмагында сары шкаф тора. Быел Диләрә Мөхәммәдьярова музейга тагын берничә эксклюзив экспонат бүләк иткән: Фатыйманың муенсасын, Сәетгәрәйнең улы – Сәгыйть Фәйзуллинның күзлеген, тагын бер улы Икрамның үз куллары белән ясаган тартмачыгын, кызы Гәүһәрнең (Диләрә ханымның әнисе булып чыга – авт.) кул эшләрен.

Бормалы баскычтан икенче катка менәбез. Монда бөек драматург яшәгән бүлмә урнашкан.

– Мирхәйдәр Фәйзи шушы караватта йоклаган, дип фаразлыйбыз, – дип аңлата музей мөдире Фәрхәт Рәшитов. – 1923 елда Казанга барышлый ул абыйсына кереп чыга. Шул чакта аның Гыйлембану исемле авыл кызына күзе төшә. Мирхәйдәр аңа багышлап шигырь һәм «Сәрвиназ» хикәясен яза. Әмма ул вакытта Гыйлембану бай малае Ибрай белән очрашып йөргән була.

Диләрә Мөхәммәдьярова сөйләвенчә, Мирхәйдәр гади кызлар белән җитди мөнәсәбәтләр кора алмый. Юкса, көндәлекләрендә ул авыл кызларын матур итеп сурәтли, аларның яхшы тәрбия алганлыкларына басым ясый. Аның гаиләсендә барысы да затлы нәселдән чыккан хатын-кызларга өйләнә, аның әнисе Зәйнәб тә, әбисе Гайникамал да, абыйларының хәләл җефетләре дә татар морзаларының оныклары була.

– Илдә булган кискен борылыш вакытында Мирхәйдәр унбер туганын җир куенына иңдерә. Шушы авырлыклардан соң, ул көндәлегендә: «Ходай Тәгалә юк ул!» – дип язуга барып җитә. Шул елларда яндырылган көндәлекләрендә нәрсә булгандыр – фаразларга гына кала. Бәлки, аларны яндырып, Мирхәйдәр Фәйзи үз гомерен саклап калгандыр. Аңа инде яшәргә дә күп калмаган була, – дип сөйли Диләрә ханым.

Казан табиблары Мирхәйдәрдә туберкулез таба. Ул вакытта бу авыруны дәвалый алмыйлар, ул хөкем карары белән бер була. Драматургка Урал якларына, аның сәламәтлегенә уңай булган климатка кайтырга киңәш ителәә. Казаннан киткәндә, ул яңадан Шодага кереп чыга. Ә анда исә халык ду килеп дуслык бәйрәмен билгеләп үтә.

– XIX гасырның 70нче елларында, җир бүлә алмаганлыктан, Шода белән күрше Куныр авылы халкы арасында ызгыш туа. Шундый бәрелешләрнең берсендә Шода

кешеләре Кунырның бер егетен кыйнап үтерәләр. Шоданың 15 егетен сөргенгә җибәреп, берсе генә туган авылына әйләнеп кайта. Шушы канкойгыч вакыйгадан соң, ике авыл халкы, дуслашырга теләп, бәйрәм оештыра. Ул бүгенге көндә үткәрелми, онытылган инде. Бәйрәмнәр хәзер болай да күп: Сабан туе, авыл бәйрәме һәм башкалар, – дип санап китте Фәрхәт Рәшитов.

Галимҗан Ибраһимов, авыл тормышын һәм кешеләрен шулкадәр үтемле итеп сурәтләүдә Мирхәйдәр Фәйзигә тиңнәр юк, дип әйтеп калдыра. 1923 елда Казанда узган әдәби конкурста драматургның «Адашкан күңел» пьесасы җиңеп чыга. Барысы да бертавыштан Мирхәйдәргә Казанда калырга кирәк, ди. Ул яраткан шәһәрендә болай да калырга риза булыр иде, әмма авыру аны Казаннан күченеп китәргә мәҗбүр итә. Туган ягы – Оренбург губернасына кайткач, ул көндәлегенә: «Мин китәм, әмма йөрәгем Казанда кала», – дип яза.

Мирхәйдәргә Үзәк көнчыгыш китапханәсенең балалар бүлеге эшен җитәкләргә тәкъдим итәләр. Ул балаларны язарга өйрәтә, рус телендәге шигырьләрне татарчага тәрҗемә итә, авыл мәктәбе турында нәниләр өчен пьеса яза. Пролетариат белән мещаннарның балаларына бертигез мөнәсәбәттә булганы өчен, хезмәт җыелышында берәү: «Фәйзулинны долой!» – дип кычкыра. Драматург өенә кайтып, көндәлегенә: «Кемнең хаклы булганын вакыт күрсәтер», – дип теркәп куя.

ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘСЕ

Диләрә Мөхәммәдьярованың Мирхәйдәр Фәйзинең иске татар телендә язылган әсәрләренең хәзерге заман татар теленә тәрҗемә ителмәвенә эче поша. Шушы тәкъдим белән ул Татарстан Фәннәр академиясенә дә мөрәҗәгать иткән. Әмма анда, барлык башкарыласы эшләр ун ел алдан язылган инде, Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләрен тәрҗемә итү эш планына кертелмәгән, дип җавап биргәннәр. Моның өчен, билгеле, акча кирәк. Фәйзинең әсәрләрен шулай ук рус теленә тәрҗемә итүче дә юк.

– Татар классигының иҗаты белән кызыксынган, әмма татарча укый да, сөйләшә дә белмәгән кешегә нишләргә? – дип гаҗәпләнә Диләрә ханым. Ул, Мирхәйдәр Фәйзинең юбилее алдыннан, Орск шәһәренең драма театрына да шалтырата. Драматургның тормышы да, иҗаты да бу шәһәр белән тыгыз бәйләнгән, «Галиябану»ны да шушында яза бит ул, ди. Театр директоры Диләрә ханымга болай дип аңлата: Мирхәйдәр Фәйзинең рус телендә пьесалары юк, ә Орск шәһәрендә татар театры юк. Аның каравы, драматург исемен йөртүче Оренбург татар театры ноябрь башында тамашачыга Мирхәйдәр Фәйзи пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Адашкан күңел» спектаклен тәкъдим итте. Ә Балтач районында быел халык театрлары арасында драматург исемендәге иҗат фестивале оештырылды.

ИШЕТӘ БЕЛЕРГӘ КИРӘК...

Музей янындагы бер катлы бинада башлангыч мәктәп белән балалар бакчасы урнашкан, анда бишәр бала укый һәм тәрбияләнә. Нәниләр музейның көтеп алынган кунаклары: алар татар әдәбияты классикларының юбилейларын бәйрәм итүдә катнаша, шигырьләр укый, моның өчен Фәрхәт абыйлары аларга кучтәнәч тә өләшә.

Шода чыннан да җыр-моңга бай як булып чыкты. Биредә һәр кошчык, һәр бөҗәк, һәр агач үзенчә җырлыйдыр кебек. Моны ишетә белергә генә кирәк. Нәкъ Мирхәйдәр Фәйзи ишеткән сыман.

PRESSA.RU

96+ | ОЗЫН ГОМЕРЛЕ БАБАЙЛАРЫБЫЗ

96 яшьлек «Татарстан» журналы үзенең яшьтәшләрен һәм, гомумән, республикабызның «озын гомерлеләрен» эзләвен дәвам итә. Тарихи һәйкәлме ул, әллә истәлекле урын гынамы – «Татарстан» үзенең укучыларын гасырлар дәвамында әһәмиятен һәм тарихи кыйммәтен җуймаган шундый уникаль һәйкәлләр, почмаклар һәм Татарстаныбызның башка күренекле урыннары белән таныштыра бара – алар үзләренең матурлыклары, үзенчәлекләре һәм... мәңгелек булулары белән һәркемне җәлеп итә.

ЯМАШ ЧИШМӘСЕ

Әлмәт районының Ямаш авылына керү юлында инде бик күп еллар буе (элмә тактага «287 ел» дип язылган) «Изгеләр чишмәсе» ага. Хәзер аны Татарстаннан читтә яшәүчеләр дә яхшы белә, аңа инде яңа исем кушылган, – ә элгәре ул исемсез бер чишмә, ягъни Ямашка елгасының «башы» булган, җирле халык аны «Изге баш» дип атап йөрткән.

Әле Екатерина патшалык иткән заманнарда бу урында кемдер тәре тапкан һәм аның астыннан су бәреп чыккан, дип сөйлиләр. Суның составында көмеш бар, һәм ул, галимнәр фикеренчә, Ямаш суына үзгә бер пакьлек һәм савыктыргыч көч бирә. Күрәсең, химия, биология буенча белемнәре булмаса да, борынгы бабаларыбыз бу суның файдалы икәнен аңлый алган һәм аны могҗизалы чишмә дип атаган. Бу хәл 1729 елда булган.

Шул рәвешчә, «Хуҗалар тавы» астыннан бәреп чыккан шифалы чишмә, суында зәңгәр күк йөзен һәм тәреләрдәге изгеләрнең сурәтләрен чагылдыра-чагылдыра, гасырлар дәвамында агып утыра бирә.

Православие динендәгеләр биредә чукындыру йоласын үтиләр, никах укыталар. Җирле риваятьләр буенча, тауның иң биек түбәсендә мәҗүсиләрнең гыйбадәтханәсе урнашкан – борынгы болгарлар анда Тәңрегә корбан китерә торган булган.

Соңрак халык чишмәнең изгелеге хакында бердәм фикергә килгән. Хәзер ул мөселманнарны да, православие динендәгеләрне дә, мәҗүсиләрне дә бердәй үзенә тарта. Биредә берәүнең дә кайсы диндә булуын тикшермиләр, юмарт чишмә һәркайсының сусавын да баса, коендыра да, савыктыра да. Көндәлек «тузаннардан» арынгач, монда кешенең баш авыртуы бетә, уй-фикерләре тәртипкә килә.

«Изге чишмә»нең атеистлар өчен дә үз «бонусы» бар. Ачык һавадагы «спа-процедуралар»дан елның теләсә кайсы вакытында файдаланырга була.

«Изге чишмә»не табу бик ансат. «Әлмәт – Чаллы» юлыннан барганда Рус Акташына җитәр алдыннан уңга – Сарманга таба борылырга кирәк. Ямаш борылышыннан соң ике километр үткәч, «Изге чишмә» дигән күрсәткеч кирәкле урынга алып барып чыгар. Чишмәгә 72 басмасы булган баскыч алып килә.

100+ ОЗЫН ГОМЕРЛЕ БУЛУНЫҢ СЕРЕ

Бүген Татарстанда 100 яшькә җиткән һәм аннан да күбрәк гомер итүче 182 кеше бар. Ә менә Нәгыймулла Гәрәев белән Мәгъсүм Нуруллинның тормышында булган вакыйгалар ике-өч кеше гомеренә җитәр иде. Озак яшәүләренең сере нидә? Бу хакта сөйләүләрен без якташларыбызның үзләреннән үтендек:

1НЧЕ СЕР
Әлмәт районының Колшәрип авылында гомер итүче Нәгыймулла Гәрәй улы Гәрәев 18 сентябрьдә үзенең 100 яшьлеген билгеләп үтте.
Авылдашлары аның озын гомерле булуының сере бакчасында дип исәпли. Алмагач, карлыган үстерү белән генә чикләнми ул, Нәгыймулла абзый бакчасында алтын тамыр да, женьшень да бар, ә өендәге буфет киштәсендә һәрвакыт төрле үлән төнәтмәләре тезелеп тора. Әле ул безгә тагын бер серен ачты:

– Җан тынычлыгы кирәк. Аннары – күп эшләргә. Үзең һәм якыннарың белән килешеп яшәргә һәм Ходайга ышанырга.

2НЧЕ СЕР
Узган елның 22 декабрендә Әлмәт районының Елхово авылы халкы Мәгъсүм Гыйлаҗ улы Нуруллинның 100 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Ә бер айдан аңа 101 яшь тулачак! Мәгъсүм Гыйлаҗевич яшьләргә менә нинди киңәш бирә:

– Бөтенесенә – үзеңә дә, бүтәннәргә дә елмаеп, юмор белән карарга кирәк. Кабаланмыйча гына ашыгырга. Һәммә нәрсәнең чамасын белергә. Вәгъдә бирсәң, үтәргә. Сүз биреп тә, эшләмәсәң, гаебеңне тою хисе авыр чирдән дә яманрак була ул. Ачу тотмаска, рәнҗемәскә. Шулар арасында – бал, шоколад һәм коры җимешләр ашарга. Аракы эчмәскә, тәмәке тартмаска һәм, билгеле, Ходайга ышанырга.

Фото: Лилия Седельникова, Александр Эшкинин

PRESSA.RU

БӘХЕТЛЕЛӘР ЕЛЪЯЗМАСЫ:
НЕФТЬ ЭШЕНДӘ 60 ЕЛ

«Бала-чага гына әле сез!» – «Татнефть» ГАҖ Ветераннар советы рәисе, Татарстан Республикасы нефтьчеләре һәм газчыларының фәнни-техник җәмгыяте рәисе урынбасары Татьяна Игнатьева илле яшьлек хезмәттәшләренә, яратып, әнә шулай эндәшә.

– Өлкәнәйгән саен үзеңне иркенрәк хис итәсең, – ди ул. – 80 яшькә якынайганда минем теләсә кайсы өлкәдә сайлау мөмкинлегем 40 яшьлек чагымдагыга караганда күпкә зуррак.



Нефть минем өчен – тулы бер тормыш. Туган оям. Күпләр бу турыда хыяллана гына ала.

ЭШЕ ТУРЫНДА:
КАРТЛАР ГАСКӘРЕНЕҢ БАШКОМАНДУЮЩИЕ

– Бер җитәкче мине «Картлар гаскәренең башкомандующие» дип атады. Чыннан да шулай. Тик минә «картлар» сүзе безнең өчен борынга чиерткән кебек яңгырый. Әйе, чынбарлыктан качып булмый: билгеле бер яшьне узгач, күпләр бизәнүдән, биек үкчәле туфлиләр киеп, эшкә чабудан туктый... Тик пенсионерларга өйдә оныкларын гына карап утырырга димәгән бит. «Мин әле яши генә башладым дип әйтергә була – пенсиягә чыктым», – дип, почтальон Печкин бик шәп әйткән. Урта кул булып, дәшми-тынмый гына яшисе килми бит әле. «Татнефть» ветераннары советы шуның өчен төзелде дә. Әүвәлге хезмәттәшләребез өчен күп нәрсә эшли алабыз без. Безнең пенсионерлар файдаланылганнан соң чыгарып ташланган кирәксез йөктәй хис итмиләр үзләрен. Алар бүген дә вакыйгалар эчендә кайный. Бу традиция безнең өчен бик кадерле. Нефть эшендә 60 елга якын эшләгән кеше буларак әйтәм мин моны.

БАЛАЧАГЫ ТУРЫНДА:
ӨЛКӘН СТАЛИНГА — ЧӘЧӘКЛӘР

– Сугыш чоры баласы мин – шуннан барысы да аңлашыла торгандыр. Тормыш тугыз яшемнән сыный башлады – абыйларыбыз сеңелем белән икебезне Богырыслан балалар йортына илтеп тапшырды. Әти сугышта һәлак булган иде, әни авыр хезмәттән үлеп китте. Абыйларның башка чарасы калмагандыр инде. Берсе – студент, икенчесе – армиядә. Сугыш елларында балалар йортлары безнең кебекләр өчен үлемнән котылу чарасы иде. **«Сталин – совет балаларының иң яхшы дусты» дигән сүзне мин ихластан кабул итәм.** Бәлки, үзенең әтисез балачагын яхшы хәтерләгәнгәдер, ятимнәр һәм урам балалары өчен күп эшләде ул.

Беренче май бәйрәмнәренең берсендә безне, балалар йортында тәрбияләнүчеләрне, ил җитәкчеләренә чәчәкләр тапшырырга алып бардылар. Минем белән җитәкләшеп килгән малайга – Сталин, миңа Маленков эләкте.

ЯШЬЛЕГЕ ТУРЫНДА:
КЕЧЕ СТАЛИНГА — СӨТ

Алтмышынчы елда мин инде буй җиткән кыз идем. Бервакыт шулай Казанда яшәүче дус кызыма кунакка бардым. Һәм, ышанасызмы, Мәскәү районындагы ишегалларының берсендә Василий Сталинны очраттым. Әтисенә бик тә охшаган иде ул! Нәкъ өлкән Сталин кыяфәтендә эскәмиядә аягын аякка куеп утырып тора. Мин кыюсызлардан түгел, янына килеп, сүз каттым. Ә сөйләшерлек нәрсәләр бар иде! Хәтта уртак танышлар да бар булып чыкты. Минем аңа бик тә яхшылык эшлисем килде. Берәр ярдәм кирәкмиме, дип сорадым. Сөт сатып алып килүемне үтенде...

Ник гаделсез язмышка дучар булды икән ул? Еш кына минә шул сорау борчый. Минем өчен тормышта иң куркынычы – хыянәт. **Тарихыбыз турындагы «хәтерне җую»ны да мин хыянәт дип исәплим.**

ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК ТУРЫНДА:
ЧИГЕНЕРГӘ ИСӘП ЮК

– Бу монстр белән көрәштем, көрәшәм һәм көрәшәчәкмен. Сүз дә юк, бик авыр. Әмма 45 мең кешедән торган пенсионерлар армиясе сиңа карап тора икән, башка юл юк.

Кем дә булса янына ярдәм сорап килмәгән көн бар микән? Дөрес, ветераннарны урманга чәй үләннәре җыярга алып чыгу яисә алар белән дельфинарий яки берәр музейга экскурсия ясау күпкә күңеллерәк, тик кырыс көнкүрешкә күз йомып булмый шул. Бер ветераныбыз исемена килгән торак-коммуналь хезмәткә түләү кәгазендә, гомуми торак мәйданы исәбеннән чыгып, ишек алдын җыештырган өчен дә бәя язганнар. Ә ул берничә ел инде урын өстендә ята. Бу хәл тәмам чыгырымнан чыгарды, һәм мин торак-коммуналь хуҗалык белән чын-чынлап көрәш башладым. Ни белән бетәр, белмим, шулай да чигенергә исәп юк.

ХЫЯЛЛАР ТУРЫНДА:
АЛАР ТОРМЫШКА АШТЫ

– Дөресен әйткәндә, миңа тормышта гел уңай килеп торды. Сабый чагым балалар йортында узса да, гади киемнәрдән генә йөрсәм дә, талонга алып ашаган чаклар күп булса да, рухи хыялларым тормышка ашты. Яраткан кешем белән гомер иттем, әни булу сөенечен, дуслык бәхетен татыдым. Ходайга шөкер, әлегә чаклы яраткан һәм кешеләргә игелек китерә торган эшем бар. **Ә нефть минем өчен – тулы бер тормыш. Туган оям. Күпләр бу турыда хыяллана гына ала.** Дөрес, күпме әтәчләнсәм дә, яшь үзенекен итә. Һәр иртәне мин шундый сүзләр белән башлыйм: «Кәефең начар булырга тиеш түгел, елмай әле, Таня!»

КҮҢЕЛ КИҢЛЕГЕ ТУРЫНДА:
ЯНКИЛАРГА ДА ОШАДЫ

– Билгеле, бу кадәр күп еллар эшләгәч, алган медальләрем, грамоталарым һәм башка бүләкләрем дә шактый. Шулай да партия өлкә комитетының «Америка социалист-нефтьчеләре делегациясен ТАССР территориясендә кабул итүне оештыруда ярдәм иткән өчен» бирелгән Рәхмәт хаты аеруча нык истә калды. Янкиларга минем аларны кабул итүем бик ошаган, күрәсең, күрше Башкортостанда йөргән чакларында да алар миңа: «Тания, сезгә кире кайтсак буламы?» – дип, гел шалтыратып тордылар.

PRESSA.RU

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

МАМАДЫШ: ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

Ялтыравыклы журнал битләреннән яисә күптән түгел генә шул якларда йөреп кайткан дустыңның айфоныннан дөньяның төрле кыйтгаларында төшерелгән фотосурәтләрне карагач, үзеңнең бер мәртәбә дә анда булмавыңа үкенеп, ә кайберләренә беркайчан да бара алмаячагыңны уйлап, уфтанып куясың. Дөнья искиткеч зур бит...

Ә шул ук вакытта, дөньяның бөтенләй башка бер почмагында, әйтик, Париждагы Эйфель манарасын күзәтеп басып торган кеше дә нәкъ шуңа охшаш хисләр кичерергә, мәсәлән, безнең Мамадыш якларын чагылдырган фотографияләргә карап, шулай ук биредәге матурлыкны күрә алмавына уфтанырга мөмкин бит. Ә бәлки ул тиз генә чемоданнарын тутырып,үзеннән ерак провинциаль матурлыкны үз күзләре белән күрер өчен юлга да кузгалыр.

– Матурлык ул – күрә белгән кешенең күзләрендә, – дип, үз фикере белән уртаклаша фотографыбыз Ната Смирнова. Ә без ул арада компьютер экранындагы Мамадышның күзге күренешләре белән хозурланабыз, гаҗәеп төбәк миләш тәлгәшләре арасыннан, чын могҗизадай, бик матур булып балкып тора!

– Ни өчен тагын Мамадыш? – дип сорар нәзберек укучыбыз.

Чөнки моннан Парижга кадәр барлыгы 3784 км – моны мамадышлылар үлчәгәннәр, исәпләгәннәр һәм җирле архитектурада да, шулай ук шәһәрнең эчке өлешен бизәүдә дә мәңгеләштереп үк куйганнар.

Ә җитдирәк итеп әйтсәк, җир йөзендәге иң матур урынны – якын кешеләрең гомер иткән, үз диварларың, диваның булган һәм тәрәзәдән бүген яр буенда туй барган Нократны гәүдәләндергән туган йортны бернинди Париж да алмаштыра алмый.

Фото: Ната Смирнова

МАМАДЫШ: КАРА ӘЛЕ, СИН ЯШИ ТОРГАН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

PRESSA.RU



ПАРИЖ 3784 КМ

PRESSA.RU



PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
Журнал
ТАТАРСТАН
Татарстан
ТАТАРСТАН

УТЫРЫП ТУТЫРМА ТУТЫРДЫМ...

XXI гасыр – мода һәм стиль заманы. Һәркем трендта булырга, свитшот киеп, кэжуал стилендә йөрергә тырыша. Гәрчә сүз гадәти фуфайка һәм джинс чалбар турында барса да. Хәер, нәрсә соң ул мода? Үткәннәрне искә төшерү һәм әйләнеп кайткан ретро әйберләргә заманча исем бирү, нигездә. Исем дигәннән, яшь әниләр хәзер балаларына Кәрим, Асылбикә, Вафирә, Гыйззәтдин дип кушалар. Шулай ук мода, ләкин миңа мондый күренеш ошый. Исемнәрдә без татарлыгыбызга кайтабыз кебек, ә аш-су өлкәсендә дә шулаймы соң?Дөрес туклану идеясен алга сөреп, барыбыз да брокколи ашарга күчмәгәнбезме икән әле?

Автор:
Айсылу Хаҗиева

БОРЫНГЫ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРНЕҢ ЯҢАРЫШЫ

Тагын бер кат китапларны кулга алып, тарих белән танышып, татар халык ашларын искә төшерик. Татарлар күбесенчә ит ризыкларына өстенлек биргәннәр, «чәй өстәлен» мулдан әзерләгәннәр, дигән мәгълүматны да очратырга була. «Ил-көннәр тыныч булмаганга күрә, алар хәстәрен алдан күреп, киләсе көннәргә дә нык-лап әзерләнгәннәр. Мәсәлән, озак бозылмый, салкыннарда җылыта, аз күләмдә ашап та, туклык хисе бирә торган ризык – тутырма бик популяр булган», – дигән фикерләрне дә еш ишетергә туры килә. Безнең заман теленә күчерсәк, бабаларыбыз хәзер бик популяр булган колбаса ясаганнар. Әүвәлге чор белән бүгенгесен чагыштырып карасак, шуны искәртә алабыз: димәк ки, борынгыдан килгән гореф-гадәтләребез сакланган, үзгәрсә дә, онытылмаган. Горурлык түгелмени бу?!

Ә менә үзгәрешләр турында сөйләшәбез икән, монда инде төгәллек кертү кирәктер. Тутырма мал эчәгесеннән ясала. Ләкин сарыкныкымы, сыерныкымы, әллә атныкымы? Татар халкының тормышын тасвирлаучы китапларга нигезләнсәк, алар болай яза: «Татарларның яраткан ите сарыкныкы булган, икенче урында исә сыер һәм ат ите торган». Шунда ук китап мишәрләрне дә аерып күрсәтә. Алар ат итенә өстенлек биргәннәр, ди. Менә сиңа, мә! Мишәрләр бит бүген дә «мишәрлекләре» белән горурланалар. Тикшереп карасаң, бәлки ашаулары да шул чордагычадыр әле, дип, чыгышы белән Нурлат районы Яңа Әлмәт авылыннан булган мишәр апае белән очрашып, тутырма әзерләргә булдык.

ПЕШЕРГӘННӘН СОҢ СӨЙЛӘШЕРГӘ ЯРЫЙ...

Нурлат районында булганым бар. Зур, чиста, матур як, ләкин гаҗәпләндергәне шул булды: кибет-кафеларда русча сөйләшеп каршылап, русча сөйләшеп озатып калганнар иде. Бу юлы без Нурлатка кайтып тормадык, ә хуҗабикә белән Яр Чаллы шәһәрендә очраштык. Шуны әйтергә кирәк: ашарга пешергәндә хуҗабикәләребез гадәттә бик җитди була торганнар иде, ә Гөлсинә апа белән көлә-көлә эшләр катты.

Шула итеп, «Татарстан» журналы өчен тутырманы бу юлы махсус Гөлсинә Нурхода кызы Баһаветдинова пешерәчәк. Чаллыга килеп төпләнгәненә дә биш былтыр, ләкин бу хакта – бераз соңрак. Өйләренә килеп керүгә, елмаеп, мәзәкләр сөйләп каршы алды Гөлсинә апа. Аш бүлмәсенә узуга, исем китте. Гадәттә, безнең хуҗабикәләребез кирәк-яракларны алдан әзерләп куялар, ә Гөлсинә апа, аларны уздырып, тәлинкәләрен дә, кәстрүлләрен дә әзерләгән, хәтта ки, ашарга пешереп бетергәннән соң, коймак белән чәй эчәрбез, дип, камырын да туглап куйган иде. «Әһә, – дип уйлап куйдым эчемнән генә, – мишәрләрне кызу халык диләр, чынлап та шулай икән». Бу юлы эшнең барышы да башка юл белән китте. Гөлсинә апа: «Иң элек пешерик әле, аннары сорарсың, сөйләрмен», – диде.

Керә-керешкә күзем өстәлгә төште: сарык эч-башларын күреп бераз гаҗәпләндем. Дәү әнием элегрәк безгә дә тутырма пешереп ашата иде. Ләкин аның составы башкачарак иде кебек. Түзә алмадым, сорадым: «Нурлат якларында шулай пешерәләрмени?» Гөлсинә апабыз: «Бөтен Нурлат районы өчен сөйли алмыйм, ә Яңа Әлмәт авылында шулай эшлиләр, ничек ашап үстем, шулай пешереп күрсәтәм», – диде. Мин исә бер җөмләдән ике нәтиҗә ясадым: 1) рецепт күптәннән барлыкка килгән һәм үзгәрмәгән; 2) Нурлат районында тутырма пешерүнең башка ысуллары да булуы бик мөмкин.

КЫЗУ ХАЛЫК, ЯКИ МИШӘРЧӘ ЫСУЛ

Өстәлебезгә әйләнеп кайтыйк: бәрәңге, дәфнә яфраклары, суган, дөге, эч майлары һәм ит кирәк булачак безгә. Шуларның барысын да иттарткычтан чыгарабыз. Сүз уңаеннан, элек иттарткычлар булмау сәбәпле, эчлек составына керүче ингредиентларны вак итеп тураганнар. Соңыннан барысын да яхшылап бутап, тәменчә тоз-борыч салып, кайнаган су өстәп, әйбәтләп болгатабыз. Шуннан соң гына эчәгегә эчлекне тутырабыз.

Фото: Айсылу Хаҗиева

PRESSA.RU

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

ГӨЛСИНӘ БАҺАВЕТДИНОВА РЕЦЕПТЫ:

Эчлек өчен:
1. 1 баш суган
2. 1 йөрәк
3. 1 пар бөер
4. 250 г бавыр
5. 1 бәрәңге
6. 300 г ит
7. 500 мл кайнаган су

ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ РЕЦЕПТЫ:

1 кг үпкә-бавыр, йөрәккә:
1. 100 г дөге яисә 120 г карабодай ярмасы
2. 1 йомырка
3. 100 г суган
4. 300–400 г сөт яки шулпа
5. Тәменчә тоз, борыч

Без тутырманы сарык эчәгесеннән әзерләдек. Әлбәттә инде, йөрәк, бавырлары да – сарыкныкы, ә малыбыз Корбан бәйрәменә чалынган булган. Шуңа да тутырманың тәмле булачагында беркем дә шикләнмәде. Эчәкнең бер башын җеп белән ныклап бәйлибез, икенче башына бүрәнкә куеп, эчлекне чүмеч белән агызабыз. Эчлек эчәгене тулысынча тутырырга тиеш түгел. Бәйлисе башы белән эчлек арасында урын калырга тиеш, чөнки пешкән вакытта эчлекнең күләме арта һәм ул артык тыгыз булган очракта, тутырмабыз шартларга да мөмкин.

Эчәгене тутыра башлаганда, Гөлсинә апабыз шаян тон белән: «Хәзер мишәрчә ысул белән тутырачакбыз», – диде дә, әзерләп куйган бүрәнкәне алып куеп, башы киселгән пластик шешә чыгарды. «Бүрәнкә – матурлык өчен генә. Фотога төшергәнсеңдер ич? Шулай булгач, хәзер ничек уңайлы, шулай эшлибез инде. Яңа Әлмәттә барысы да шулай итә. Тутырманы, гадәттә, үзең генә пешерәсең. Булышырга кеше юк, шуңа да бүрәнкәгә эчлек салу – артык мәшәкать, чөнки бүрәнкәнең «авызы» тыгыла, эчлек үтми, бәйләргә дә җайсызрак. Ә пластик шешәнең «авызы» да зур, тотарга да, бәйләргә дә җайлы», – дип, рәхәтләнеп көлеп җибәрә Гөлсинә апа. Чынлап та, эчлекне санаулы секундларда тутырып бетердек, эш күзгә күренеп кызуланды. «Нишлисең, кызу халык», – дип уйлап куйдым мин тагын бер мәртәбә.

Әзер эчәкләрне кайнап чыккан тозлы суга салып, 1,5 сәгать пешерәбез. 40 минут узгач, эчәкләрне (берьюлы берничәне әзерләргә булдык) энә белән берничә урыннан тишәбез. Бу – шартлаудан коткаручы тагын бер ысул.

ИКЕ МИШӘР БЕРГӘ ТУРЫ КИЛСӘ...

Әйткәнемчә, Гөлсинә апа безне коймак камыры белән каршы алды. Тутырманы кәстрүлгә озаткач ук, таба исе чыгарырга тотынды. «Әйдә, сора! Сөйлим», – ди үзе. Билгеле, беренче сорау мондый булды: «Сез «мишәрчә ысул», «без мишәрләр» дип еш кабатлыйсыз, мишәр булуыгыз белән горурлануыгыз әллә каян сизелә. Татар белән мишәр шулай ук нык аерыламы әллә?» – дим. Гөлсинә апа кинәнеп-рәхәтләнеп сөйләп китте...

– 1973 елда Югары Осланга икътисадчылар курсына укырга килдем. Шунда кызлар белән танышып киттек. «Гөлсинә, син мишәрме әллә?» – дип сорадылар болар миннән, танышуга ук. Мин исә, гаҗәпләнеп тә, аптырап та: «Ю-у-ук, мин мишәр ТЕГЕЛ!» – дип җавап бирдем. Тегеләр исә шаркылдап көлделәр. Шулай итеп 1973нче елда гына мин үземнең мишәр икәнемне белдем.

Уйлап карасаң, чынлап та шулай бит. Без үзебез: «Кара әле, синдә мишәр каны ага бугай», «Сөйләмеңдә мишәрлек сизелә» кебек сүзләрне уйлап та тормыйча ычкындырабыз.

Терлекнең үпкә-бавырын, йөрәген эшкәрткәч, вак кына турап, суган кушып, иттарткычтан чыгаралар. Тоз, борыч сибеп, йомырка сытып, яхшылап болгаталар, аннары сөт яисә салкын шулпа, дөге яки карабодай ярмасы өстиләр дә, болгатып, эчәккә тутыралар, эчәкнең башларын бәйлиләр. Бу катнашма сыек булырга тиеш. Аны бавыр белән ярмадан гына әзерләргә мөмкин. Тутырманы эчәклеккә тутыралар. Эшкәртелгән эчәкнең өчтән ике өлешенә шул катнашманы тутыралар да ачык башын бәйләп куялар. Катнашманы эчәк тулганчы салырга ярамый, чөнки пешкән ярма бүртә һәм тутырма ярылып китәргә мөмкин. Әзер тутырманы уклауга бәйлиләр дә кайнап торган тозлы сулы кәстрүлгә батыралар һәм 30-40 минут пешерәләр. Табынга кайнар килеш чыгаралар. Пешкән тутырманы турап та, бөтен килеш тә майлы табада ут өстендә яисә духовкада кыздырып алырга була.

– Нәрсә генә дип әйтим соң инде үзеңә? Тупый – башлык, нүеш – почмак... Шулайрак сөйләшәбез инде. Безнең сөйләм, анысы, аерылып тора... Әмма мишәр булсам да, телевизордагы әдәби сөйләмне бозып сөйләүче алып баручылардан хата табып утырам әле менә!

Гел елмаеп, көлеп кенә торучы Гөлсинә апабызның тормышында сынаулар күп булган. Авылдан шәһәргә килеп төпләнү тарихы да күңеллеләрдән түгел. Яңа Әлмәттә яшәгән вакытта аягын сындыра ул. Табибларның диагнозы катгый була: йөрмәячәксең. Шул вакытта Гөлсинә апаны күрше хатыны Чаллыга алып килә. «Монда табиблар башка, аякка бастырырлар үзеңне», – дип ышандыра. Гөлсинә апа әллә чынлап та ышанып, әллә мондый хәлтендә авылда калырга куркып, Чаллыга күчենә. Мондагы табиблар аны чынлап та аякка бастыралар. Соңыннан эшкә урнашып, шәһәрдә генә кала ул. Бер көнне «пятачок»та Гөлсинә ханым үзенең булачак ирен – Әхәт абыйны очрата. Шулай итеп, яшьләр шәһәрендә очрашып, Нурлат мишәре Гөлсинә апа белән Буа мишәре Әхәт абый никахлашалар. Ике ул үстерәләр, бүгенге көндә инде 3 оныкның зур әнисе Гөлсинә апа. «Мишәрләр алар малай алып кайта!» – дип шаяртып та ала хуҗабикәбез.

БЕРОЧТАН ТАВЫК ТА ТУТЫРДЫК!

«Гадәттә, килен булып төшкәч, кайнана ни дә булса пешертеп карый. Сезгә бу эләктеме?» – дим. «Юк, туйның икенче көнендә үк эшкә чыгып киттек. Ашарга пешерергә вакыт юк иде. Алай да кайнанам бәрәңге кыстыбые пешерергә өйрәтте. Бездә кыстыбыйны тары ярмасы белән генә пешерәләр иде», – диде хуҗабикәбез.

Белә идегезме икән, кыстыбыйның борынгы, оригиналь вариантында нәкъ менә тары ярмасы кулланыла, ләкин андыйны пешерүчеләр инде юктыр, дип уйлый идем. Менә Гөлсинә апаны очраттым! Тутырманы да сарык эчәгесеннән пешерәләр, кыстыбыйны да борынгыча әзерлиләр икән Нурлат якларында.

P.S. Элек яратып пешерелгән милли ризыклар бүген онытыла бара, алар урынына брокколи, шпинат ише «сәламәтләре» килә. Ләкин туклыклы һәм тәмле ашарга яратучылар һәрвакытта да булачак. Шундыйлар өчен без, чираттагы тәмле татар халык ашлары рецептын эзләп, һәр айда юлга кузгалабыз. ■

1. Иттарткычтан чыгарабыз!

2. Дөге кушып, тәмләткечләр өстибез!

3. Су салып, болгатабыз!

4. Эчәккә тутырабыз!

5. Тутырып бетердек!

6. Пешерәбез! Энә белән тишәбез!

7. Табынга чыгарырга әзер!

8. Бизәп чыгарабыз!

Табыннарыгыз мул булсын!

PRESSA.RU

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Кызылкүлдә балык **НИ ӨЧЕН** беткән

Карганың каргалары **КАЯ** киткән

Җүкәтау **НИНДИ** серләр саклый

Балалар **НИ ӨЧЕН** үлә

Үзбәкстан татарлары **НИЧЕК** яши

«Восток-Запад» сериалы йолдызы **НИГӘ** Казанга килгән

Резидә Галимова **НИК** Мәскәүдә калмаган

НИ ӨЧЕН без төньякка юл тоттык

Сертотмас хатын **КАЙДА** яшәгән

‹ КЫЗЫЛКҮЛ КАРГА ›

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлады. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.

Мамадыш районы. Түбән Әрнәш авылы.

PRESSA.RU

ТӨПСЕЗ КҮЛ

Биектау районындагы Кызылкүл авылында күл, дөрестән дә, бар. Заманында балыгы мыжлап торган, диләр. Бүген инде ул саегып беткән һәм камыш баскан су буенда кармак тотып утыручылар сирәк. Авылдагы иллеләп хуҗалыкның күбесендә «дачниклар» яши. Алар, кошлар сыман, көннәр җылыткач, авылга кайта да, суыта башлагач – кире китә. Кызылкүлдә туып-үсеп, нигез

Автор:
Линар Закиров

КҮЛНЕ КАРАВЫЛЛАГАННАР

Кызылкүлне авыл уртасындагы дамба икегә бүлә. Һәр ике як та аерым хуҗалык булып яши, теге як белән бу як ярыша-ярыша яши. Бу авылда хәтта зиратлар да икәү, һәр якның – үзенеке.

Илдар абый Мифтахов – авылга килеп кергән як старостасы. Аның сөйләвенчә, 1926 елда авылның икенче ягына Коркачык белән Урмат авылы кешеләре килеп, «Кызыл көч» колхозын оештыра. Ә Илдар абый яши торган якка 1927 елда сасмаклылар, ягъни Сасмак авылыннан бер төркем кеше килеп утыра да «Яңа көч» хуҗалыгына нигез сала.

– Бер хәлле кеше өч ел дәвамында ат белән балчык ташыттырып, ике арада биек дамба төзеттерә. Күл буена ике яктан да картлар җыелып, авылга бер исем кушыйк, диешәләр. Су төбендә кызыл балчык булганга, авылны Кызылкүл дип атыйлар...

Безнең күл якын-тирәдә бик данлыклы, төбенә җитеп булмый иде. Ә балыгы-ы-ы... Колхоз чорында анда каравылчы утыртып, балыкны кармак белән генә тотарга рөхсәт итәләр иде. Төнлә ятьмә белән урлап кына тоткаладылар, – дип сөйләде Илдар абый.

Аның әйтүенчә, элек бал һәм икмәк белән беррәттән, балыкны да хезмәт хакы итеп биргәннәр. Көз көне Камай авылыннан көймә алып килеп, ятьмәне аркылы салып, балыкны колга белән дөмбердәтә-дөмбердәтә куып тотканнар. Аннары барысын бергә амбарга алып менеп бушатканнар да эшчеләргә таратканнар. Илдар абый әйтүенчә, Урмат авылы урман каравылчысы күлнең бөялгән урынын махсус ерганга, сулык саегып беткән.

КЫЗЛАР КАЗ ЙОЛКЫЙ, ЕГЕТЛӘР БЕРНИ ЭШЛӘМИ

Илдар абый 1941 елда шушында туа. Йортлары авыл читендә урнашкан була.

– Элек халык бәйрәмнәрдә бер-берсенә кунакка йөреште, яшьләр сөрән сала идек. Ул чакта әле аракы юк, бал эчеп, гармунга кушылып җырлап, егетләр кызларны кунакка чакыра. Аннары, урам әйләнеп, клубка чыгып китәләр иде. Сөрән салудан соң каз өмәсе башлана. Көндез кызлар каз йолкый, әмма өмәгә егетләрне чакырмыйлар. Алар үзләре килеп керә. Әбизәтелне, киләләр, – дип сөйли әңгәмәдәшем.

– Кызлар көне буе каз йолкыганда, егетләр нишли иде соң? – дим.

– Бернәрсә эшләми, кич белән ашарга гына килә, – дип көлдерде Илдар абый. – Иртәгә Сабантуй дигән көнне, ат җигеп, гармун уйнатып, өй саен яулык та җыя идек. Бездә аны «чүпрәк җыю» дип әйтәләр иде.

ХӨСӘЕН ӨЙЛӘНГӘН

Мифтаховлар йортында ике песи яши. Хөсәен исемлесе аш бүлмәсендә йоклап ятса, Томан атлысы алгы якта диван өстендә сөйләшүебезне тыңлап ятты. Кызыксынуданмы икән, башка төрле сәбәптәнме – күзләре ут булып янды.

– Бер ел элек иртән песи кычкырган тавышка уянып киттем. Урамга чыгып карасам, безнеке тагын бер песи ияртеп кайткан да, икәү бергә мияулыйлар. Шулчак хатыныма: «Тор әле, безнең Хөсәен өйләнгән», – дим. «Нәрсә сөйлисең син, өйгә кертә күрмә», – диде. Шул арада ят песи өйгә атылып килеп тә керде. Ана түгел, ата мәче булып чыкты. Ул чакта кечкенә иде әле. Исемен үзем куштым. Авыл кешеләре аны әнисе белән каенлыкта күргән булган, – диде Илдар Мифтахов.

– Кулыгыздагы «ИЛЯ» дигән татуировка нәрсә дигәнне аңлата? – дип сорыйм.

– И-и, дөрес язылмаган ул. Авылда Коля дигән тимерче малай бар иде.

Автор фотолары

Исемеңне русча язып бирәм, дип, Илья урынына Иля, дигән. Нечкәлек билгесен төшереп калдырган, – ди әңгәмәдәшем.

1959 елда Мифтаховлар йорт җиткереп куя. Өй ашы уздырып, берничә көн үткәч, ут чыгып, йорт янып бетә.

– Июльнең 24е иде ул, бик эссе көн. Мин су буена төшкәч, авылга Казаннан кайткан кунакларның малайлары Таһир мине табып, «Абый-й, төте-е-ен» дип кычкыра. Килеп җитсәм, салам түбәле йорт өстендә «пәри туе» күтәрелә. Капкага йөгереп барып бәрелдем дә, йозак ватылып китте...

Абыйның армиягә киткән чагы. Әни эштә. Урак өсте бит. Элек бер көн эшкә чыкмасаң, бригадир биш көнлек хезмәт хакын кисә дә куя. Авылдан бер гаилә Коркачык станциясенә күченеп, авылда иске өйләре шул килеш калган иде. Алардан рөхсәт сорап, шунда төшеп урнаштык. Яңа елдан соң, үзебезгә өй җиткереп куйдык, – диде Илдар абый.

Ноябрь уртасында аңа 75 яшь тулды, ә тиздән хатыны Тәкъзимә апа 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк. Олы яшьтә булсалар да, абзарларында сарык бәэлдәве, тавык кыткылдавы тынып тормый. Этләре дә бертуктаусыз өреп тора.

БАЛ ЯШӘТӘ

Васил абый Газыймов – Кызылкүлнең икенче ягы старостасы. Декабрьдә 82 яшь тулса да, һаман машинада җилдерә. Әкрен йөрим, шуңа куркытмый, ди үзе.

– Ямәшкә (күрше Ямаширмә авылын җирле халык шулай дип атый – ред.) – кибеткә, Чыпчыкка бульнискә генә төшәм. Тегендә-монда барган юк, – ди ул.

Васил абый 1951 елдан трактор йөртә. Башта – ДТ-54, аннары ДТ-74 белән ДТ-75тә эшли. Пенсиядән соң да сигез ел трактордан аерыла алмый ул. Җанын-тәнен биреп эшләгәне өчен, Кызылкүлнең данлыклы тракторчысы Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Октябрь Революциясе орденнарына ия була. Әмма югары дәүләт бүләкләре янгында көлгә кала.

– Комбайнда озак эшләдем. Аңарда кызыграк, икмәк җыясың ич. Әле хәзер дә йөртеп карарга кызыгам, көчем генә юк. 50 яшемдә, машина йөртүчегә укып, машинага утырдым. «Волга» белән урманга барып, ауган агачларны трос белән тарттырып алып төшә идем дә пычкы белән кисә идем. Берсендә машинаны «скоростька» салырга онытып, ул кызымның машинасына килеп бәрелде. Шуннан соң «Волга»ны Арчага утильгә тапшырдык. Хәзер инде утынны трактор арбасы белән алып төшәбез, урман якын гына бит, – дип сөйләде ул.

Васил абый күл турындагы хатирәләре белән дә уртаклашты.

– Элек ул тирән, ат дилбегәсе төбенә кадәр җитми иде. Кызылканат зерә күп, артыгын Коркачыкка төшеп сата идек. Бу күл саега башлагач, аннан 250 метр читтәрәк икенче бер күл бөяп куйдым, бульдозерда эшли идем, – диде ул.

Авыл карты җәй көне балалары-оныклары белән умарта карый, үзенең ун баш умартасы бар. Унбиш ел буе ул колхозның «бал»лы эшчәнлеге өчен җавап бирә.

– 50 яшьтә йөрәк борчый башлагач, күрше авылдан бер умартачы: «Васил, бал аша да бал аша», – диде. Дусларымның күбесе үлеп бетте, ә мин һаман яшим. Умарталарны яратып карыйм, Аллаһы Тәгалә мине шуның өчен яшәтә торгандыр. Чәйне балсыз эчкәнем юк, – диде Васил абый.

Аның оныклары шулкадәр күп, хәтта төгәл санын да белми.

– Балалары җыелса, Васил абыйның йорт турысында тезелеп баскан машина арасыннан узып китеп булмый, – дип көлде безнең белән йөргән Иске Казан җирлеге башлыгы Гөлнара Закирова.

Васил абыйның бакчасында балан да үсә. Бер тәлгәше өстәлдә укылып беткән газета битендә кып-кызыл булып күз явын алып ята иде.

– Быел балан галәмәт күп, җыелып бетмәгән әле. Аның суы бик файдалы, диләр, – диде староста.

«СЕҢЛЕМ, КАРАП КЫНА ТОР»

Авыл халкы, ике як арасында бернинди ярыш юк, дисә дә, Иске Казан җирлеге башлыгы Гөлнара Закирова киресен сөйләде.

– Җирлеккә кергән башка авылларда өмәләр, башка төрле чаралар үткәрергә үзем булышсам, Кызылкүлдә әйткәнемне, килгәнемне көтеп тормыйча, үзләре эшкә тотыналар. Сельсоветка гына салынып тормыйча, авылны үстерү өчен кирәк-яракка акчаларын да җәлләмиләр. Берсендә зират өмәсенә самавыр белән чәй, пироглар алып мендем. Әйдәгез, булышыйм, дигәч, «Сеңлем, карап кына тор, үзебез эшлибез», – диделәр. Кызылкүллеләрне, менә нинди уңган, дип, коркачыкларга да үрнәк итеп куям. Авылда ике як бер-берсеннән үрнәк ала. Теге якта берәр эш башкарылса, берничә көннән бу яклар да, җыелышып, авылны матурлау хәстәрен күрә. Т

PRESSA.RU

КАРГАДА КАРГА ЮК

Әлки төбәгендәге Карга авылы турында беренче рәсми мәгълүмат XVII гасырдан күренә башлый. Ул чорда унлап хуҗалык теркәлсә, хәзер авылда 142 йортта 432 кеше гомер кичерә. Авыл уртасыннан мул сулы Актай елгасы ага, басуларында иген гөрләп үсә, болыннарын көтүлекләр иңли. Тәүлекнең биш вакытында намазга чакырып азан тавышы ишетелә.

Автор:
Гөлүсә Закирова

331 ЕЛ ЭЛЕК...

Карга авылының барлыкка килү вакыты төгәл билгеле түгел. XVII гасыр документларында Карга «Актай елгасының югарырак ярындагы Яңа Ахтачы», «Югары Ахтачы, шул ук Карга» кебек исемнәр белән искә алына. Беренче кешеләре турында менә ниләр билгеле: 1685 елда Актай елгасының Чаллы һәм Ромодан елгалары койган түбән агымы арасындагы уң ярындагы җирләре кенәз Абдул Яушев һәм 5 йомышлы морзага бүләк итеп бирелә.

1716-1717 елларда Каргада 24 хуҗалыкта 284 йомышлы татар яшәгән. Петр I вакытындагы социаль-икътисадый үзгәртеп корулар алар тормышына да үзгәрешләр кертә. 1718 елның 31 гыйнварында дөнья күргән Указ нигезендә, йомышлы татарлар флотка кораблар төзү өчен урман кисү эшенә җәлеп ителә. Моның өчен, әлбәттә, хезмәт хакы түләнми, аларны мәҗбүр итәләр. Хөкүмәт җан башыннан түләүләр кертә, моны урман кисеп кенә түләп була. Кичәге хәрбиләр (йомышлы татарларның моңарчы дәрәҗәләре югарырак була!) шул рәвешле лашманга әйләнә. Элеккеге вәкаләтләр бетерелгәч, йомышлы татарлар дәүләт крестьяннары хәленә төшә. 1722 елда Каспий буе җирләрен кулга төшерү белән, Сулак, Баку һәм башка урыннарга төрле эшләргә Казан губернасыннан 5 мең татар чакырыла. 1723 елда Каргадан 8 кеше Бакуга җибәрелә. Күченүләр шактый күзәтелә бу чорда. 1737 елда Карга авылыннан да 5 йомышлы татар Иске Ибрайга юл ала, 1747 елдагы II ревизия вакытында бу авылда Каргадан күченеп килүчеләр инде 25кә җитә.

КАРГА АТАМАСЫ

Авыл атамасы күпләрдә кызыксыну уята. Җитмәсә, Россиянең кайбер төбәкләрендә шул ук исемдәге торак пунктлар да бар. Мәсәлән, Архангельск өлкәсендә шул исемдәге шәһәр, Мәскәүнең төньягында – Медведково бистәсендә Каргополь исемле урам да бар. Бәлки, аларга нигез салучы Әлки районындагы Карга авылы мишәрләре булгандыр? Бу фикер язучы-эзтабар Геннадий Панинны да безнең якларга китерә. «Каргополь» атамасы буенча шактый гына бәхәсләштек без аның белән. «Финнарның «каркун пуоли» – «овсяная сторона» яки «каргун пуоли» – «медвежья сторона» дигән сүзләреннән «Каргополь» килеп чыга, – ди ул. – Грекларның «карго-полис» – «кораблар пристане» сүзеннән дә алынырга мөмкин. Шәһәр тирәсендә каргалар күп, «Каргополь – каргалар кыры» дип тә аңларга мөмкин. «Эрзя телендә «карго» – «торна» дигәнне аңлата.

Фотолар автордан алынды

Ә «пеле» сүзе – «яртысы, шул як» мәгънәсендә. Киек Каз Юлы – «каргонь ки» дип йөртелә».

Авыл исеме хакында Карга халкы хәтерендә бердәнбер риваять сакланып калган: «Борынгы заманда кешеләр, бераз калкурак урынны сайлап, шунда килеп төпләнә башлаган, авыл барлыкка килгән. Ләкин аның исеме булмаган. Уйлашканнар да мондый карарга килгәннәр, имеш. Бер ялгыз агач тирәсенә җыелырга һәм шул агачка иң беренче нинди кош килеп куна, авылны шул кош исеме белән атарга. Халык җыелган, аларны көттереп тормыйча, агачка карга килеп кунган, имеш. Шулай итеп, авыл Карга исемен йөртә башлаган...» Авылны икегә бүлеп, Актай елгасы ага. Читтәрәк Сарсаз елгасы, Аръяк елгасы, Үләт елгасы, Тәкә елгасы, Тирән елга, Алмагач елгасы, Бакый елгасы, Вәлит елгалары билгеле.

Карга авылы булгач, авылда каргалар күптер, диярләр. Әмма авыл тирәсендәге биек агачларны, берсен дә калдырмыйча, кисеп бетергәннәр. Элегрәк каргалар зиратта бик күп булган. Хәзер биредә бер генә биек агач та юк. Каргада карга да калмаган...



МӘХӘЛЛӘ

1885 елда Каргага имам-хатыйп булып Лаеш өязенең Казыл волосте Татар Казысы авылы крестьяны Шаһиҗиһан Шиһабетдинов билгеләнә. Гаять укымышлы, алдынгы карашлы кеше була ул. Матбугатта аның күренекле язучы Гаяз Исхакый белән дус булуы турында да мәгълүматлар бар. Бу мулланы искә алуның хикмәте шунда: ул кызыл комиссар Касыйм Туйбактинның әтисе дә. Карга авылында туып-үсеп, Тукай белән аралашып яшәгән, иҗат иткән, мөгаллим, язучы, җәмәгать эшлеклесе, Әстерхан Мөселман хәрби комиссариаты рәисе булган аның улы. Рәис булып эшләү дәверендә ул Мәскәүдән Әстерхан губернасының мәдәни ихтыяҗларын кәнәгатьләндерү өчен миллион ярым сум акча алуга ирешә. Бу акчага шәһәрдә һәм аның тирәләрендә кыска сроклы милли мәктәпләр ачыла. Наданлыкны бетерү өчен, илле урында кичке курслар, 25 районда халык китапханәсе оештырыла. Әстерханда укытучылар өчен махсус курслар ачыла. Үлеме дә үкенечле була Туйбактинның, гомере буе советлар өчен җан аткан комиссарны үзебезнекеләр үк кыйнап үтерә.

Октябрь түнтәрелешеннән соң озак та үтми, Карга мәчете манарасына да бау эләләр. Бу вакыйганы авыл аксакалы Габдулла абый Гафиятуллин үз күзләре белән күреп тора: «Зур калын арканнар белән бәйләделәр дә «Хабирун!!!» («Ха, берем!!!» мәгънәсендә) дип кычкыра-кычкыра сөйрәп төшерделәр», – ди. Аның чордашы Галимҗан абый Сафин, мәчет манарасын 1937 елларда кистеләр, дип искә ала: «Манарасы – бер якка, ае икенче якка мәтәлеп төште. Дәү әтием Галиәкбәр белән бергә мәчетнең мөнбәрен келәткә алып кайтып куйдык. Ә гөмбәзе зират йортына куелды. Мәчетнең ае Гөлсем апалар өен сүткәндә матчадан килеп чыкты. Бүген ул мәктәп музеенда саклана».

«ШҮРӘЛЕ КАРГАГАН АВЫЛ»

Карга тарихында тагын бер тетрәндергеч вакыйганың әледән-әле кабатланып торуына да игътибар иттек. Ул – авылның көчле янгыннар кичерүе. Янгыннардан каза күргән авылларны «Шүрәле каргаган авыл» дип тә йөртәләр. Имеш, берәү урман иясен рәнҗеткән дә, авылга аның рәнҗеше төшә икән...

PRESSA.RU

1859 елның 9 маендагы янгын авылга шактый зыян сала. Ялкын телләре, бер өйдән икенчесенә күчә-күчә, барлыгы 46 йортның башына җитә. Авылга килгән гомуми зыян 5812 сум көмеш белән бәяләнә. Бу хакта тарихи документлар да сакланып калган. XVIII гасыр ахырында Фатыйх Әмирханның әтисе Зариф ага биредә кызлар өчен мәдрәсә салдыра. Авыл халкы белем учагының да янып көлгә әйләнүе хакында әрнеп сөйли. 1920 елгы ачлык чорында исә түбән очта 70–80 йорт күз ачып йомганчы янып бетә. Эссе, коры җәй килә, бөтен җирне кояш көйдерә, су юк. Җитмәсә, ураза ае. Халык кичен кырдан кайтып, булган байлыктан ахшамга ризык әзерли. Әнә шулчакта бер өйдә очкын чыгып, салам түбәләрне бер-бер артлы ялкын чорнап ала башлый. Чулпания апа Фәттахованың бабасы ишек алдында ат арбасында йокларга яткан була, бу хәлләрне оныкларына гыйбрәт өчен сөйли. Бисмиллаһ әйтеп, тәрәзәләрне намазлык белән каплап куя карт. Әллә өйдә Коръән булганга, әллә өй түбәсе салам урынына такта булганга, әллә башка сәбәп белән, гаилә учаклары – өйләре исән кала аларның.

70нче елларда түбән очта 5–6 йорт рәттән янып бетә. 2000 елда урта мәктәп янгын афәтенә дучар була. Ул бинада авыл тарихын ачкан мәктәп музее да, экспонатлары-ние белән көлгә әйләнеп, күккә оча.

«ИМАНЫҢНЫ ӘЙТӘ БАР»

1921 елгы ачлыкны каргалылар бик әрнеп искә ала. Һәрбер гаиләдә югалтулар булган, интегеп, бер телем ризыкка тилмереп вафат булучылар да шактый җыела. Әкълимә апа Хәмәтшина сөйләвенә караганда, халык этләргә кадәр суеп ашаган, сөякләр тарттырып, җан асрарга тырышкан, авылда тегe яки бу кеше турында «кергән бер хәерчене дә кире чыгармый икән» дигән коточкыч хәбәрләр йөргән. Бу хәбәрләрдән болай да өшегән күңел бөтенләй өметсезлеккә бирелгән. Авыл халкы кимегәннән-кимеп, кайсы җан биргән, кайсы ризык эзләп авылдан чыгып киткән. Үлгәннәрне күмәргә хәлләре дә булмаган хәтта. Атнага бер тапкыр Ромодан авылы руслары килеп, мәетләрне җыеп, бер чокырга күмә торган булган. «Нурхәмәт абый ат арбасына салып, мәетләрне идарә буена ташыган икән, – дип сөйли Чулпания апа Фәттахова. – Берьюлы Сәкинә исемле карчыкны илтә ул. Сизеп ала, карчыкның җаны чыкмаган әле. «Иманыңны әйтә-әйтә бар», – ди ул аңа. Тегесе: «Лә иләһе иллаллаһ», – дип иреннәрен кыймылдата...»

ҖИДЕ ЮЛ ЧАТЫНДА

«Кулак дигәнен мин болайрак аңлыйм, – дип сүз ала Галимҗан абый Сафин. – Кешеләр бер төрле генә түгел бит, кемдер эшләгән, берәз хәл җыйгач, малы, ашарга ризыгы барлыкка килгән. Ә кайберәүләр «алма пеш, авызга төш» дип кенә утырган. Бу тигезсезлекне тигезләргә кирәк булган – хәлленең малын алып, ярлыга өләшкәннәр. Йортларны да шул рәвешле эш яратмаган халыкка биргәннәр. Безнең авылда кулак дигән исем күтәрүчеләр – бай түгел, ә тырыш кешеләр генә булган ул».

Карга авылының репрессия җиле кагылган тагын бер каһарманын искә алырга хаклыбыз. Ул – Кыяметдин Мисбахов. Яшь комсомолны, партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, Тәтеш районына юллыйлар. Олы Тархан районының Бакырчы авылында мәктәп директоры булып эшли ул, аннан Тәтеш районына икенче секретарь итеп билгелиләр. Сугыш елларында Олы Тархан районының беренче секретаре булып эшли. Авыр чак. Комбайннар, тракторлар җитешми. Җитмәсә, кар да вакытыннан алда сибәли башлый ул елны. Урып-җыю өчен борчылган беренче секретарьга шикаять язучылар да табыла. Шул җитә кала, халык дошманы дигән ярлык тагып, аны кулга алалар. Тәтешнең текә кыялы елга ярыннан конвой белән атлаганда, Кыяметдин кыю карар кабул итә: сак астыннан качып китә, җепшек кар ләмгә әйләнгән аяк астын ерып, шактый куалар аны. Әмма тота алмыйлар, Кыяметдин бозлы суга төшеп, үткен күзләрдән юкка чыга. Ерак түгел генә бер авылга барып чыкканнан соң, күптәнге танышының ишеген шакый Кыяметдин. Эзәрлекләүләрдән качып, 3 көн буе тирес эчендә ятарга туры килсә дә, сер бирми. Аннан, хатын-кыз киемнәрен киеп, Ульян якларына чыгып китә. Биредә кинолог буларак этләрне өйрәтергә керешә ул, сакал-мыеклар үстереп җибәрә. Казанга да берничә тапкыр юл ялгый. Әмма берсендә Буа станциясендә поезд тәрәзәсеннән перронга күз төшерә. Кирәк бит, аны Әлки ягыннан булган бер таныш хатын танып ала. Поезд кузгалып китә, әмма күп тә үтми, шып итеп туктап та кала. Шул арада кораллы сакчылар керә һәм, Кыяметдиннең кулларын богаулап, алып чыгып та китәләр. 58 нче маддә нигезендә 10 елга утыртып куялар. Шуннан соң да тагын 4 елга хокукларыннан мәхрүм итәләр. Хатыны Оркыя өч баласы белән Карга авылына – әти-әнисе янына кайтып сыена. Көннәрдән бер көнне, срогын тутырып, әтиләре дә кайтып төшә. Кыяметдин Мисбахов яңадан партиягә керә, үз исемен аклауга ирешә, 25 меңенче була.

СЫЕРСЫЗ КАЛУ

«Сугыш вакытында без үсмерләргә бик авыр булды, – дип искә ала Галимҗан абый Сафин. – Җирләр вакытында чәчелми, орлык юк. Кыр эшләре соңга кала. Сыерлар җигеп эшләргә мәҗбүрбез. Ашамаганны әйтеп тормыйм, иртән Дубрау урманы янындагы билгеләнгән кырга сыерга тырма тагып бардым. Өйдә биш бала, бер әби. Әни эшли, сыер ашата. Көн кыздырганнан-кыздыра бара. Сыерым тәмам хәлсезләнде, авызыннан күбекләр килә. Кечкә кадәр интегепләр эшләдек инде. Шунда авылга кайтырга чыктык. Тырманы калдырып булмый, сыерга аны да сөйрәргә туры килде. Күл буена җитәрәк, су эчәсе килептер инде, сөйрәп алып торып китте бу. Мин дә артыннан сөйрәлеп барам. Суга керде. Чыкканда карыйм, тырмага аягын җәрәхәтләгән хайван. Чатаклый-чатаклый кайттык кайтуын,

лəкин тернəклəнə алмады. Шулай итеп сыерсыз да калдык...»

Кышкы суыклар исə малларның гына түгел, авыл халкының да шактый гомерен тартып ала. Азмы-күпме җылынып, салкын үлемнəн котылу өчен, халык караңгы төндə кача-поса урманга барып чыбык-чыбык җыярга мəҗбүр. Əле көндезлəрен дə урман юлын таптый алар: хөкүмəткə урман кисү бурычы да йөклəнгəн ич. Җəннəтелмəэуа, əнисе Илһамия белəн урман кисəргə баргач, ачлыктан аңын җуеп егыла. Бала гына бит əле. Өйгə кайткач, нишлəсен əни кеше, соңгы оныннан коймак изə, тегесе борынын кытыклаган ризык – яшəү исен сизеп торып утыра.

Бөек Ватан сугышы елларында Каргада Ленинградтан эвакуациялəнгəн 3 гаилə яши: Сольников, Лисицин һəм Дусалимовлар. Татарлар арасында яшəп, алар татарлашып бетə, билгеле.

Миңгəрəй абый Нотфуллин исə сугышта Ленинград блокадасына элəгə. Ат җигеп, урамнардан мəетлəр җыеп йөри, аларны Ладога күленə илтеп ташлау бурычы куела аңа. Ачлыктан үзе дə, аты да хəлсез. Авыр чаклар... Гомере буе төшлəренə кереп интектерерлек афəт лəбаса бу! Тагын күпме дəвам иткəн булыр иде – билгесез, лəкин көннəрнең берендə Миңгəрəй Нотфуллин олавы янында снаряд шартлый. Җирнең асты өскə килə – арбасындагы мəетлəр белəн бергə ул да туфрак өеме астында кала. Туган ягында эчəсе сулары калгандыр, совет солдатын табып алып, госпитальгə – Мəскəүгə озаталар. Шул ук госпитальдə аның газиз улы – Шəүкəте дə үлем белəн көрəшə. Контузия алган ата белəн ул кул сузымы арасында гына ятуларын белми дə калалар. Миңгəрəйне, инвалидлык кəгазе тоттырып, авылга кайтаралар. Ə Шəүкəт – 18 яшен əле яңа гына тутырган Карга егете, кече лейтенант хəрби дəрəҗəсен алып, Польшага – алгы фронтка китə һəм шунда мəңгелеккə ятып кала. Əнисе, кара кəгазь алгач, йөрəгə сызлауга түзə алмыйча җыр чыгара:

– Герман пулялары тигəч,
«Уф, Аллам!» дидең микəн?
Нурлы йөзлəреңне ачып,
Җаннарың бирдең микəн?

Аның кайгысы бүтəннəргə дə ят түгел: «Вəһибə, ул кадəр өзгəлəнмə əле, караңгы сарайга кереп кара, Шəүкəтең күзеңə күренер», – дип юатучылар да була. Мескен, өрəгə күземə чалынмасмы дип, сарайга да керə. Ярый əле сугыштан ире кайта. Сау булмаса да, исəн! Вак балалар – Шəүкəтнең эне-сеңеллəре Миңгəрəй этилəренең кочагына атыла. Эти кеше яшь аралаш бер генə җөмлə əйтə: «Балаларым, асылынмагыз, хəлем юк...»

КЕШЕЛƏРЕ БЕЛƏН ДАНЛЫКЛЫ

Авыл тарихын барлаганда бер нəрсəгə инанасың: аның сəхифəлəрен үзенең фидакарьлеге, кешелеклелеге белəн халык үзе яза икəн. Каргада да күп алар. Гомер буе терлекчелектə эшлəгəн апалар – ике чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты, Ленин ордены иясе Зəйнəп Вəлиева, Хезмəт Кызыл Байрагы ордены иясе Гайшə Бикушева, 36 ел бозау караган «Почет билгесе» ордены иясе, фотосы хəтта «Азат хатын» журналы тышлыгында басылган Рəйсə Сабировалар һ.б.

Карга – авыр атлетика буенча спорт осталары белəн Россиядə, халыкара ярышларда танылган Бикушевлар, Фəттаховлар белəн дə данлыклы. Əнə Газинур Фəттахов 2013 елда гына гер күтəрү буенча дөнья чемпионы булган спортчы. Фəнис Низамовның да профессиональ спортта үзен тапкан көннəре. 1991 елгы егет, буем бəлəкəй, язмыш мине кыерсытты дип, сыктап утырмый, йөзендə яшəү чаткысы чагыла. 56 кг авырлыгы белəн 130 кг авырлыкны күтəрү берни түгел аңа.

БУСЫ – ПРЕЗИДЕНТНЫКЫ!

Карга авылы бүген матурая, яшəрə. Бала табучылар күбəя. «Ана даны» медале иясе Əлфия Нотфуллинаны мисал итеп китерə яшь аналар. Ире Шəүкəт абый белəн алар 8 бала үстерəлəр, инде 10 оныклары да бар. Əлфия апаның хəтта бала тапканын да кайвакыт сабыен кулында күргəч кенə белгəннəр. Бервакыт, кичке савымга дип, җəйге аланга барганда, машина арбасына этеп диярлек менгерəлəр аны. «Əллə тазарып киткəнсең инде, Əлфия», – дип көлешкəннəр дə. Ə иртəн бер аны гына көтеп гаҗиз булгач, өенə бара савымчылар. Баксаң, төнлə Əлфияне бəби табарга районга илткəннəр икəн бит. Моны белгəч, ислəре-акыллары китə хезмəттəшлəренең. Икенче юлы Шəүкəт абый төнлə белəн уянып китсə, хатынының өйдə юклыгын абайлап, аны эзлəргə керешə. Баксаң, ул мунчада бəбилəргə дə өлгергəн, ди. Əлфия апага исə Татарстанда «Ана даны» медаленең 3нче сандагысы бирелə. Медаль тапшырганда, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шəймиев, Əлфия апаны җилкəсеннəн үз итеп кочаклап, фотога да төшə. Моны телевизордан да зурлап күрсəтəлəр. Кирəк бит, 9 айдан Нотфуллиннарның гаилəсе тагын ишəя – кече кызлары Айзилə туа. Балаларның барысының да исемнəре «А» хəрефеннəн башлана. «Ничек истə калдырасыз соң?» – дигəч, гаилə башлыгы, күзен дə йоммыйча, санап чыга: Алия, Айсинə, Айгөл, Алсу, Айрат, Айсылу, Айдар, Айзилə!

P.S.
Карганың тарихи сəхифəлəре турында күбрəк белергə телəүчелəргə 2013 елда дөнья күргəн «Каргауыл» китабын укырга киңəш итəм. Ə иң яхшысы – авылга кайтып килү. Анда һəркемгə дə – ачык йөз, якты чырай.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

Әлеге калкулык астында Җүкәтау шәһәре хәрабәләре яшеренгән.

ҖҮКӘТАУ: ТЕЛДӘ КАЛГАН, ЯЗМАЛАРДА САКЛАНМАГАН

1990 елда ТР Министрлар Кабинеты республикабызның Кама аръягы районнарында урнашкан борынгы Болгар, Сувар, Биләр һәм Җүкәтау шәһәрләрен тоташтырачак «Көмеш дага» исемле туристик маршрут булдыру турында махсус карар чыгарган иде. Кама аръягы – Идел Болгарстанының халык иң тыгыз урнашкан үзәк җирләре. Таш гасырыннан башлап, тимер гасырына кадәрге чорларда яшәгән борынгы кабиләләрнең археологик истәлекләре бихисап биредә. Табигате исә гаҗәеп гүзәл. Һичшиксез, уйлап эш иткәндә, төрле тикшеренү-төзү эшләренә акчаны кызганмаганда, менә дигән туристик маршрут булачак ул!

Автор:
Фаяз Хуҗин

Автор:
Наил Нәбиуллин

ЮЛБАСАРЛАР УЗГАН ЭЗЛӘР БУЙЛАП...

Кызыклы проектны тормышка ашыруда, беренче чиратта, археологлардан ярдәм сорала иде. Озак уйлап тормадык, без, Г. Ибрагимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының бер төркем археологлары, гыйльми сәяхәткә чыгып киттек.

...Безнең алда – ерактан ук күренеп торучы Чистай элеваторы «оялаган» биек тау башындагы мәшһүр Җүкәтау хәрабәләре. Аста чал дулкыннарын тибрәтеп, салмак кына Чулман агып ята. Шәһәр үзе кыр ягыннан өч рәт балчык үр-чокырлар, агач диварлар белән яхшылап ныгытылган булган. Бу – Кала Тау, аның үзәк өлеше, кирмәне. Калага каршы якта, Чулманның сулъяк кушылдыгы Киле суы аша чыккач, иркен, тигез мәйданда шәһәрнең һөнәрчелек бистәләре урнашкан.

Игътибар иткәнегез бардыр: Болгар тарихына багышланган гыйльми хезмәтләрдә һәм фәнни-популяр әдәбиятта Җүкәтау исемен даими рәвештә телгә алып киләләр. Шул ук вакытта аның чын тарихын гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар беләбез. Беренче мәртәбә Җүкәтауны XVIII йөз рус тарихчысы һәм җәмәгать эшлеклесе В.Н. Татищев китабында очратабыз. Биредә ул 1236 елның көзендә Батый гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителгән болгар шәһәрләре рәтендә санап үтелгән: «Татарлар Бөек Болгар иленә яу белән килделәр, бөтен җирләрен әсир иттеләр, Олуг шәһәрне (Биләрне) һәм Җүкәтауны каты сугышлардан соң кулга төшереп, ирләрен һәм хатын-кызларын үтереп бетерделәр». Кызганыч, шәһәрнең монголларга кадәрге тарихы язма чыганакларда чагылыш тапмаган.

Борынгы рус елъязмаларында Җүкәтауга нисбәтле рәвештә сурәтләнгән вакыйгалар Алтын Урда чорына карый. Билгеле булганча, XIV гасыр урталарыннан башлап, Новгород ушкуйниклары болгар җирләренә еш кына яу чабып торганнар. Ушкуйниклар (ушкуй – «ишкәкле зур көймә» мәгънәсендә) – Идел, Чулман буйларында урнашкан калаларны талап, байлык туплау максаты белән махсус оештырылган һәм угрылык-

Фотолар авторлардан алынды

Җүкәтау. Өстән күренеш.

XIV гасыр көмеш тәңкәләре (Чистай тирәсендә табылган).

тан башка һөнәрләре булмаган башкисәр ирләрдән торган коралды отрядлар алар. Ушкуйникларның болгарларга каршы 1360 елда оештырылган беренче походы турындагы хәбәр Никон елъязмасында тулырак китерелгән: «Олуг шәһәрдән юлбасарлар Җүкәтауга килделәр, бик күп халыкны кырдылар һәм байлыкларны талап алдылар, шул галәмәтләре аркасында христианнар үзләре дә болгарларда кыйналуга дучар булдылар».

1391 елда Новгородтан һәм Устюгтан чыккан ушкуйниклар, көймәләренә төялеп, янә Чулманга төшәләр, Җүкәтауны, Кашанны алалар, Иделдә юлбасарлык итәләр һәм бай табышлар белән өйләренә таралышалар. 1396 елда шул ук рус угрылары, корал кулланып, «Болгарны, Җүкәтауны, Казанны (Кашанны?), Кирмәнчекне һәм башка калаларны талыйлар, бу җирләрдә өч ай буена юлбасарлык кылып, бик күп байлыклар белән кире кайтып китәләр».

Ушкуйникларның болгар җирләренә походлары XV гасыр башында да дәвам итә. 1409 елда, мәсәлән, аларның ике зур төркеме Новгород посаднигы Анфал Никитин җитәкчелегендә Болгарга юнәләләр: йөзләп көймә – Чулман буйлап, йөз иллеләбе Идел буйлап хәрәкәт итәләр. Беренче төркемне болгарлар тотып алалар һәм хөкем итү өчен барысын да Урдага озаталар. Анфал җитәкчелегендәге икенче төркемгә каршы чыгып, Болгар һәм Җүкәтау бәкләре аларга йолым тәкъдим итмәкче булалар, ләкин ахыр чиктә болай да җиңүгә ирешәләр. Юлбасарларның күп өлеше качып котыла, әсир төшкәннәрен исә янә Урдага озаталар.

1411 елда рус елъязмалары Болгар һәм Җүкәтау бәкләренең Мәскәү белән Суздаль феодаллары арасында олуг тәхет өчен барган көрәштә катнашулары турында хәбәр итәләр.

Менә шушы хәбәрләргә таянып, XIX йөз тарихчылары А.Артемьев, И.А. Износков, Н.А. Толмачев, С.М. Шпилевский Җүкәтауның болгарлар тормышындагы икътисадый һәм сәяси ролен ачыкларга омтылалар, аның ул вакытларда әле билгесез хәрабәләрен эзләп табуда уңышлы адым ясыйлар. П.А. Понамаревның 1892 елда дөнья күргән хезмәтләреннән соң гына борынгы Җүкәтауның хәзерге Чистай тирәсендә, Донауровка авылыннан ерак түгел җирдә урнашкан булуы ачыклана.

ҮГИ ИТСӘЛӘР ДӘ, ҮЗ ИКӘН

Археологлар, әйткәнемчә, Җүкәтау каласын нишләптер озак еллар буена үз итә алмадылар. Шул ук вакытта шәһәрлек территориясендә кызыклы гына, хәтта уникаль әйберләр табыла торды. Алар арасында, мәсәлән, 1908 һәм 1909 елларда Донауровка авылы янында табылган акча хәзинәләре бар. Бу акчаларның барысы да Алтын Урда чорында сугылган. Иң кыйммәтле хәзинәләрнең берсе – алтын-көмештән, төрле асылташлардан, энҗе-мәрҗәннәрдән ясалган бизәнү әйберләре, һинд солтаннарының 1340–1341 елларда сугылган алтын динарлары – 1924 елда табылган булган. Кызганыч, Татарстан дәүләт музеена тапшырылган бу әйберләр хәзер югалып беткәннәр, алар турында без профессор В.Ф. Смолинның бер мәкаләсеннән генә укып белә алабыз.

Бары тик 1970 елда гына ИЯЛИ галиме, күп еллар Болгарда эшләп, зур тәҗрибә туплаган археолог Т.А. Хлебникова бирендә яңа казылма эшләре башлап җибәрергә карар кыла. Башта ул Җүкәтауның төгәл топографик планын эшли, Кала Тауда һәм шәһәр яны бистәсендә казулар үткәреп, берничә торак йорт, күп кенә хуҗалык корылмалары ача, монголларга кадәрге чорга караган некропольдә (зиратта) дистәгә якын болгар каберлекләрен өйрәнә.

Өч сезон буена тупланып килгән экспедиция материаллары шәһәр үсешендәге төп чорларны билгеләүдә нык лы нигез булдылар. Т.А. Хлебникова Җүкәтауның чәчәк атып яшәү дәвере XIV гасырга туры килүен исбатлады. Киле елгасы буенда үткәрелгән казылма эшләрендә галим шәһәрнең барлыкка килү вакытына караган материаллар да тапты. Аның фикеренчә, XI гасырда ук инде Җүкәтау кечкенә генә шәһәрчек булып, кирмәне 5 гектар чамасы, ә гади халык яши торган бистәсе 6-7 гектар җирне биләп торган. Алтын Урда чорында һөнәрчелек бистәләренең мәйданы 35 гектарга кадәр киңәйгән.

СЕРЛӘРЕН АЧА БАШЛАДЫ...

Шулай гадәтләнгән инде: ничек кенә яхшы тикшерелгән объект булмасын, без эшебезне беренче чиратта разведкадан башлыйбыз. Безгә шәһәр яны бистәләрнең чикләрен төгәлрәк итеп ачыкларга кирәк иде. Бу эшләр, көтмәгәндә, икенчерәк төрле юнәлеш алды. Шәһәр биләмәсе элек уйлаганга караганда күпкә зуррак икән бит! Кала Таудан яр буйлап бер километр чамасы көнбатыштарак (Галактион авылына таба) киткәч, бик кызыклы хәлгә тап булдык. Бу тирәдә чүлмәк

PRESSA.RU

Ат иярләү һәм җайдак кирәк-яраклары предметлары.



Чистайның хәзерге татар зиратында XIV гасыр кабер ташлары сакланып калган.

ясау осталары яшәгән булган. Яр ишелеп, савыт-саба яндыру өчен махсус эшләгән ике катлы зур гына мич бөтенләй шәрәләнеп калган. Мичнең аскы камерасын, утын ягып, югары температура булдыру өчен файдаланганнар. Кызган һава югары күтәрелеп, өске камерадагы чүлмәкләрне киптергән. Мичнең балчыктан сылап эшләнгән калын стеналары, югары температура астында озак торганлыктан, ничектер эреп, пыялаланып беткән.

Җүкәтау, әкренләп булса да, серләрен ача башлады кебек. Һәрхәлдә, шушы берничә көн эчендә без аның, ким дигәндә, 140–150 гектар мәйданда урнашкан булуын ышандырырлык материаллар белән исбатлый алдык. Алай гына да түгел, разведкаларыбызны Чистай ягына таба дәвам иттек. Белүебезчә, Чистайның хәзерге татар зиратында XIV гасыр кабер ташлары сакланып калган, биредә кайчандыр Алтын Урда акчалары да табылган, гомумән, бик тыгыз утырган бу тирәләрдә халык. Чыннан да, зират тирәсендәге чокыр-чакырларда, бәрәңге бакчаларында болгарларның монголларга кадәрге һәм Алтын Урда чорына караган әйберләре (әлбәттә, башлыча чүлмәк китекләре) еш очрый. Димәк, Чистай шәһәре урнашкан җирдә элек-электән болгар бабаларыбыз яшәгән булып чыга. Кечкенә генә булса да, ачыш түгелмени бу?! Шулай икән, Чистаебызның тарихы, рәсми документларда язылганча, XVII–XVIII йөзләрдән түгел, бәлки күпкә элгәрәк башлана икән бит. Һәм әлеге тарих турыдан-туры Җүкәтау каласы белән бәйләнгән булырга мөмкин. Әйе, бу әлегә фараз гына. Тикшеренүләрне дәвам итәргә кирәк әле.

МУЛЛЫК ҺӘМ МӘХШӘР ЭЗЛӘРЕ

Инде казу эшләренә тотынырга вакыт иде. Беренче казылма урынын Киле елгасының Кала Тауга каршы сул ягында, Чулманнан ерак түгел генә бер җирдә сайлап алдык. Биредә Җүкәтауның иң борынгы культура катламнары сакланган булырга тиеш, дип фараз кылдык. Һәм ялгышмаганбыз.

Өске катламны алып ташлауга, Алтын Урда чорында «яшәгән» корылмаларның эзләре аныклана башлады. Каралты-куралары белән бер торак йорт урынына тап булганбыз икән. Аны дүрт яктан уратып алган казык читән эзләренә кадәр сакланган. Шундагы чокырларның берсен чистарта гына башлаган идек, кеше скелеты килеп чыкты. Каян килгән ул?

Бераз эшләгәннән соң менә нәрсә ачыкланды: безнең бу табылдык XIV гасыр башларына караган катламда ята. Алтын Урда ханы Пулад (Булат) хакимлек иткәндә, ягъни 1407–1411 еллар аралыгында сугылган бакыр акча да табып алдык. Җүкәтау тарихында булып узган фаҗигале вакыйгалар белән бәйле түгелме икән ул? Шәһре Болгар кебек үк, Җүкәтауның да 1431 елда урыслар тарафыннан җимерелгән булуы бик мөмкин. Шул елны, Никон елъязмасы билгеләп узганча, урысларның олуг кенәзе Василий II «Идел һәм Кама болгарларына каршы Федор Давыдович Пестрый җитәкчелегендә яу җибәрде; алар, сугышып, болгарларның барча җирләрен әсир иттеләр». Безнең алда, күрәсең, менә шушы сугышларда үлеп калган кешенең мәете ята иде.

Алтын Урда катламы табылдыкларга бай булып чыкты. Дистәдән артык көмеш һәм бакыр акча, үлчәү һәм герләр, ачкыч-йозаклар, бизәнү әйберләре, орчык башлары, әллә никадәр кыйммәтле савыт-саба ватыклары, шул исәптән ерак илләрдән китерелгәннәре дә – барысы да шәһәр халкының ярыйсы гына мул тормышта яшәгәнлекләрен раслыйлар (бай булмасалар, ушкуйниклар тиктомалга бимазалап та тормаслар иде).

Казу эшләрен дәвам итеп, монгол яуларына кадәр тупланган катламга килеп җиттек. Тагын фаҗига эзләре: көл-күмер катыш туфрак арасында кеше сөякләре, тимер ук очлары, янгынга эләгеп формасын югалткан кечкенә чүлмәк. Болары инде 1236 елгы мәхшәрне күз алдына китереп бастыра.

Элгәрерәк чорга караган катламнарны ачканда төп игътибарыбызны шәһәрнең барлыкка килү вакытын ачыклардай табылдыкларга юнәлттек. XI гасыр материаллары инде безгә кадәр дә билгеле иде. Алар безнең табылдыклар арасында да бар. Әмма X гасырда гына кулланышта булган әйберләрнең очрагасы юк иде әле. Ниһаять, андыйлары да табылды. Көмеш дирһәм! Димәк, шәһәребез X гасырда «туган» булып чыга.

БЕЗ КИНӘТ ЮЛЫККАН ТАБЫЛДЫК

Казу эшләре системалы һәм максатчан рәвеш алды. Яр буйларын җентекләп тикшереп чыктык. Киле елгасы белән Чулман тоташкан җирдә таралган тимер шлак кисәкләре игътибарыбызны җәлеп итте. Үзебезгә ошаган бер участокны казып карарга булдык. Күмер һәм эреле-ваклы тимер шлакла-

Йозак һәм ачкычлар Җүкәтауда тимерчелекнең алга киткән булуын дәлилли.

Җүкәтау тибындагы керамика.

ры белән тулы калын гына катлам астында кирпеч ватыклары күренә башлады. Тиздән безнең алда биеклеге һәм әйләнәсе бер метр чамасы булган түгәрәк мич калкып чыкты. Мондый мичләрдә, руда катыш агач күмере тутырып, югары температура тудыру өчен астыннан махсус җайланмалар белән һава өрдереп, тимер һәм корыч койганнар. Табылдыкларның күбесе һөнәрчеләрнең эшенә, тормыш-көнкүрешенә нисбәтле әйберләрдән тора иде.

Ярый, металл коючылар эшләгән урынны таптык, ә алар җитештергән чималдан төрле әйберләр ясаучы тимерчеләр бистәсе кайда соң? Эзләнеп озак йөргәннән соң, күңелебезгә хуш килгән бер урыннан сайлап, шурфлар салдык, арадан берсен киңәйтеп, яхшылабрак казырга керештек. Бу тирәдә культура катламы алай калын түгел, ярты метр чамасы гына булыр. Табылдыклар да гадәти: шул ук Алтын Урда акчалары, ук очлары, пычаклар, чүлмәк китекләре... Шаккатырырлык нәрсәләр килеп чыгарга охшамаган. Казылманың бер почмагында ачыла башлаган ниндидер агач корылма эзләре дә әллә ни вәгъдә итми кебек. Әмма, нәкъ менә шушы корылмабыз тимерче алачыгы булып чыкмасынмы! Аның стеналары җиргә казып утыртылган агач баганаларга калын такталар беркетеп эшләнгән.

Ишектән кергәч тә уң якта – кирпеч-таштан өеп ясалган кечкенә учак. Учак күмерләре арасында тимер-калай кисәкләре. Стенаның учак тирәсендәге өлеше, янгын куркынычсызлыгы максатыннандыр инде, кызыл балчык сылап ныгытылган. Каршы якта, ихтимал тимерче сандалы торгандыр. Кызган тимерне суыту өчен суны тар гына арыктан агызып җибәрә торган булганнар. Икенче як стена буенда инструментлар һәм төрле әйберләр кую өчен «сәке» тибындагы урын җиһазландырылган...

КОЛАЧЫБЫЗНЫ КИҢРӘК ҖӘЙСӘК ИДЕ...

Соңгы елларда без Җүкәтау каласының оборона ныгытмаларын казу белән шөгыльләндек, шәһәрнең борынгы зиратларын тикшердек, тирә-юньдә урнашкан археология һәйкәлләрен барладык. Күп нәрсәләр ачыклана төште кебек. Әйткәнебезчә, шәһәрнең монголларга кадәрге территориясе дә 11–12 гектар гына түгел, 25–30 гектарга җиткән, Алтын Урда чорында ул Идел-Кама төбәгендә Болгардан кала иң эре шәһәрләрдән саналган, һөнәрчелек үзәге булган, зур гына кенәзлекнең башкаласына әверелгән. Кенәзлек дигәннән... Ниндирәк кенәзлек булган соң ул? Кайсы җирләр кергән аңа?

Бу сораулар галимнәрне күптәннән кызыксындырып килә, ләкин язма документлар сакланмагач, алар һаман җавапсыз кала. Археологиянең мөмкинлекләре чиксез түгел, шулай да, безнең материаллардан чыгып, кенәзлекнең чикләрен якынча билгеләргә мөмкин дип саныйбыз. Эш шунда ки, һәр төбәкнең матди культурасында нинди дә булса бер үзенчәлек бар. Бу үзенчәлек керамикада чагылыш тапкан. Болгар керамикасы беренче карашка гына бертөрле булып күренә. Чынбарлыкта һич алай түгел. Җүкәтауда, мәсәлән, археологлар телендә «Җүкәтау тибындагы керамика» дип йөртелгән түгәрәк төпле, балчыгына эре ком яисә төелгән бака кабырчыгы кушып ясалган дулкын сыман бизәкле чүлмәк-касәләр күп табыла. Мондый керамика Биләрдә, Суварда, Болгарда бөтенләй юк диярлек. Шул ук вакытта Җүкәтауга якынрак урнашкан җирләрдә очрый. Әгәр дә Җүкәтау тибындагы керамика табылган археологик истәлекләрне картага төшереп чыксак, Чулманның түбән агымында, хәзерге Чистай, Алексеевск районнарында урнашкан күп кенә болгар авыл-шәһәрләренең югарыда әйтелгән үзенчәлекләре буенча, Җүкәтауга «тартылуын» күрербез.

Тагын бер кызыклы факт: безнең эпиграфист-галимнәребез, XIV йөздә куелган кабер ташларындагы язмаларның тел үзенчәлекләренә нигезләнеп, борынгы Җүкәтау җирләрен «җ-диалект» өстенлек иткән мөстәкыйль төбәк булган, дип карыйлар. Югарыда китерелгән дәлилләр, ихтимал, Җүкәтау халкының этник үзенчәлекләре белән бәйледер.

Җүкәтау һәм аның тирәсендәге археология һәйкәлләре (Чистай җирлеген дә кертеп) тагын да зуррак игътибарга лаек. Аны өйрәнү киң колач белән алып барылырга тиеш. Табылдыкларны Чистай музеена урнаштыру мөмкинлеге турында да уйланасы бар. Аларның урыны институт подвалларында түгел – халык күрсен, уйлансын, үткән тарихыбыздан гыйбрәтләр алсын!

P.S. Җүкәтау... Чал дулкыннарын тибрәтеп, салмак кына агып ятучы Чулман буенда ул, борынгы Болгар, Биләр, Сувар кебек үк, ерак үткәнебезнең мөкаддәс бер һәйкәле.

PRESSA.RU

Ната Смирнова фотолары

БАЛАЛАР НИГӘ ҮЛӘ?

– Мондый сорауларны йә табибларга, йә Аллаһы Тәгаләгә бирергә мөмкин, – ди Анжела Вавилова исемендәге балалар хосписының баш шәфкать туташы Ләйсән Камалова. – Ә без монда бары тик ярдәм итүчеләр, сабыйларның газапларын җиңеләйтергә тырышучылар гына. Бәләкәчләрнең язмышларын үзебез аша үткәреп, аларга ничек авыр булганын аңлыйбыз. Әмма бу безнең өчен эш кенә түгел, күңелебез омтылган изге вазыйфа да. Шул вазыйфаны үзеңдә тоюдан, шәфкатьлелектән һәм аңлый белүдән башка монда эшләп булмас иде. Монда яткан балалар үзебезнекеләргә әвереләләр, – ди Ләйсән Маратовна һәм безне йолдызлы күк картасы янына алып килә, анда һәрбер йолдыз инде бу җирдән киткән баланың исемен йөртә. Һәм ул баланың соңгы көннәре шушы Фәрештәләр йортында үткән. Шуңа монда аларның һәркайсын хәтерлиләр һәм яраталар.

PRESSA.RU



...Бу йортка фәрештәләр җыела. Кемдер – арбада, кемдер – әтисе йә әнисенең кулында, бик сирәкләре генә үз аякларында. Кайбер фәрештәләр биреге вакытлыча, үзләренә һәм якыннарына беркадәр социаль ял, тәнәфес алу өчен, ә кайберләре, башка дөньяга күчкәнче, дарулар, рецептлар, подгузниклар һәм чиратларга бәйле бюрократик тоткарлыклардан арынып торган якын һәм кадерле кешеләре янында лаеклы рәвештә яшәп калырга килә. Биредә, йомшак елмаюлар һәм җан җылысы, яхшы тәрбия һәм матур интерьер эчендә, барысы да, гәрчә бик яратсаң һәм аерылырга теләмәсәң дә, үлемне тоткарлап булмавы белән килешкәннәр, хәтта кеше – синең бердәнбер балаң булган очракта да.

Әниләр биредә елмая һәм балаларына төрлечә ярдәм итә. Алардан яктылык сирпелә, бу беренче карашка күтелмәгәнчә тоела, чөнки без хосписта бит.

– Без монда җиңеллек алабыз, – диләр алар. – Монда без авыруның үзе һәм аны әле алда көтәчәк вакыйгалар белән берүзебез генә калмаячагыбызны тоябыз. Безне ташламаячаклар.

Бассейнда йөзеп һәм уйнап туйгач – монда түшәктәге авыруларны сак кына суга күчерү өчен махсус күтәргеч тә бар – фәрештәләр төшке ашны ашый. Төштән соң кемгәдер – массаж, кемнеңдер – озак ятканнан соң хасил булган җәрәхәтләрен эшкәртү, кемгәдер – уен бүлмәсендә уйнау. Ә 15 яшьлек Павликның бүген ни өчендер гел йокысы килә.



– Күрәсең, һава торышыннандыр, урамда көн болытлы, – дип аңлата әнисе һәм йокыга изрәгән улын үбеп, өстенә плед яба: – Минем иң татлы ир-егетем бит ул...

PRESSA.RU



– Дөньяда онкологик сызланулардан да көчлерәк һәм чыдап булмастай авырту юк, диләр. Һәм ул авыртуның әйләнеп кайтуыннан куркудан да көчле курку юк. Әмма «теориядә» моны күз алдына да китереп булмый. Монда, хосписта да, мөмкин түгел бу. Чөнки биредә авырту юк. Кайчакта булмас та кебек тоела. Авырту да, чир үзе дә. Соңгы өметләр алдаучан, чөнки хоспис – бу паллиатив ярдәм – бөтен зарури медицина процедуралары һәм авыртуны тулысынча басу. Онкологик авырулар өчен генә түгел, ДЦП һәм неврологиянең авыр формалары өчен дә.



Мөгаен, әти-әниләренең тормышы балалары киткәннән соң да дәвам итсен өчен яшидер дә бу Фәрештәләр йорты – бала ахыргача әти-әнисе янәшәсендә үз-үзе булып, шат күңелле һәм борчуларсыз кала алырлык урын, авыртулардан азат йорт. Һәр әти, һәр әни үзләренең дә, әйләнә-тирәдәгеләрнең дә аларның балалары соңгы көненәчә бәхетле калсын һәм бер генә мизгел дә сызланудан газапланмасын өчен мөмкин булганның барысын да эшләгәнен белә. Ахырдан минем баламның тормышы яхшы булды, дип әйтергә мөмкин булсын. Бу – бернинди әҗер-таләпсез ярдәм итәргә һәм бу ярдәмгә күңелен салырга теләгән кешеләрдән тора.

АВЫРУ БАЛАЛАРНЫҢ БАЛАЧАГЫ БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ

Владимир Вавилов, Анжела Вавилова исемендәге Фонд Идарәсе рәисе, балаларның ни өчен үлүе һәм үлүчеләрнең балачагын лаеклы итү өчен нәрсә эшләргә кирәклеге турында.

– **Балалар ни өчен үләме? Чөнки без ана булу культурасының ни икәнен оныттык.** Бер кулына сыра, икенче кулына сигарет тотып, сөт кухнясы янында бала арбасы белән торган әниләрне күрәм дә миңа куркыныч булып китә. Елның салкын фасылында берниндидә җылылык бирми торган модалы киемнәр кебек үк, сыра белән сигарет бу әниләрнең кулларында бәбиләре туганчы ук булган. Арбаларында йоклап ятучы сабыйларның сәламәт булуы икеле – **бездә бит бүген балаларның 1,5 проценты гына сау-сәламәт туа.** Балалар инвалидлыгы үсә, экология начарая – инде көн саен яңгырый торган бу сүзләргә беркем дә игътибар итми кебек. Аларның мәгънәсе шомарып, җуелып бетте. Ә шул ук вакытта бездә онкология генә түгел, дәвалап булмый торган башка авырулар да пәйда булды.

Моның белән ничек көрәшергә? Аңа ничек каршы торырга?

Барысы да гаиләдән башлана, барысы да аш-су бүлмәсеннән башлана – нәрсә ашатабыз, нәрсәгә өйрәтәбез, балаларыбыз белән нәрсә турында сөйләшәбез. Алар бит туу белән, бишектән үк барысын да сеңдерә. Аннары гына ул – балалар бакчасы, мәктәп, урам... Башта барысына да гаиләдә нигез салына. Без хәзер балаларыбызны артык азындырабыз, аларга бер нәрсәне дә чикләмибез – димәк, аларны харап итәбез. Айфон теләләрме – рәхим ит – нәтиҗәсе турында беркем уйланып тормый, бары тик бала башкалардан ким булмасын, ялтыравык кәгазьле тәм-томмы – куллану вакытына, составында балалар өчен зыянлы, сыйфатсыз матдәләр булуына да игътибар итмичә, анысын да сатып алабыз. Балаларыбызны фастфуд белән тукландырабыз, чөнки үзебез пешерергә өлгермибез. Әллә теләмибезме? – болай җайлырак та, тизрәк тә бит. Кая ашыгабыз? Без үзебез дә сәламәт ризыктан баш тарттык, балаларны да аннан читләштердек. **Генофонд җимерелә. Авыру ата-анадан сәламәт бала тумый, авыру бала туа. Ә бу авыру баладан – тагын да көчлерәк авыру бала.** Ә аннан ары? Аннан соң – катастрофа. Авыру балалар артканнан арта. Аларны яшәтү һәм дәвалау өчен торган саен күбрәк мөмкинлекләр, акчалар кирәк. Хезмәткә яраклы һәм сәламәт кешеләр саны аның саен азая бара. Хезмәткә яраклы һәм салымнар түләргә сәләтле сәламәт кешеләр саны аның саен азая бара.

Ни өчен хоспислар барлыкка килә – чөнки авыруларның газапларын ничектер җиңеләйтергә кирәк. Мондый ярдәм йортларына ихтыяҗ арта бара. Монда дәваланырга түгел, ә паллиатив ярдәм алырга киләләр. Без сызланмыйча яшәргә, лаеклы яшәргә булышабыз. Әлбәттә, монда эшләү җиңел түгел, үзең иялашкән балаларның бу дөнья кешеләре булмавын, озакламый китәчәкләрен тою бик авыр. Алар урынына башкалары киләчәк, һәм шулай ук китеп барачак... **Әмма хоспис – үлем йорты түгел, бу лаеклы тормыш йорты. Һәм безнең бурыч – пациентларыбызның тормышын, гадәти балачакта ул нинди булырга тиеш булса, шундый ук сызлануларсыз һәм кызыклы итү. Безнең фонд акчаны нәкъ шуның өчен җыя да.**

Хоспис – авыртулардан азат йорт – бик күп битараф булмаган кешеләрнең ярдәме белән барлыкка килгән. Бу йортта даими рәвештә 35 көчле авыру бала яши һәм 100гә якын балага хосписның «Стационар на дому» хезмәте өйләренә барып ярдәм күрсәтә. Хоспис карамагындагы балаларның авырулары төрле: бу онкология дә, ДЦПның авыр формалары да, неврология дә.

«Татарстан» журналы өчен махсус

Мин халыклар дуслыгы һәм тынычлык яклы!

Евгения Лоза, актриса, «Восток-Запад» рус-төрек фильмында төп рольне башкаручы, яулап алулардан баш тарту һәм Казан ир-атларының төрекләрдән ни өчен яхшырак булуы турында.

– **«Восток-Запад» фильмын төшерү фикере миңа башта шактый авантюр булып тоелды, чөнки ул безнең илләр арасындагы каршылыкның иң кызган вакытына туры килде.** Халыклар бер-берсе белән каршылыкта тормый, ә менә фильмга килсәк, сәяси мәсьәлә шактый уңайсызлык тудыра иде. Мин һәрвакыт безнең тамашачының аңлавына һәм бу вазгыятьнең уңай чишелешенә өметләндем һәм, Аллага шөкер, өметләрем юкка булмаган. Төркиядә соңгы төшерүләр вакытында без татуланышу турында ишеттек, барысы да үз урынына кайтты, һәм, илләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең җайлануына дәлил буларак, безнең беренче рус-төрек сериалы экранга чыкты.

Әлбәттә, кино төшергәндә без, актёрлар, арасында үзара аңлашуларда кыенлык тумый калмады. Аднан Котч (төп ир кеше ролен уйнаучы) төрекчә сөйләшә, мин – русча, әмма без, үз системабызны уйлап табып, ул кыенлыкны җиңдек: икебезнең дә текстларны ятладык та, шулай остарып киттек.

Гомумән, сериалны эшләгәндә, минем төрекләргә мөнәсәбәтем үзгәрде. Россиялеләрнең күбесе кебек үк, мин дә Төркияне курортлар иле буларак кабул итә идем. Без бит төрекләрне нигездә кунакханәләрдә генә күрә идек. Моңа кадәр минем төрек актёрлары һәм бигрәк тә андагы гади халык белән аралашканым булмады. **Аларның рус әдәбиятын яхшы белүләре мине чын мәгънәсендә гаҗәпләндерде.** Миңа исә аларның мәдәнияте турындагы белемнәремнең бик сай булуы өчен кайчакта оят та булгалады. Төрекләрдә актёрлар мәктәбе бик көчле. Өлкән буын булсынмы, яшьләрме – бик яхшы актёрлар бар аларда. Барысы да шундый музыкаль, нечкә күңелле, хисчән. Мин алардан эштә экспрессия көткән идем, кайбер күренешләрдә Аднан, русларда еш очраганча, кызып китәр дип уйладым, ләкин ул шулкадәр нечкә итеп, хисләргә бирелеп, җанын биреп уйнады. Партнёрымнан уңдым мин.

Шәрыкка карата миндә аерым бер мөнәсәбәт – соклану барлыкка килде. Анда барысы да шундый колоритлы, сусыл, яндыра торган – ризык булсынмы, кеше мөнәсәбәтләреме.

Миңа шәрык гаиләсе культы – өлкәннәргә хөрмәт, традицияләргә ихтирам, гаиләнең бердәмлеге, барысын да киңәшеп, бергә хәл итүләре бик ошый. Безнең илдә болар кайчак нык җитешми. Мин Аднанның зур гаиләсен күзәттем, алар фильмны төшерү мәйданына да килделәр. Мондый җылы мөнәсәбәтләр бик кадерле. Казанда да шулай. Монда мин беренче генә тапкыр, әмма шул ук шәрык колоритын тоям.

Бу «шәрык» миңа хәтта якынрак та, чөнки биредә мин телне, уйларны, хисләрне, шаяртуларны аңлыйм... Миннән еш кына, фильмдагы кебек шәрык ир-егетен ярата алыр идегезме, дип сорыйлар. Әгәр мин телне аңламыйм, аның ничек уй-фикерләвен тоймыйм, шаяртуларына төшенмим икән – ай-һай, булмастыр. **Әмма шәрык ир-егетләре Төркиядә генә түгел, алар Татарстанда да бар бит, татарстанлылар белән уртак тел табу миңа күпкә җиңелрәк.** Балачактан ук иң якын дустым татар кызы иде. Шуңа күрә мин татар халкы традицияләре һәм кухнясы белән яхшы таныш. Дустым Динараның әнисе һәм әбисе еш кына бәлешләр, өчпочмаклар белән сыйлыйлар иде, аларны бик яратам. Ә татарча азуны еш кына үзем дә пешерәм.

Ике вакыйганы – фильмның премьерасы күрсәтелү һәм шәһәр буйлап экскурсияне – берләштерә алу мине гаять шатландырды. Биредә заманча биналар белән иске йортларның архитектурасы үзара ярашып тора, шуңа сокланам. Кремльдә булдым, яңа ЗАГСның күзәтү мәйданында йөрдем, монда барысы да матур, киң колачлы, төпле, мөнәсәбәтләр – кунакчыл.

Быел минем дусларым артты – төрекләр арасында да, татарлардан да. Дагыстанда, Украинада да дусларым бар. Мин бит тумышым белән Украинадан, Луганск өлкәсеннән – чын сугыш та, мәгълүмати сугыш та барган җирдән. Моны тою, яңалыклардан ишетү һәм күрү җанны бик әрнетә.

Шуңа күрә мин, блондинка кебек әйтә бу дип бәяләүчеләр булса да, бөтен дөньяда халыклар дуслыгы һәм тынычлык яклы. Мин кайчан да булса барыбыз да бер телдә аралашырбыз һәм бер-беребезне ярты сүздән аңларбыз, дип ышанам. Яулап алуларга табигый омтылыш юкка чыкканнан соң, бу, һичшиксез, булыр – без цивилизацияле илләрдә яшибез бит, ә кешеләрнең күпчелеге белемле, димәк, сугышларны бетерер вакыт та җиткәндер.

Тынычлыкта, татулыкта, мәхәббәттә яшәр вакыт инде. Мәхәббәт ул милләткә дә, нинди катламнан булуыңа да карамый – ул бары тик җиңә һәм шул гына. Очкын чәчрәп китә дә, бер-береңә тартылу барлыкка килә, аннан тарих пәйда була – болар барысы да милли һәм башка барлык киртәләрдән өстен.

Бу бөтен матурлыгы белән балкыган мәхәббәт: балаңа, әтиәниеңә, туган илеңә, яраткан кешеңә. Һәм берниндиди сугышка да урын юк монда.

Александр Эшкинин фотолары.

«Восток-Запад» рус-төрек фильмыннан күренеш. Евгения Лоза, Аднан Котч.

PRESSA.RU

«РУСЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ, ТАТАРЧА ҖЫРЛЫЙБЫЗ, ҮЗБӘКЧӘ ЯШИБЕЗ»

Үзбәкстанда 300 мең татар яши! Заманында алар бөтенләй дә 750 мең булган. Әмма хикмәтнең санда гына түгел, сыйфатта да булырга тиешлеге көн кебек ачык. Шуңа да «Татарстан» журналы Үзбәкстан татарларының баш аксакалы Рим Гыйниятуллиннан шулкадәр татарның якынча ничә проценты туган телендә иркен сөйләшә белә, дип кызыксынды.

Фото: Александр Эшкинин, prtuz.tatarstan.ru

Автор:
Линар Закиров

ҮЗБӘК ГАЗЕТАСЫН ТАТАР ЧЫГАРГАН

Үзбәкстан татарлары тарихи ватаннары – Казанга үзләренең сәнгать җәүһәрләрен күрсәтү максаты белән килде. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс Тукаев әйтүенчә, республика тамашачысын төрле төбәкләрдә, илләрдә яшәп иҗат итүче сәнгать коллективлары, артистлары белән очраштыру өчен, аларны Казанга китертәләр. Новосибирск, Омск, Төмән, Чиләбе, Ульяновск, Иваново өлкәләре, Пермь крае, Чувашия, Коми, Башкортостан республикалары, Мәскәүдән килгән милләттәшләребез иҗади имтиханны узды инде.

Үзбәкстан татарлары, республикада бер атна кунак булып, Әтнә, Арча, Болгар җирлекләрен карадылар, үзләрен дә күрсәттеләр. Казанда милләттәшләребез Тинчурин театрында имтихан тотты.

– Үзбәкстан – эшчәнлегебез, тарихыбыз һәм мәдәниятебез өчен бик мөһим төбәк. Бүген анда 300 меңләп татар яши. Башка илләр белән чагыштырганда, бу зур сан. Финляндиядә – бер меңләп, Кытайда – биш меңгә якын, Төркиядә 25 мең милләттәшебез гомер ки-

черә. Татар оешмалары Ташкентта гына түгел, Сәмәркандта да, Бохарада да, башка шәһәрләрдә дә бар. Уннан артык төбәктә Сабантуйлар оештырыла. Үземнең катнашканым юк, ләкин күргән кешеләр, Үзбәкстандагы Сабантуйлар турында хәйран калып сөйли, андый бәйрәм хәтта Казанда да юк, диләр, – дип сөйләде Марс Тукаев.

Үзбәкстан белән Татарстан арасындагы бәйләнешләрнең тамыры тирәндә. Казан ханлыгы алынганнан соң, дини белем алу өчен, милләттәшләребез Бохарага, Сәмәркандка бара. Шиһабетдин Мәрҗани һәм башка дин әһелләрен әзерләп чыгарганы өчен генә дә Үзбәкстан җирләренә баш ияргә тиешбез. Чукындырудан качып киткән татарлар да күп анда. Үз чиратында, милләттәшләребез дә Россия белән Урта Азия арасында күпер вазыйфасын башкара, шул төбәкне күтәрүгә зур өлеш кертә. 27 июнь – Үзбәкстанда матбугат көне. 1906 елда «Тәрәккый» дип аталган беренче үзбәк газетасын милләттәшебез Исмәгыйль Габитов нәшер итә башлаган.

ИКЕ МЕҢ ТАТАР УЯТЫП ҖИБӘРДЕ

Үзбәкстан татарлары катнашында матбугат очрашуы да оештырылды. Делегацияне Үзбәкстан татарлары иҗтимагый-мәдәни агарту үзәгенең аксакаллар шурасы рәисе Рим Гыйниятуллин җитәкләде. Аның никтер гел русча сөйлисе килде. Хәтта журналистлар белән очрашуда ул: «Миңа татарча сөйләргә киңәш ителсә дә, берничә минут рус телендә сөйләргә рөхсәт итәрләр, дип уйлыйм», – диде.

Сөйләвенчә, Үзбәкстанда барлык милләтләр бертигез хокуклы, берсе дә кысрыкланмый. Рим Абдуллович белми әйтмәс. Ул заманында туган-даш республиканың мелиорация һәм су хуҗалыгы министры, соңыннан премьер-министр урынбасары булган.

– Без кемнедер шаккатырырга килмәдек. Татарстан бөтен дөньяга җырчылар, биючеләр һәм башка төрле сәнгать әһелләрен тәрбияләп чыгара. Сезгә алып килгән концертларыбызда хилафлыклар булса, алдан ук гафу үтенәм. Без тарихи ватаныбызга шатлыгыбыз белән уртаклашырга, Казанның матурлыгына сокланырга дип килдек, – диде ул.

Рим Гыйниятуллин Үзбәкстан татарларының яшәешен бер җөмлә белән тасвирлады: русча сөйләшәбез, татарча җырлыйбыз, үзбәкчә яшибез.

– Татарстанның бер районында 50–60 мең кеше яши, диләр. Шулай булгач, бездә Татарстанның 5–6 район халкы кадәр кеше гомер кичерә. Үзбәкстанда татар мәктәпләре дә, югары уку йортларында татар теле факультетлары да юк. Шушы шартларда телебезне, көйләребезне ничек саклап кала алганбыз икән, дип хәйран калам. Димәк, бездәге татарларның тамыры бик көчле икән. Башка халыкларны беркайчан да дошман күргәнебез булмады. Бер дәүләт, бер халык булып яшибез, – диде аксакал.

Бу урында «Татарстан» журналы хәбәрчесе Үзбәкстанда яшәүче күпме милләттәшебезнең татарча камил сөйләшә алуы белән кызыксынды.

– Бездәге татарның 70 проценты, ягъни урта һәм өлкән буын кешеләре туган телдә аралаша. Яшьләрдә татар теле белән кызыксыну әллә ни сизелми. Ә Казанда татар яшьләре кайсы телдә сөйләшә? Күргәнегез бармы? – дип сорады бездән олпат кунак.

– Күргән дә, ишеткән дә бар, – дидем. – Шул ук вакытта Үзбәкстан урамнарында татарча сөйләшүчеләрне ишеткәнегез бармы?

– Әлбәттә. Милли чараларга килүчеләрнең 80 проценты бер-берсе белән татарча сөйләшә. Татар туйлары татарча үтә. Бу да күрсәткеч. Иртән Казанның Кремль яр буенда йөргәндә, татар егет-кызларының русча сөйләшеп баруларына игътибар иттем. «Татарча белмисезме әллә?» – дип сорадым. «Беләбез, ләкин аның кирәге юк бит», – дип җавап бирделәр. Моннан 30 ел элек беркем татарча сөйләшми иде. Ике милләттәшебез туган телдә аралашып китсә, яннарындагы рус кешесе: «Русча сөйләш», – дип кисәтү ясый иде. Хәзерге көндә Казанда шулкадәр кешенең татарча сөйләшкәненә сөенергә кирәк. Дөньяда җиде миллион татар яши, дип исәпләсәк, 90нчы елларда Казанда туган телебездә сөйләшеп, аны саклап калган ике мең кешегә рәхмәт дип әйтергә кирәк. Алар безне уятып җибәрде, – диде Рим Абдуллович.

ЯШЬЛӘР ҮЗБӘКСТАНГА КАЙТМЫЙ

Рәйхан Мәннапова Татарстанның Шөгер районында туып-үсә, Казан консерваториясен тәмамлый. 35 ел элек Ташкентка барып төпләнә, шунда кияүгә чыга, балалар таба. Музыка училищесында студентларны җыр-моңга өйрәтә. Ун ел элек аны Үзбәкстан дәүләт радиосының татар-башкорт редакциясенә тапшырулар эшләргә чакыралар.

– «Бәллүр чишмә» тапшыруы атнага өч мәртәбә, яртышар сәгать эфирга чыга. Татар җырлары, күренекле шәхесләребез турында сөйләп, замандашларны да онытмыйм. Татар моңын үз балаларыма да, студентларыма да сеңдерергә тырыштым. Кызганыч, яшьләр татарча белми. Курслар ачтык, балалар өчен түгәрәкләр дә оештырдык. Сөйләм телен генә өйрәтеп, тиешле нәтиҗәгә ирешеп булмый, иркен сөйләшер өчен грамматиканы белергә кирәк, – диде Рәйхан ханым. Милли мохиттә киңкырлы эшчәнлек алып барганы өчен, аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелә. Ни кызганыч, Үзбәкстандагы әлеге радионы Интернетта тыңлап булмый.

Рәйхан ханым татар телен өйрәтү курсларын өч ел үзе алып бара. Бу-

PRESSA.RU

генге көндә укучыларының күбесе Казанга күченеп киткән.

– Безгә телне тирәнтен белгән укытучылар кирәк. Бу хакта Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров белән дә сөйләштем, Яшьләрегезне безгә җибәрегез. Аларны татар теле бүлегендә укытып, кабат сезгә җибәрербез, диде ул, – дип сөйләде Рәйхан Мәннапова.

Шушы мизгелдә сөйләшүгә Рим Гыйниятуллин кушылды:

– Укыту – дәүләт эше, якшәмбе мәктәбе белән генә туган телне саклап калып булмый. Үзбәкстанда дәүләт теле берәү генә, рус мәктәпләренең яртысы ябылып бетте. Юкса, руслар һәм татарларның артында торган көчләрне чагыштырырлык та түгел. Казанга киткән балалар Үзбәкстанга кайтмый инде, анда укытырга мәктәп тә, хезмәт хакы да юк, – диде.

Башкалабызның югары уку йортларында Үзбәкстаннан килгән йөзләрчә студент белем ала. Тарихи ватаннарында калып, яхшы эшкә урнашучылар да байтак.

Татарстанның атказанган артисты Фирүзә ханым Халдарова Ташкентта туып-үсә, әнисе – Татарстаннан. Фирүзә ханым үзенең кызын, ана телен онытмасын дип, Казан федераль университетына укырга бирә. Быел инде ул магистратурага кергән.

– Татар егетенә кияүгә бирергә дә ниятлибез, – дип елмайды әни кеше.

ТУЙДА ЯРТЫ МЕҢ КЕШЕ КАТНАША

Римма Гыйззәтуллинаның әнисе – татар (Самарадан), әтисе – башкорт (Уфадан), ә үзе Ташкентта туган. Кечкенә чакта өйләрендә күбесенчә татар теле яңгыраган. Римма ханым үзбәкчә дә сөйләшә, Ташкент мәктәпләренең берсендә рухи-агарту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли ул. Үзбәк – дәүләт теле булганга, документ эше дә фәкать шул телдә алып барыла.

- Кечкенә чакта туганнарым белән җәй саен, Самара өлкәсендәге Иске Җөрәй авылында яшәүче әбиебез янына кайтып, татар телен шунда да отып кала идек. Ул безне: «Болар татарча белми икән», – дип, үз итеп орыша да иде. Тик Ташкентка кайткач, гаиләдән кала, бөтен җирдә русча сөйләшәләр, – диде Римма ханым.

Ташкент дәүләт музыка педагогика институтына укырга кергәч, ул 19 яшендә «Дуслык» татар ансамбленә языла. 1990нчы елда Ринат Ибраһимов аларны Казанга чакыра. Римма ханымның тарихи ватанына беренче баруы була бу. Булачак ире Рәмзил белән «Дуслык»та танышып, 2000 елда «Болгар» ансамблен оештыралар. Бик күп баланы җырларга өйрәтәләр.

Рәмзил әфәнде читтә туса да, әти-әнисе белән Балык Бистәсе районына кайтып, шунда үсә. Үзбәкстанда яши башлагач, ул Римма ханыма, Татарстанга кайтып төпләник, дип тә карый, әмма әңгәмәдәшем әти-әнисен ташлап китәргә теләми. Алай да Балык Бистәсендә торучы туганнарына кунакка еш кайталар. 2010 елда икесе бергә «Татар моңы» конкурсында катнашып, лауреат булалар.

– 12 яшьлек улыбыз да музыканы ярата, әмма заманчаларына өстенлек бирә. Ул безнең концертларда катнаша. Бергәләп татар туйларын оештырып, милли гореф-гадәтләребезне күрсәтәбез, кияү белән кәләшне бал-май, чәкчәк белән сыйлап түрдән уздырабыз. Ә үзбәкләрдә килен, мәҗлескә килеп керешкә, бөтен кеше алдында баш ия, – дип сөйләде әңгәмәдәшем.

Баксаң, үзбәкләр туйны берничә көн бәйрәм итә, һәм мәҗлескә 500ләп кеше килә икән.

– Шулкадәр халыкны сыйдырырлык залларны каян табып бетерәләр? – дим, гаҗәпләнеп.

– Бездә туй заллары зур, иркен. Бәйрәмдә үзбәкләр озаклап бии. Малайларның 12 яшь тулган көнен зурлап үткәрәләр. Үзбәк халкы алга карап эш итә. Бала тугач, аны өйләндерәсе, машина, фатир сатып аласы бар, дип акча җыя башлыйлар. Россиядә яшьләр туй үткәрмичә дә яши алса, Үзбәкстанда бу йоланы башкармыйча калу мөмкин түгел, – дип аңлатты Римма Гыйззәтуллина.

Үзбәкстанда уза торган Сабантуйларда башка милләт вәкилләре дә катнаша. Тамашада аларның милли җыр-биюен дә тәкъдим итәләр. Көрәшне аеруча үзбәкләр үз итә, соңгы елларда баш батыр булып алар кала икән. Ә татарлар туры баганага менүдә җиңүче кала.

– Безнең як кояшлы булганга, үзбәк хатыннары, ялтыравык киемнән йөреп, кояш кебек балкырга ярата. Заманча базарлар, супермаркетлар күп, элеккеге «восточный базарлар» юк инде. Кавын-карбыз бездә күпкә очсыз. Үзбәкләр татарларны ярата. Динебез, гореф-гадәтләребез уртак. Ике халык та Корбан, Рамазан гаетләрендә, бала туса да, кеше үлсә дә, мулла чакыртып, кеше җыя, – дип сөйләде әңгәмәдәшем.



«АЛМА-ХӨРМӘ АШАРМЫН ДА КАЙТЫРМЫН»

Рәмзия Бикбулатова Кайбыч районы Мөрәле авылында туа. Шунда 8 класс укып, Казанның тегү училищесын тәмамлый. Үзбәкстанга башта апалары, аннары 21 яшендә үзе дә күченеп китә.

– Мине монннан беркем кумады. Берәрсе кияүгә алам дисә, бәлки, Казанда калган булыр идем. Үзбәкстанда бераз алма-өрек ашармын да кайтып китәрмен, дип уйлаган идем. Шунда Башкортостанның Иглин районы кешесе Мөгаллим исемле егеткә тормышка чыктым. 44 ел бергә яшибез. Иремнең эше командировкаларга бәйле иде, шуңа да шәһәрдән шәһәргә күченеп йөрдек. Һәр барган җирдә татарларны барларга тырыштым. Бохарада Рәфис Уразаев исемле Сарман егете белән танышып, өч-дүрт ел, мәҗлесләр оештырып, җырлап йөрдек. Мин бит 6–7 яшемдә тальянда уйнарга өйрәнеп, авылның беренче гармунчысы идем, – дип сөйләде әңгәмәдәшем.

26 ел Беговатта яшәп, 2000 елда Гыйзәтуллиннар Чирчик шәһәренә барып төпләнә. Рәмзия ханым, хакимияткә барып, татар диаспорасының барлыгы белән кызыксына. Аңа, Кырым татарларын күздә тотып, татарлар бар, диләр. Әмма Рәмзия ханым татар-башкорт диаспорасы белән кызыксынуын җиткерә. Бар, әмма берләшмәне җитәкләүче кеше юк, дип җавап бирәләр. Шуннан соң ул матбугатта игъланнар бастырып, милләттәшләрне барлый. Бергәләп Габдулла Тукай, Муса Җәлил көннәрен, Казанның меңьеллыгын үткәрәләр. 2011 елда Рәмзия ханыма Татарстанның атказанган артисты исеме бирелә.

Үзбәкләргә килсәк, алар башта Нәүрүз, аннары Сүмәләк бәйрәмен зурлап үткәрәләр. Әңгәмәдәшем сүмәләк ясау тәртибен дә аңлатты: уҗым итеп үстерелгән бодайны юалар, иттарткычтан биш мәртәбә чыгаралар. Килеп чыккан измәне марля аша сөзеп,сыеклыкка он кушалар да, төбенә утырмасын өчен, тәүлек буе бутап торалар. Мондый мәҗлестә берничә хатын-кыз катнашып, чиратлашып бутыйлар. Шикәр салынмаса да, сүмәләк баллы килеп чыга икән.

– Үзбәкләр туган-тумачасы белән бик якын. Берәр бәйрәм булса, барысы бергә җыела. Егетләре, чиста, пөхтә, уңган булганлыклары өчен, татар кызларына өйләнергә тырыша. Үзбәк кызлары да бик чибәр. Аларның ирләргә карата хөрмәте зур. Үзбәкстанда бик сирәк аерылалар. Яшь гаиләне ата-аналары тотып тора, шунысы яхшы. Күрше-тирәмдәге үзбәкләр, әз генә күренми торсам, Рәмзия апа, кая югалдыгыз, дип сорашалар. Кайбер татар яшьләре дә саф үзбәкчә сөйләшә. Улыбыз Наил Краснодарда яши. Безгә эти белән әнкәй, дип эндәшә, – дип сөйләде Рәмзия Гыйззәтуллина.

«АНА ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШ!»

Үзбәкстан татарларының Кәрим Тинчурин театрында тәкъдим иткән концертын да тамаша кылдык. Рим Гыйниятуллин, сәхнәгә чыгып:

– Әссәламегаләйкем, газиз дуслар! Исәнмесез, кадерле туганнар! Здравствуйте, дорогие земляки. Мин татарча да, үзбәкчә дә сөйләшә беләм. Тик монда утыручыларның күбесе татарча аңлап бетермидер, дип уйлыйм. Рөхсәт итсәгез, мин русча сөйләр идем, – дигәч, берничә тамашачы:

– Ана телендә сөйләш! – дип кычкырды. Үзбәкстан кунагы, тавышын күтәреп:

– Сез театрда утыргач, театрда утырыгыз. Миңа замечание бирмәгез, – диде. Халык, күрәсең, аның сүзен куәтләп, көлә-көлә, кул чаба башлады. – Микрофонны миңа бирделәр. Рус теле – Россиянең дәүләт теле. Бик кыланасагыз, хәзер чакырырбыз (кемне чакыруын әйтмәде. – **Авт.**) да, башка җиргә барырсыз, – диде.

Рим Абдуллович залда утырган тамашачыга ике теләген җиткерде. Боларына, чыннан да, кул чабарлык иде.

– Үзбәкстанда яшәүче милләттәшләребез бер-берсен, Себер татары, Әстерхан татары, мишәр, дип бүлми, керәшен дә, нугай да, димибез. Дошманнарыбызның аз түгеллеген белеп торабыз, алар безне бүлергә, таркаулык тудырырга тели. Галимнәр дә башыбызны бутый. Үзбәкләр дә, буленгәнне бүре ашар, диләр. Үзебезне бүлгәли башласак, иртәгә вак халыкка әйләнәчәкбез. Бу теләк күбесенчә үзебезгә кагыла.

Аксакалның икенче фикере милли бәйрәмебезгә кагылышлы иде:

– Казанда Сабантуйны каядыр урманга алып чыгып, халыкны яшереп кенә үткәргәч, нинди милли бәйрәм булсын, ди ул. Кыен булса да, булмаса да, Үзбәкстанда төп Сабантуйны Ташкент үзәгендә үткәрәбез. Бу бит татарларның бәйрәме, дип, хакимият тә безнең омтылышны хуплый. Ә Казандагы Сабантуй VIP-бәйрәмгә охшап кала. Машинаң булса, бара аласың. Барсаң да, адым саен полиция тора, барып та, карап та булмый. Бу безнең милли бәйрәм, дип Хөкүмәткә әйтегез, – дип гозерен җиткерде кунак.



PRESSA.RU

Аның башкару манерасында да, үз-үзен тотышында да, киенү рәвешендә дә, хәтта аралашуында да аерым бер зәвык, затлылык бар. Һәм – сер. Үзенә илтүче сер пәрдәсен чак кына ачарга рөхсәт итә дә, барыбер дә шул сер булып кала бирә ул...

«ЯРАТМЫЙЧА... ҖЫРЧЫ БУЛЫП БУЛМЫЙ»

Луиза Янсуар
әзерләде

- Мин гаиләдә төпчек бала. Миңа кадәр дә әтием белән әнием абыйны, апаны музыкага тартып караганнар. Әмма алар сәнгать юлыннан китмәделәр. Минем очракта хыяллары, ниһаять, чынга ашкан, күрәсең. Тирә-юньдәгеләрнең: «Кызыгыз матур җырлый», – дигәннәрен хәзер дә искә алалар. Әмма әти дә, әни дә – эш кешеләре, минем белән шөгыльләнеп утырырга вакытлары аз иде. Ә мин гел шыңшып йөрим, нидер көйләп. Һәм миңа 6 яшем тулгач, алар түзмәделәр, мине музыка мәктәбенә алып бардылар.

Беренче чыгышымны бик яхшы хәтерлим. Анда бит болай гына узып булмый, комиссия алдында хисап тотасы бар. Берничә бирем үтисе. Миңа ул чакта Дмитрий Кабалевскийның «Наш край» җыры бик ошый иде. Шуны башкардым да. Комиссия чыгышымны әйбәт дип тапты, берсүзсез кабул иттеләр.

Мин җыр эчендә үстем. Әнием гомере буена заводта эшләде, әтием машина йөртүче иде. Югыйсә, сәнгатьтән ерак торган кешеләр дә шикелле, әмма өйдәге бер мәҗлес тә, бер җыен да җырсыз узмый иде. Шул чор хитларын бергәләшеп өстәл артында җырлаулары әле дә колагымда яңгырап тора.

Кухняда «Татарстан» радиосы тәүлек буена сөйләп торды. Концертларны бик яратып тыңлый идем. Ул чорда инде өйләрдә телевизорлар да пәйда була башлады. Зәңгәр экраннан караган концертлар аеруча әсир итә – башкаручының үзен дә күрәсең бит. Александра Пахмутова, Иосиф Кобзон, Лев Лещенко, София Ротару... – Мәскәүнең Колонналар залыннан тапшырылган бу концертлар миңа бик зур йогынты ясады балачакта. Һәм, әйтүләре буенча, әле «музыкалка»га кадәр үк мин шактый чиста җырлаганмын.

Музыка мәктәбе беренче зур сынау булды. Анда уку җиңел түгел. Әмма әйбәт педагог туры килсә, киләчәктә җыр сәнгатенә кереп китүең бик ихтимал. Миңа гомерем буена, уку чорымда, яхшы педагоглар туры килде. Хорны бик ярата идем. Гомумән, музыка мәктәбенә баруны түземсезлек белән көтеп алуым хәтердә. Кулымнан килсә, барлык балаларга да музыкаль белем бирүне тәэмин итәр идем. Заманында аксөякләр балаларын кече яшьтән музыкага өйрәткән, бик яхшы традиция булган, минемчә.

Музыка ул – дисциплина һәм җаваплылык. Бу өлкәдә кечкенәдән һәрбер карарың, кылган гамәлләрең өчен үзең җавап бирергә өйрәнәсең. Миңа, мәсәлән, әнием артка юл калдырмады. Музыка мәктәбенә йөри башлагач, болай диде: «Без сиңа фортепиано алабыз алуын, әмма бары тик музыканы ташламыйсың дигән

Фотолар Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе һәм Резидә Галимова архивыннан

шарт белән генә». Менә шулчакта мин, әле кеп-кечкенә генә бер кызчык, тормышымда бик тә әһәмиятле карар кабул иттем. Һәм аннан соң ул карарым өчен беркайчан да үкенмәдем.

Музыка мәктәбе мине хезмәткә, тырышлыкка өйрәтте. Хәзер дә бер генә чыгышыма да җиңел карый алмыйм. Артист кеше өчен бик кирәкле сыйфат – тырышлык. Тырышлык булмаса, талантны да әрәм итәргә мөмкинсең. Артистны чын-чынлап тырышлык кына үз һөнәренең остасы итә.

Без Мәскәүне сайладык. Фортепиано һәм вокал буенча музыка училищесын тәмамлаганнан соң, педагогым: «Резидә, сиңа югары уку йортын да тәмамларга кирәк», – диде. Мәскәү куркытса да, шунда – Россия музыка академиясенең Гнесиннар исемендәге Югары мәктәбенә юл тоттым. Минем кебек җырларга, музыкаль белем алырга теләүче яшьләрнең күплеген күреп шаккаттым. Владивостоктан Архангельскига кадәр – бөтен Россиядән җыелган яшьләр бит ул! Мин бу кадәр халык ташкыны булыр дип уйламаган идем.

Татарлар бик бала җанлы халык. Бу нииндидер үзенә бер, рациональлектән ерак торган хис – баланы, инде балигъ булгач та, сабыйларча күреп сөю, аны кайгырту. Мин аны Мәскәүгә укырга киткәндә татыдым. Хәзер инде менә үз кызым үсеп җитте... Кайда торыр ул, ашамый-эчми йөрмиме икән, өстенә җылы кигәнме, дип хафаланабыз... Без, гомумән, бик хисле халык.

Күпләр төшеп калды. Өч сайлау турыннан узарга кирәк иде. Концертмейстер белән программа сайлана да, әсәрләрдән комиссия әйткәнен башкарасың. Ул операдан ария булырга мөмкин, романс, җыр. Нигездә, 5-6 әсәр әзерләнә. Шуннан соң исемлекләр эленә, алардан карап, үтү-үтмәвеңне беләсең. Монда осталык ягыннан гына түгел, ә характер, рух ныклыгы ягыннан да сынау узасың. Кайберәүләр бары тик нык дулкынлану нәтиҗәсендә генә төшеп калырга да мөмкиннәр. Эләксәң, зур шатлык, әлбәттә.

Уку процессы – ул үзеңне зур тормышка һәм профессиональ сәхнәгә әзерләү вакыты. Аның вакытлыча булуын һәм зур мөмкинлекләр чоры икәнлеген дә онытмаска кирәк. Мин укыган елларымда күп нәрсәне өйрәнеп, күп нәрсәне сеңдереп кала алдым. Үзеңне тәрбияләү дә мөһим. Аннары моңа вакыт булмый, бөтен нигез укыган вакытта салына.

Кеше бар яктан да белемле һәм киң карашлы булырга тиеш. Сәнгать әһеле – бигрәк тә. Академиядә укыганда, без музыка белән генә шөгыльләнми идек, ә билгеле бер чорны яхшырак белер өчен, музейларга, күргәзмәләргә дә йөрдек. Ничек син барокко музыкасын

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Татарстанның халык артисткасы Резидә Локман кызы Галимова 1966 елның 26 октябрендә ТАССРның Чистай районында туа. Түбән Камада С.Сәйдәшев исемендәге музыка училищесын тәмалаганнан соң, Мәскәүдәге Россия музыка академиясенең Гнесиннар исемендәге Югары мәктәбенә укырга керә. Күпсанлы халыкара конкурслар лауреаты. АКШ, Франция, Италия, Австрия, Финляндия, Төркия, Кытай, Кипр, Украина, Казахстан, Португалия һ.б. илләрдә гастрольләрдә була.

Резидә Галимова – ТРның Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең халык уен кораллары дәүләт оркестрының солист-вокалисты. Лирик сопрано иясе. Төрле жанрдагы әсәрләр башкара: опера классикасы, борынгы классик романс, дөнья халыкларының җырлары. Оркестрның мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп яшендәге балалар, студентлар өчен оештырылган абонемент концертларында Р.Н Корсаковның «Снегурочка» операсыннан Снегурочка ариясен, М. Глинканың «Руслан и Людмила» операсыннан Людмила каватинасын, Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан Алтынчәч ариясен һ.б. башкара.

Төркия, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Казахстан, АКШ, Украина һәм Россиянең татарлар күпләп яши торган төбәкләрендә узган Сабантуйларда катнаша. Хакимият делегацияләре составында җырчы Һиндстанда, Германиядә, Финляндиядә, Швециядә, КХРнда, Латвиядә, Эстониядә, Украинада чыгышлар ясады. 2013 елның апрелендә Европа Сараенда (Страсбург, Франция) концерт бирде.

PRESSA.RU

аның архитектурасын белмәгән килеш бар тирәнлегендә тоясың, ди. Бу мөмкин түгел. Алар бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгән. Йә булмаса, шул ук импрессионизм… Менә шуларны тоярга өйрәнмәсә, артист чын мәгънәсендә югары зәвыклы сәнгать кешесе була алмый.

Мәскәүдә калу теләге булмады. Максатым – укуны тәмамлау һәм монда кайтып төпләнү иде. Казан миңа көннән-көн күбрәк ошый бара – ул үзенә күрә яңарыш чорын кичерә кебек.

Гаиләм һәм дусларым белән Казансу буенда йөрергә яратам. Моннан Казан Кремленә һәм серле Сөембикә манарасына бик матур манзара ачыла. Композитор Резеда Әхиярованың шагыйрь Разил Вәлиев сүзләренә иҗат ителгән «Сөембикә» җырын бик яратып башкарам, мөмкинлек булганда, аны концерт программасына кертми калдырмыйм. Кызыма да Сөембикә дип исем куштым. Килгән кунакларның шәһәребезгә соклануын күргәндә горурлык хисләре уяна.

Мин кызыксынучан кеше. Хәзер дә театрга, күргәзмәләргә йөрим. Гадәттә, кызым белән барам. Концертлар, юбилей кичәләре турында инде әйтеп тә тормыйм!

Премьералар яратам. Яңа чыккан фильмнарны. Миңа киноны зур экраннан карау ошый. Аның дискларда чыкканын, Интернетта таралганын көтеп ята алмыйм.

Интернет мине мавыктырмый. Телефондагы тиз аралашуны тәэмин итә торган ниндидер кушымталар – анысы әле бер хәл. Алар вакытны экономияләргә булыша. Әмма лента карап, озаклап социаль челтәрләрдә утыру – минем өчен түгел.

Артист әйбәтләп ял итәргә тиеш. Йокысы туйганчы йокларга. Безнең эш бит үзенчәлекле: башкаларныкы тәгәлләнгәндә башлана гына. Гадәттә, кеше үз эшеннән арып-талып, безне карарга килә. Ә аңа кадәр артистка, аны тыңлап җан рәхәте алырга килгән тамашачы алдында тиешле дәрәҗәдә чыгыш ясар өчен, бик озак һәм кат-кат репетицияләр ясарга кирәк. Ул өенә концерт тәмамлангач, төнлә генә кайтып керә. Шуңа да аңа һәм эмоциональ, һәм физик ял кирәк.

Мин хәзер дә сәхнәгә чыгар алдыннан дулкынланам. Бу һәр артистка хас халәт. Һәр чыгыш, бигрәк тә тере тавыш белән җырлаган җырчыга, зур җаваплылык йөкли. Шуңа да син формада булырга, күтәренке рух белән атларга тиеш тамашачы каршына. Ә инде сәхнәгә беренче адымнарыңны атлауга, ул дулкынлану юкка чыга. Син үзең булудан туктыйсың, ә сәхнәдәге образга сеңеп бетеп, ул булып яши башлыйсың.

Позитив энергия бүләк итү – артистның бурычы. Шуңа да мин төшенкелеккә бирелү, газаплануларны кабул итеп бетерә алмыйм. Аеруча – концертларда. Театр артистына, образына, спектакльнең канвасына бәйле рәвештә, бу, әлбәттә, кирәк. Әмма концерт вакытында син үзеңне тыңларга килгән тамашачыга бары тик күтәренке рух һәм якты эмоцияләр генә җиткерергә тиешсең. Ул бит сине тыңлап ял итәргә килә.

Концертлар төрле була. Нинди дә булса тематика белән бәйле, йә булмаса жанр белән. Юбилей концертлары аерым урын алып тора. Мин юбилейларны үз итәм. Андыйларга яраткан артистын, коллективын, яисә композиторының әсәрләрен тыңларга килә тамашачы. Юбилей концертларына аеруча зур җаваплылык белән карарга кирәк, анда син үз чыгышың өчен генә җаваплы түгел, ә башка иҗатчының, йә булмаса тулы бер коллективның абруен, дәрәҗәсен дә төшермәскә тиешсең.

Миңа кайда да, кайчан да рәхәт. Елның барлык фасылларын яратам. Җәй күбрәк якын-якынын. Кояш балкып торса, янәшәдә тагын елга яки диңгез дә булса, бөтенләй бәйрәм. Ә болай… фасылларга, һава торышына бәйле кеше дип әйтә алмыйм үземне.

Ә менә патриот дип әйтә алам. Бу аеруча чит илләрдәге концертларда, делегацияләр белән барып чыгыш ясаганда үзен сиздерә. Татар диаспорасы алдында җырларга яратам. Алар татар артистларын һәрчак зарыгып көтеп ала, бик җылы каршылыйлар. Үз телең, җырларың, милләтең өчен горурлык хисе белән ала күңелне. Һәм бу – зур җаваплылык, дәрәҗә дә, билгеле.

Алкышлар артист өчен – иң зур куаныч. Әсәрне башкарып, бигрәк тә уңышлы башкарып, сәхнә артына кереп киткәндә, эйфория кичерәсең. Кайчакта алкышларны ишетмисең дә. Миңа күп тапкырлар: «Бис! Кабат чакыралар», – дигәннәре бар. Алкышлар җырчының осталыгына гына түгел, кемнең әсәрен башкаруына да бәйле була кайвакыт. Андый вакытта композитор яисә оркестр өчен дә өстәмә шатланасың.

Мин бөтен җырларымны да яратам. Аларны бит озаклап, җентекләп өйрәнәсең, аңа күпме вакытыңны багышлыйсың. Яратмаган әсәрне башкарып булмый. Гомумән, бу профессияне яратмыйча, үзеңне аңа багышлап булмый.

Конкуренция дигән төшенчәгә бик позитив мәгънә салам. Без барыбыз да – бер һөнәр вәкилләре. Бер гримеркаларда киенеп, бер-беребезгә иңдәш, киңәшче булып, гастрольләр вакытында бөтенләй дә бер гаилә булып укмашып йөри торган халык. Ничек инде тату булмыйсың, ди?! Җитмәсә, һәрберебезнең – үз тамашачысы, үз жанры, үз тавышы.

Бар да үзеңнең эчке көйләнешеңнән тора. Син кешегә начарлык теләмисең икән, ул да сиңа күрәләтә торып яманлык эшли алмый. Минем дошманнарым юк, дип әйтә алам. Ә инде көнләшүчеләр бар икән, анысы – аларның шәхси проблемасы. Минем моңа бер катнашым да юк.

Балачагым машинада узды. Ул чакта әле машина бик сирәк кешедә генә бар иде бит. Без исә гел машинада йөрдек. Мин әтинең безне җәяү йөрткәнен хәтерләмим – кайда барасы булса да, һәрчак вакыт таба иде ул. Тагын… аның бер гаҗәеп осталыгы бар иде – берәр җиһазмы ул, келәм-фәләнме, нәрсә булса да, ул аны машинага, һичшиксез, сыйдыра. Хәзер генә ул назланалар берәр кибеттә җиһаз сатып ала башласаң: «О, юк, бу машинага сыймый», – диеп. Шулчакта гел әтине сагынып искә алам.

Хәзер үзем дә рульдә йөрим һәм… йөзә беләм. Шундый ошый миңа машина йөртү һәм йөзү! Кеч-

кенә вакытымда һәм яшь чакта булдыра алмаганымны менә хәзер чынга ашырдым.

Көнбагыш – ярамый, мүк җиләге – хуплана. Без үзебезне бик нык сакларга тырышабыз, билгеле. Шулкадәр тырышабыз ки, кайбер гастрольләр – бигрәк тә салкын чакка туры килсәләр – гримерка һәм сәхнә күреп кенә уза. Туңдырма, чикләвек, көнбагыш – артистка аларның дөньяда барлыгын ук онытырга кирәктер, бәлки. Мин үзем, авырсам, мүк җиләге кайнатмасы эчәм. Кайнаган сөт белән минераль су катнашмасы да ярдәмгә килә.

Гаиләм турында җәелеп китеп сөйләргә яратмыйм. Һәрбер кешенеке кебек үк минем дә үз тормышым. Анысын киң җәмәгатьчелеккә чыгарырга кирәк дип тапмыйм. Сәхнәгә тамашачысы каршына артист Резидә Галимова чыга. Ә инде гримеркада өстемне алыштырып, өйгә кайтып киткәндә, мин гап-гади, гадәти хатын-кызга, ирем өчен – тормыш иптәшенә, кызым өчен – әнигә, әнием өчен – кызына, туганнарым өчен сеңелләренә әверелэм. Һәр нәрсәнең үз урынында һәм үз вакытында булуы яхшы.

Артистта азарт булырга тиеш. Чыгыш ясыйсы килеп тормаган җырчы... андыйлар сәхнәдә озак елларга кала аламы икән, белмим. Юктыр... Бу үзенә күрә бер бәйлелек, яшәү рәвеше, дисәң дә буладыр. Артистның сәхнәгә чыгар алдыннан күзләре янып, йөрәге җилкенеп торырга тиеш.

Россия тамашачысы бөтен жанрларны да үз итә. Классикамы ул, джазмы, шул ук поп-музыка булсынмы. Монда сүз сыйфат турында түгел, ә безнең бар нәрсәне дә кабул итә белүебез турында бара. Һәр яңалыкка әзер булуыбыз, дияргә дә буладыр хәтта. Әйтик, кызым белән без опера тыңларга да йөрибез, Адель концертына да барып кайттык. Ә инде сыйфатка килгәндә... Шулай берсендә әле Сөембикә кечкенә чакта концертта утырабыз. Бер җырчы фальш белән җырлый. Мин инде түзәм, үземчә аклап утырам башкаручыны – мөгаен, бу сәхнәдә юньләп репетиция ясый алмагандыр, фәләндер-төгәндер, дип. Антракт вакытында кызым: «Монда тагын нәрсә тыңларга була?! Китәбез!» – димәсенме. Һәм кайтып киттек. Аның бу сүзләре минем үзем өчен дә зур гыйбрәт булды.

Җырчы тамашачысын хөрмәт итәргә тиеш. Без үзебезне сакларга тиеш, дигәндә, кемдер, бәлки, аны һавалылык буларак кабул итәдер. Әмма сүз башка нәрсә – үзеңә йөкләнгән вазыйфаны бар җаваплылыгы белән тоюың һәм башкарып чыгуың хакында бара. Син – халыкка үзеңнең тавышың аша ул ишетергә теләгән моңны җиткерүче. Шагыйрьгә – сүз, композиторга көй бирелгән. Ә син шуларны яңгыратыр өчен яратылгансың. Шул гына. Һәр кешенең үз урыны бар җир йөзендә.

PRESSA.RU

ТӨНЬЯККА ЮЛ ТОТАБЫЗ...

Кыш – Яңа ел, Раштуа һ.б. күпсанлы бәйрәмнәре, кырыс тормыш шартлары белән үзенә күрә бер сынау. Яз, йокыдан уятып җибәреп, күңелне җилкетә һәм бакчалар-дачаларга каһарманлык кылырга чакыра. Җәй, төрле кыйтгаларга дәшеп, бер-береңне уздыруга корылган яллары, шул ук принципка нигезләнгән уңыш үстерү-җыеп алу рейтингы белән вакытны «урлый». Ә көз «дача сезонын» ябу һәм кышка әзерләнү мәшәкатьләре белән җәлеп итә... Димәк, укыр өчен вакыт нәкъ менә октябрь белән ноябрьдә генә кала да.

Автор:
Луиза Янсуар

Һәм, вакытны бушка уздырмыйча, киттек! Китаплар дөньясына. Бу юлы без Төньякка юл тотабыз...

КАР ТОЙГЫСЫ, ЯКИ БЕЗНЕҢ ЮЛ – КАЙСЫСЫ?

Беренче эш итеп, Питер Хёг дигән Дания авторын тәкъдим итәм. Скандинавия әдәбиятының бүгенге көндә барлык китап фестивальләре, күргәзмәләре лидеры булуын, дөньякүләм китап рейтингларын «шартлатучы» икәнлеген артык сүз күпертеп, искәртеп тору кирәктерме, юкмы... Һәрхәлдә, моны инкарь итеп булмый – шунысы хак. «Millenium» сериясе бездә – иң популяры булгандыр, бәлки. Стиг Ларссон исемен дә ишетмәгән кеше калмады бугай, аеруча «Девушка с татуировкой дракона» фильмы кинотеатрларда күрсәтелә башлагач. Трилогияне, шактый саллы булуына һәм бәясе ягыннан да «тешләшүенә» карамастан, китап киштәләреннән кырып алып бетерделәр. Гауга, фетнә булган очракларны безнең халык шулай үзгә бер ярату белән ярата инде... Әмма Ларссонның «татуировкалы кызы»ннан соң да Скандинавия үз дилбегәсен кулдан ычкындырмады.

Питер Хёг, бәлки, нәкъ менә шул «дулкын»да мәйданга килгән язучы буларак күзалланадыр. Бик мөмкин. Чөнки бездә ул нигездә әнә шул чакта ишетелә башлады. Тыныч кына, сабыр, әмма ни беләндер игътибарны үзенә җәлеп итә торган «үз тавышы» белән. Тынычын-тыныч, әмма бүгенге көндә Хёг дөнья әдәбиятындагы иң эксцентрик фигураларның берсе булып исәпләнә бирә. Беренчедән, моңа аның үз шәхси тормышын тышкы йогынтылардан мөмкин булганча сакларга омтылышы сәбәпчедер, бәлки. Йомылып яшәве. Китап презентацияләре оештырып, шау-шу куптармавы. Китапларның үзләрен дә еллар буена аскезага китеп язуы. Шуннан соң гына, 5–6 елга бер интервью бирергә риза булуы. Телефон номерын бары берничә якын кешесенең генә белүе.

Әйе, Даниядәге кечкенә генә бер шәһәрдә яши. Әйе, хатыны һәм кызларын журналистларның төпченүенә дучар итми һәм фотокамералар балкышы астына куярга яратмый. Әйе, аның адресы йортының ишегендә дә күрсәтелмәгән, ә аңа юлланган корреспонденция турыдан-туры нәширенә тапшырыла. Әйе, шул ук шәһәрдә ул хөрмәт иткән гуру да яши, һәм Хёг аның белән көн саен аралаша. Әйе, ул медитация төшенчәсен сүздә генә сөйләп түгел, ә даими рәвештә көн дә гыйбадәтханәгә барып һәм хөҗрәсендә кылып, гамәлдә белүче. Моннан тыш, Питер Хёгның балачагына, яшьлек елларына караган фактлар да халыкны дулкынландыруын дәвам итә: ятим үскән бала, кече яшендә үк җинаять эшендә тотылган, төрле категорияле уку учреждениеләрендә «тәрбияләнгән». Бер әңгәмәсендә, шул елларга сак кына кагылып үткәндә, ул үзен 14 ел дәвамында түбәнсетүләре, мыскыллаулары хакында сүз кузгаткан иде. Шаккатасың: хәзерге Дания, 70–90нчы еллар җәмгыяте. Һәм менә нәкъ шушы – бүгенге җәмгыятьтә, бигрәк тә кечкенә илләрдә, кешенең ни дәрәҗәдә куркыныч астында булуы, яклауга мохтаҗ икәнлеге хакындагы проблеманы күтәрүе белән киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте дә Хёг. Җитмәсә, ул бу мәсьәләнең балаларга кагылышлы четерекле ягын да ачты, аннан да битәр, олыларның система дигән машина эчендә кемгә әйләнүләрен бар ялангачлыгында күрсәтә алды.

Үзе ул, инде өлкән кеше позициясеннән торып, балачагына бик анык анализ бирә: ялгышкан кешене нәкъ менә балачакта дөрес юлга кертеп җибәрергә кирәк, бу җәһәттән, «тәрбиячеләрем»не аңлыйм, ди. «Алар миңа яхшы булуын теләделәр, шул гына», – дип тә өсти. Әмма аның һәр әсәреннән үзенчәлекле, талантлы, башкаларга охшамаган бала фаҗигасе кычкырып тора, укыганда, тынычлыкны ала, өшетеп җибәрә, каз тәне чыгара. Беренче зур популярлык казанган һәм экраннарга Джулия Ормонд гәүдәләнешендә чыккан «Фрекен Смилла и ее чувство снега» романы аша белә күпчелек интеллектуаллар Питер Хёг дигән язучыны. Һәрхәлдә, күпчелек өчен ул шуннан башлана. Ни өчен интеллектуаллар, дип ассызыклыйм? Чөнки бу әсәрләрнең детектив катламыннан тыш, тирәнрәк өлеше дә бар, нәкъ менә шунысы җәмгыятьтәге ситуацияне анализларга, аңларга этәрә дә. Дөрес, фильмда бу катламны Голливуд традицияләрендә «эреткәннәр», картина күпмедер дәрәҗәдә детектив тарих белән «Секретные материалы» рәве-

шендәге стилизация төсмерен алган. Әмма әсәрне укучылар роман фактурасына кумелгәч, чын мәгънәсендә ләззәт алачак, дип ышанам.

Мин чагыштырып укыдым: мин яши торган кечкенә генә «Татарстан» мәмләкәте һәм Дания. Охшашлыкларга исем-акылым китте: һәр кеше, аның шәхесе, иҗтимагый-мәдәни позициясе – күзәтү астында. Аеруча – милли индентификация төшенчәсе һәм социаль иерархиядә кешенең урыны мәсьәләсе борчый Питер Хёгны. Әтисе Даниянең уңышка ирешкән галиме, табиб, сәяси һәм милли карашлары анык булган җәмәгать эшлеклесе, һәм аңа капма-каршы герой – 37 яшьлек кызы Смилла Ясперсен. Ул да – табиб-гляциолог, галим, әмма диссертация яклап, уңайлы кәнәфиләрдә утыруны кирәк тапмаган, җәмгыятьтәге тәртипләргә авыр яраклашкан, Антарктика бозларының үзенчәлекләрен биш бармагы кебек белсә дә, дистәләгән экспедицияләрдә катнашса да, күкрәк сугып, хакимияткә һәм киң җәмәгатьчелеккә уңайлы хакыйкатьне якларга алынмаган Смилла.

Бик гади генә башланып китә сюжет: өенә кайтып килгән җиреннән Смилла фаҗигагә шаһит була – күршедә яшәүче алкоголик ханымның улы Исайя түбәдән егылып төшеп һәлак булган. Әлбәттә инде, халык җыелган, тикшерүчеләр килгән. Бәхетсез очрак буларак, бу хәл тиешле графага теркәлгән. Детектив төене төйнәлгән, ягъни мәсәлән. Алга таба интрига китә. Смилла, тикшерүчеләрнең ай-ваена карамыйча, түбәгә менә һәм бу хәлнең бәхетсез очрак булмавын белдерә. Бу – криминал, тикшерү эше ачып җибәрергә кирәк, дип бәйләнә барысына да. Һәм, аны ишетергә теләмәүчеләрне инкарь итеп, үз тикшерүен башлап җибәрә.

«Ни өчен бәхетсез очрак түгел дип уйлыйсыз», – дип төпченәләр аңардан. Смилла елмая гына: «Чөнки мин карны беләм». Әйе, Гренландиягә экспедиция вакытында шундагы җирле инуит кабиләсеннән булган ханымга гашыйк булып, аның кыргый рухын авызлыкларга теләп, берни дә барып чыкмагач, кире Даниягә кайтып китәргә мәҗбүр була аның атаклы табиб-әтисе. Ә бәләкәй Смилла әнисе белән кала: ауга йөри, кырыс шартларда яши һәм сирәк очрый торган сәләткә ия була – ул карны һәр күзәнәге белән тоя. Ауга чыкканда, бер генә җигем дә Смилласыз чыкмый, чөнки, иң хәтәр һава шартларында да, өйгә юлны бары ул гына таба ала. Бу – аларның нәселләреннән килә торган борынгы сәләт. «Карның 70 төрле билгеләмәсен беләм», – дип теркәлә аның полициядәге досьесына да, Исайяның үлем сәбәпләрен ачыкларга тырышып, баланың язмышы өчен пошынып йөри башлагач. Бу балага кагылырга ярамый икәнлеге дә ачыклана, аның Копенгагендагы Антарктиканы өйрәнү институтында учетта торуы да, ай саен сабыйдан биопсия анализы алулары да. Һәм, ахыр чиктә, урала-урала, бу төен балалар белән яшерен экспериментлар үткәрүгә, тыелган экспедицияләргә баруларына, һәм Смилланың ватаны булган Гренландиянең – Европаның бер өлеше булган Дания өчен эксперимент һәм өйрәнүләр базасы булуына ук алып чыга. Бу урында инде Смилла үзенең язмышының да әнә шул ноктадан башлануын аңлый – кайчандыр аның әтисе кар һәм боз иленә, инуитлар кабиләсе гомер бакый яшәгән кеше аягы басмаган почмакка бозлыклардагы уникаль үзенчәлекләрне ачыклар өчен килгән. Ә бу үзенчәлекләрне өйрәнеп, экспериментлар үткәреп, күпләр менә дигән карьера да ясый икән Европаның тәртипле-гадел җәмгыятендә.

Ни өчен пошына соң Смилла ул бала өчен, дип гаҗәпләнер кемдер. Бу сорау башта минем дә миемне бораулады. Әйе. Ул аның кечкенә дусты, әнисе эчеп яткан көннәрдә Исайя Смилла фатирына кереп куна, аңарда сыену урыны таба торган була. Әйе, ул баланы карый, тәрбияли, укырга-санарга-язарга өйрәтә, аңардагы сәләтләрне ача, аның бу җәмгыятьтә үз урынын таба алырдай шәхес булып үсүен тели. Әмма хикмәт монда гына да түгел, Исайя – инуит кабиләсеннән. Һәм әле сабый гына булса да, ул Смилла өчен – кан туганы. Менә шушында Питер Хёг барлык кечкенә халыклар һәм этнослар өчен гаять кискен булган проблеманы алга чыгара – милләтнең сакланып калуы, үз эчке кануннары буенча яши алуы, үз туган туфрагында кимсенмичә гомер кичерүе, аңа гына яраклы урынын табу, кардәшлек тойгысы мәсьәләсен. Европаның бер өлеше булган Даниядә, Копенгаген шәһәрендә, үзен һәрчак читлеккә эләккән җәнлектәй хис итүче Смилла өчен бу төшенчәләр сүздә генә түгел. Монда үзен яраксыз, кирәксез итеп тоюы да – психологик тайпылышлар категориясенә керми. Үз стихиясеннән «йолкып» алынган бер милләт вәкиленең ниндидер гомуми стандартларга яраклашырга мәҗбүр ителүен без чагыштырмача яңарак кына глобализация дип атый башладык һәм бу төшенчә белән килештек бугай инде. Ә менә Смилла килешергә теләми.

Акыллы европеоид расасы вәкиленең кыргый, аңлаешсыз, стихияле Исландиягә карашы призмасы аша мин үземнең мәмләкәтемә

карыйм һәм шул ук картинаны күрәм. Акрынлап без, Шпенглер әллә кайчан игълан иткән «баеш»ны, ниһаять, бар тирәнлегендә ваемлап бетереп, Яңа Дөньяга йөз тотуыбызны, инде аның потларына табынуыбызны да анализлар хәлгә җитәрбез, бәлки. Кем белә! Ә аңа кадәр фрекен Смилла артыннан Питер Хёг ачып күрсәткән тарафларга һәм үз психологиябезгә сәяхәт итеп кайту – комачауламас. Үзебезгә кайтуның һәм үзебезне үзебез итеп саклап калуның нинди юллары барлыгын аңлар өчен генә булса да.

Можно разными способами пытаться преодолеть депрессию. Можно слушать органные произведения Баха в церкви Христа Спасителя. Можно с помощью бритвенного лезвия выложить на карманном зеркальце полоску хорошего настроения в виде порошка, а потом вдыхать его через трубочку для коктейля. Можно звать на помощь. Это европейский путь. Надеяться, что можно, что-то предпринимая, найти выход из трудного положения. Я выбираю гренландский путь. Он состоит в том, чтобы погрузиться в черное настроение. Положить свое поражение под микроскоп и сосредоточиться на нем. Когда дело обстоит совсем плохо – как сейчас – я вижу перед собой черный туннель. К нему я и иду. Я снимаю свою дорогую одежду, свое нижнее белье, свой шлем безопасности, оставляю свой датский паспорт и вхожу в темноту. Я знаю, что пойдет поезд. Обшитый свинцом паровоз. Я иду ему навстречу. Я знаю, что в глубине туннеля, под колесами, между шпалами есть крошечный просвет.

Бу «гренланд юлы» никтер безнең үзебезнең борынгы кыргый, «төрки юл»ны, хәтерләтә миңа. Ә бит ул «кыргый» чагыбызда без ирекле рәк тә булганбыз.

PRESSA.RU



КЕШЕЛӘР ЯЗМЫШЫ БЕЛӘН ЦИВИЛИЗАЦИЯНЕКЕ – ТӘҢГӘЛ

Икенче язучыбыз да Скандинавиядән – швед авторы Майгулль Аксельссон һәм аның «Апрельская ведьма» китабы. Бу китап үзенең авторына бик зур популярлык һәм Август Стриндберг исемендәге мәртәбәле премияне – Швециянең төп әдәби бүләген китерде. Китап бүгенге көндә 15 телгә тәрҗемә ителде һәм әдәбият сөючеләр арасында Майгулль Аксельссон дәрәҗәле авторларның берсе булып санала.

Майгулль ханым белеме буенча – журналист, социолог. Шуңа да аны борчыган проблемалар, шулай ук, җәмгыятьтәге кискен мәсьәләләргә кагыла, һәм бик еш кына – янә дә балаларның социаль яклауга мохтаҗ булуы проблемасына барып тоташа. Шунысы гаҗәпләндерә: яшәү дәрәҗәсе шактый югары исәпләнгән Скандинавия илләрендәге язучылар нәкъ менә эчкечелек, наркомания, балаларны ташлау, аларның хокукларын кысу, алардан файдалану, инвалидлык, социаль яклау, коррупция, ил эчендәге клаустрофобик тойгы-халәт, һәм тотальь ялгызлык турында яза.

«Апрельская ведьма» романында балалар проблемасы ике яссылыкта – бала күзлегеннән һәм өлкән яшькә җиткән ханымнарның анализ сызыгыннан бирелә. Әсәрдә кешеләрнең үзләрен, асылларын, тамырларын эзләве һәм җәмгыятьтәге торышка яраклаша алмавы турында сүз бара. Аксельссонның героинялары дүрт кыз – Кристина, Биргитта, Маргарета һәм аларның бәхетле язмышы хакына гомерен кеше кулында, һәртөрле социаль учреждениеләрдә, хастаханәләрдә үткәрергә мәҗбүр ителгән инвалид Дезире. Хикәяләү барышында алар, бер-берсен алыштырып, укучыга үз ситуацияләрен ачып күрсәтә. Бу какофония эчендә вакыт-вакыт кемнең кем икәнлеген дә бутый башлыйсың. Җитмәсә, язмышлары бербөтенгә укмашкан, үзара туган да булмаган, бары, үз әти-әниләреннән тәрбия алу мөмкинлеге булмау сәбәпле, кеше карамагына, төгәлрәк әйтсәк, Дезиренең үз әнисе – Эллен кулына калган балаларның яралары һәрдаим ачылып, ул ярадан балачак фаҗигасе саркылып тора.

Бу ханымнарның берсе – югары квалификацияле танылган табиб, икенчесе – галим-физик, өченчесе – өметсез наркоман. Шуны да әйтергә кирәк: скандинав язучыларының һәрберсендә бу мотив кызыл җеп булып сузылып бара – иҗтимагый статус мәсьәләсе һәм аутсайдерлык проблемасы. Һәм аларда бу, иң беренче чиратта, дәрәҗәле белем алу белән һөнәргә ия булуга бәйле. Америка хыялыннан аермалы буларак, тар, кысан җәмгыятьтә бер-берең алдында торткан дәрәҗә дә – аерым бер тема. «Әтәч менгән читәнгә», – дип уйлап куйдым эчтән генә.

Беренче икесе – Кристина белән Маргарета – җәмгыятьтә үз урынымны таптым, ниһаять, кеше исәбенә кердем, дигән горурлык хисе белән яшәсә, Биргитта-наркоман исә үзләренең аяныч балачагыннан һаман да котыла алмый. Дөресрәге: Эллен йортына эләккәч, беркадәр йорт иллюзиясенә ия булып яшәп алган гомернең җимерелү моментыннан. Хәрабәләрдән. Чөнки ул хәрабәләрнең сәбәпчесе, беренче карашка, нәкъ менә ул. Әмма китапның буеннан-буена Аксельссон, интриганы ачып бетермичә, укучысын киеренкелектә тота – бәлки, алай да түгелдер. Бәлки…

Әсәрдә безнең замандагы кайбер җәрәхәтләрнең үткәндәге эзләре дә ачыла. Питер Хёг проблеманы бер ракурстан алса, Аксельссон икенче бер якка басым ясый – аның әсәрендәге Европа фаҗигасенең бер тотамы нацизм чәчәк аткан чорга, Гитлер Германиясе кылган гамәлләргә барып тоташа. Эллен – әнә шул афәтнең корбаны. Һәм ул, сугыш чоры газапларын балачагында кичергән, ачлыкның ни икәнен бөтен күзәнәкләре белән тойган сабый буларак, тормышын башкача корырга тели – балаларга бәхет бүләк итеп. Ләкин язмышның карары икенче була – сабые Дезире балачак ачлыгыннан гарипләнгән әгъзаларында сәламәт булып формалаша алмый һәм дөньяга «тагын бер имгәк» туа. Ә ул заманда Швециядә бу проблема белән күзгә-күз очрашкан әниләргә бер генә юл кала – баланы махсус учреждениегә урнаштыру һәм табиблар күзәтүенә тапшыру. Эллен шулай итә дә. Аннан инде, бала җылысына сусап, бер-бер артлы өч нарасыйны канат астына җыя – ятимнәрне, рәнҗетелгәннәрне, ярдәмгә мохтаҗларны. Эллен йортында үскәндә, бу балаларның берсенә дә җил-яңгыр тими, берсе дә кимсенү-җәбер күрми. Асылда, ул кеше балаларын ятимлектән, балалар йортларында кагылып-сугылып йөрүдән саклап кала.

Ә ул арада Дезире параллелендә – озакка сузылган җиңеп булмаслык авыру белән көрәшү, михнәт-газап еллары. Авыруы булмаса, икенче Стивен Хокинг булыр иде ул, бәлки, табиблар аңа хәйран кала. Ул бертуктаусыз укый, текстлар яза, үзендә яңадан-яңа талантлар ача. Әмма бу җәмгыятьтә аны берәү дә колач җәеп көтеп тормый… Һәм шул талантларның берсе – Дезиренең, үз гәүдәсен калдырып, күчә алу сәләте (телепортация) булып чыга. Нәкъ менә шул көннән Дезире, апа-сеңелләрен эзләп, сәфәргә чыга. Аларны таба һәм инде башка күз уңыннан ычкындырмый.

Нет, никто из сестер не крал моей жизни. Эту жизнь, предназначенную мне, я прожила сама. И все-таки я не могу их отпустить, не могу позволить Кристине, Маргарете и Биргитте разбежаться в разные стороны.

Шулай итеп, язучы, Кафка, Сартр традицияләрен дәвам итеп, кешеләрнең бер-берсенә якынаю, аңлаша алу мөмкинлегенең әле XXI йөздә – югары цивилизацияле җәмгыятьтә дә – гайре табигый хәл булып калуын ассызыклый. Һәм бу аңлаша алмауның кайчан да булса бер, башка битлек киеп алса да, барыбер дә шул ук фашизм, неофашизм кебек һәлакәткә китерүенә ишарә ясый.

Ул арада үзләрен апалы-сеңелле дип исәпләргә мәҗбүр булган өчәү, төрлесе-төрле якка таралышып, һәрберсе үз тормышын яши. Берсе – Эллен йортында булган идиллияне торгызырга, кайтарырга омтыла, икенчесе, гаилә бәхетенә ышанмыйча, үз бәхетен эзли, өченчесе – үз-үзен юкка чыгару белән шөгыльләнә. Һәм, ни генә булмасын, һәрберсе үзенең ташландык бала булуын анык хәтерли, үткәненнән качарга тели. Өчесе бергә очрашу да – алар өчен зур җәфа. Чөнки бу очрашу һәрберсенә үткәнен хәтерләтә. Ә үткәненең тамыры анык булмаган кешегә – Аксельсон моны кат-кат ассызыклый – киләчәккә ышанычлы курс белән бару гаять авыр. Үткәннән качарга түгел, ә гыйбрәт, сабак алырга өнди ул.

Бары Дезире гына – искәрмә. Ул бу ханымнарга үчле күңеле белән кайта-кайта, ни генә булмасын, аларны күңеленнән генә «апа-сеңелләрем» дип атый. Чөнки алар – Дезирене әнисе, нормаль тормыш белән тоташтыручы бердәнбер күпер. Сүз уңаеннан, азакта әнисенә дә барыбер, нәкъ үз кызы кебек, гомеренең соңгы көннәрен социаль учреждениедә уздыру насыйп була.

Мистика жанрына тартым алымнар китапның тукымасын тагын бер мәгънә катламы белән тутыра – кешеләр, социум эчендә гарипләндерелә-гарипләндерелә, ахыр чиктә, барыбер үз асылларына кайта башлыйлар. Балачакка. Менә шул балачакны өр-яңадан күздән кичереп, анализлап, кабул итә һәм ирекә җибәрә алмыйбыз икән, без мәңге бер урында таптанып торачакбыз, ди Аксельссон. Һәм бу кеше язмышларына гына кагылмый, бу дәүләтләр, цивилизацияләр язмышына да кагыла.


Болгар
Красная
Слобода
Татар
Тактальсы
Антоновка

PRESSA.RU

Спас районы

БӨЕК БОЛГАР КҮЛӘГӘСЕНДӘ

Татарстанның Спас районы илебез халкына һәм хәтта чит ил кешеләренә дә, беренче чиратта, Болгар музей-тыюлыгының истәлекле урыннары белән таныш. Ул гүя сирәк очрый торган асылташ – аның кысасы да аерым тарихка ия.

ХАТЫН-КЫЗ ӨЛЕШЕНӘ ТӨШКӘН ГЕКТАРЛАР

Екатериновка авылы янындагы юлдан рәт-рәт булып тезелгән «Дон» комбайннары күренә. Спас районының авыл хуҗалыгы идарәсе консультанты Дмитрий Савинов безне урып-сугу кампаниясе вакытында Татарстанның Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан килгән хәбәрләрдә күп еллар инде исемнәре яңгырап торган кешеләр белән таныштырырга алып бара. Ни гаҗәп, бодай уңышы гектарыннан 31,8 центнер (2016 елда республика буенча гектарыннан уртача 27 центнер) булган бу алдынгы хуҗалык белән хатын-кыз җитәкчелек итә икән.

Айсылу Мөхәммәтова кул астында иң яхшылар гына эшли! Республиканың атказанган механизаторы – Айрат Яруллин.

– Тормыш иптәшем белән бу хуҗалыкка 10 ел элек нигез салдык, бәләкәйдән башладык. Хәзерге вакытта 4 мең гектар җиребез бар, – дип сөйли Айсылу Мөхәммәтова. – Дәүләт бик ярдәм итте. Быел да авыл хуҗалыгы техникасы сатып алганда, субсидияләр бирү программасы буенча без берничә яхшы машина сатып алдык, киләсе елга паркны киңәйтеп, чәчүлек мәйданнарын да арттырырга ниятлибез.

Иң мөһиме, ди ул, эш процессын җайга салырга кирәк.

– Барысын да вакытында эшләп барсаң әйбәт, хаталар кыйммәткә төшә. Бездә кешеләр бик яхшы, тәҗрибәбез дә зур, шуңа да эшебез уң бара. Һава торышлары да гел уңай килеп торса икән! Бер елны бөтен җирдә яңгырлар явып үтте, ә безнең Екатериновкада – юк. Аптыраганнан

Автор:
Олеся Бондаревская

PRESSA.RU

басуга чыгып, орлыкларны казып карадык – тишеләләрме? Тәвәккәллек һәрвакыт бар инде ул... Әмма без башка эшне белмибез, дөресен генә әйткәндә, теләгебез дә юк! – дип елмая Айсылу Мөхәммәтова.

140 – БАШЫ ГЫНА ӘЛЕ

Татар Такталысында икенче бер гаилә хуҗалыгы капкасыннан безне яшь кенә бер егет – Ильмир Гайнуллин каршы алды. Әтисе белән икесенә ике ферма – 140 баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Ильмирга 25 яшь, ике ел элек Казандагы әйбәт кенә эшен ташлап, туган авылына кайткан. 2014 елда алар беренче фермаларын оештырып җибәргәннәр, 2015тә – икенчесен. Әлеге ике проектка алар яңа эш башлап җибәрүче фермерларга грант ярдәме программасы буенча федераль бюджеттан – өч миллион, республиканыкыннан 800 мең сум күләмендә субсидия алганнар.

– Шәһәрдән кайтырга булдым. Үзең өчен эшләп булганда, ни өчен әле кемгәдер эшләп йөрергә? – ди Ильмир.

Сөт җыю машинасы килә, иртәнге 380 литр сөтне алып китә. Ильмир белән әтисенең ике ярдәмче эшчесе бар. Бөтен коллектив шушылардан гыйбарәт. Ләкин эшне авыр дими ул.

– Узган ел ит сарыклары алдык, киләсе елга 10 сыер алырга, 200 баш сыерга яңа ферма төзергә планлаштырабыз, – дип сөйли фермер. Атсыз бармагында яңарак кына кигән туй балдагы ялтырый.

– Хатының да фермада эшлиме? – дип кызыксынабыз без.

– Юк, сез нәрсә, хатын-кыз эше түгел бу. Ул – өйдә, хуҗабикә, – дип елмая Ильмир.

– Безнең район бәләкәй, ләкин шәхси хуҗалыклар күп. Башка күп кенә районнарда авыл хуҗалыгы мәйданнары бөтенләе белән диярлек инвестор кулында, ә бездә яртысы гына, калганнары – фермерларда. Монда һәм, гомумән, крестьян-фермер хуҗалыкларының саны елдан-ел артуда район башлыгы Камил Нугаевның өлеше зур. Ул, үзенә эшләп, үсәргә, киңәергә тырышкан фермерларга нык ярдәм итә, – дип йомгаклый безнең экскурсияне Дмитрий Савинов.

БУЛАЧАК ХӘРБИЛӘР МӘКТӘБЕ

Болгар кадет интернат-мәктәбенә директор Евгений Савинов белән бергәләп керәбез. Көндезге кизүдә торучы безне бөтен шартын туры китереп сәламли. «Вольно!» дигән команда яңгырагач кына, без әлеге үсмер белән сөйләшә алабыз. Исеме Илья икән, 14 яшьтә, Ульяновскидан, монда бишенче елын укый. Хәзерге вакытта Илья укуда да, физик әзерлек буенча да менә дигән уңышларга ирешкән, ул районның әзтабарлар отряды составына керә.

Болгардагы Балалар сәнгать мәктәбенең музыка, хореография һәм сәнгать бүлекләрендә шөгыльләнүчеләрнең тик утырырга вакыты юк. Гамманы өйрәнергә яисә төсләрне тонықландырырга өлгереп кенә җитәсең, шәһәр, районда үткәрелә торган берәр чарага, республика яки федераль күләмдәге фестивальгә, җәйге иҗади сменага әзерләнергә вакыт җитә. Елына берничә тапкыр мәктәп үзе дә «Балалар борынгы Болгар җирендә» Республика музыка марафоны, «Россиянең яшь талантлары борынгы Болгар җирендә» Бөтенроссия фестивале һәм «Аккордеон феериясе» республика фестивале кебек масштаблы чараларны оештыручыларның берсе буларак чыгыш ясаган. Менә бүген дә Даша Осокина, Лера Сосипатрова һәм Камилә Вафина кебек талантлы балалар шуларның берсенә бию әзерли.

– Миңа монда уку ошый, алга таба тормышымны хәрби хезмәт белән бәйлисем килә, – ди Илья. Ул һәркем ватанпәрвәр булырга тиеш, дип саный. Ватанпәрвәрлек ул – нинди генә шартлар булмасын, ватанны сакларга әзер булырга тиешсең, дигән сүз.

– Бездә 100 кадет укый. Читтән килгәннәр интернатта яши, араларында авыр тормыш хәлләренә юлыккан үсмерләр дә бар, аз керемле гаиләләрдән булганнары да. Төп бурычыбыз – аларга социаль мохиткә яраклашырга, тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итү, – дип сөйли Евгений Савинов. – Быелдан башлап, конкурс нигезендә кабул итәбез. 5нче сыйныфка керергә дип, Татарстаннан һәм Ульяновск өлкәсеннән 66 бала гариза язды. 13ен сайлап алдык.

Директор Марат Фәритовның җиңел кулы белән Спас һөнәр лицеенда кадет классы буларак башланып киткән мәктәпкә 2017 елда 10 ел тула. Аны тәмамлаучыларның барысы да урта, аннан соң югары уку йортларына керә. Иң яхшылары хәрби училище курсанты булу бәхетенә ирешә. Мәктәп җитәкчелеге һәркайсының язмышы белән кызыксынып тора.

– Хәрби училищеларга конкурс зур, – дип сөйли Евгений Викторович. – Аларның кайсына керә алу да зур җиңүгә тиң. Һәм без Ильяга да, башка кадетларга да ул җиңүне яуларга ярдәм итәчәкбез. Бездә егетләр тырышып укыйлар, хезмәткә өйрәнәләр – беренче чиратта үз өсләрендә эшлиләр. Һәм алар мондый җиңүләргә лаек.

КАЛӘМ ОЧЫННАН ЧЫККАН ТӨТЕН

Фойедагы ниндидер җирле, иҗади вакытны күрсәтә торган тылсымлы сәгать янышннан үтеп, Болгар сәнгать мәктәбе директорының кабинетына керәбез. Директор Ирина Илюхина мәктәпнең кайнап торган тормышы турында сөйли.

– Бездә дә һәркайдагы кебек үк проблемалар бар, әлбәттә, – ди Ирина Петровна. – Менә хореографыбыз берәү генә, ә бию – безнең

Ел саен үткәрелә торган хәйрия марафоны – Спас районында 20 ел элек башлангыч алган күркәм традицияләрнең берсе. Февраль аеның бер көнендә оешма һәм предприятиеләр җитәкчеләре, эшкуарлар, депутатлар, Спас һәм башка районнарда яшәүчеләр ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә булышуга үз өлешләрен кертү өчен җыелалар. Иң юмартларны, иң активларны «Ел хәйриячесе» дигән грамота белән бүләклиләр. Фотода: Рәшит Зыятдинов, кекусинкай каратэ буенча кара пута иясе, балалар секциясендә тренер. Ул хәтта җитди диагнозы булган шәкертен дә илһамландырырга сәләтле.

Рабига күле әйтерсең лә түгәрәк тәлинкә. Рабига – хан кызы, гүзәлләрнең гүзәле булган, дип сөйлиләр. Әтисе аңа өйдән чыгып йөрергә рөхсәт итмәгән. Бервакыт гүзәл туташ дус кызлары белән бергә аккошка әверелеп качып киткән. Шул көнне хан да ауга чыккан. Кош дип атканы кулына гүзәл кызы булып килеп төшкәч, кайгы-хәсрәтнең чиге булмаган! Хан түккән күз яшьләреннән шушы күл барлыкка килгән, диләр.

Фото: Ната Смирнова, tatfrontu.ru, artinrussia.org

PRESSA.RU

визит карточкабыз, шулай булгач, аңа эш бик күп. Театр студиясенең эшен туктатып торырга туры килде – яраткан педагогыбыз лаеклы ялга чыкты, ә аңа алмашка әлегә кеше таба алганыбыз юк.

Өстәлдәге стикерлар кабына күзем төшә. Иң өстәге битендә каләм белән төшерелгән сурәт: тәтен болытларына уралган, поезд, томырылып, карлы тауга таба ашыга.

– Дәвамчанлык дигәннән – яшь педагогыбыз без сөйләшкән арада төшерде, – дип елмая Ирина Петровна.

Яшь педагог дигәнебез кыска чәчле, чандыр гына гәүдәле матур туташ булып чыкты. Әллә кайдан күренеп тора – рәссам. Варвара мәктәптә графика укыта икән.

– Балалар белән эшләргә яратам, аларда иҗади энергия ташып тора, гәрчә кайчагында материалны аңлату өчен әллә нинди могҗизалар уйлап чыгарырга туры килсә дә. Ләкин нәтиҗәсе хакына, әлбәттә, түзәсең, – ди Варвара.

Сыйныф бүлмәсендә урындыкларга әзер эшләр куелган – укучыларның мәдәният, сәнгать, иҗат буенча халыкара бәйгедә катнашасы эшләре. Япон мультипликаторы Хаяо Миядзаки ленталары мотивлары буенча төшерелгән поезд рәсеме караламасы исә – Варвара бәйгедә үзе катнашачак эш икән. Укыту аңа иҗади тәҗрибә тупларга да ярдәм итә.

– Аннан соң?

Җавап итеп, Варвара иңнәрен генә сикертә һәм, елмаеп, карашын тәрәзәгә дә түгел, ә еракка – офыкларга төби. Чын иҗат әһеле өчен чикләр юк шул.

БӨТЕН ЮЛЛАР «ОЛИМП»КА ИЛТӘ

Болгардагы «Олимп» спорт комплексының зур залында зәңгәр форма кигән кызлар туп өчен көрәшә. Уенның икенче таймы бара, исәп тигез – Яшел Үзәннең баскетболчы кызлары белән азнакайлылар көч сынаша.

– Чемпионат 13нче «Сәламәтлек» авыл спартакиадасы кысаларында үткәрелә. Спартакиаданың финалы спортның 16 төре буенча декабрьдә узачак. Әлегә Арча, Спас һәм Азнакай районнары алда бара, – дип аңлатып китә Татарстанның «Уңыш» спорт җәмгыяте рәисе Видади Мәхмүтов.

Уен барышын игътибар белән балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе директоры урынбасары Наталья Филиппова белән Спас районы башкарма комитетының яшьләр, туризм һәм спорт эшләре буенча бүлек башлыгы Әхтәм Вәлиәхмәтов күзәтә.

– «Бердәм Россия»нең спорт комплекслары төзелеше программасы булуын шатланып кабул иттек. «Олимп» шулай барлыкка килде, – ди Әхтәм Нурвахитович. – Спорт мәктәбе шунда ук бирегә күчте – аңа яңа бина бик кирәк иде. Хәзер без биредә спортның 8 төрен үстерәбез. 2015 елда Болгарда «Дулкын» бассейны төзелде. Мондый инфраструктура балаларыбызның сәламәтлеген кайгыртуны тулысынча тәэмин итә дип уйлыйм.

– Безнең «Олимп»ның буш торган көне юк. Даими рәвештә район һәм республикакүләм ярышлар уздырылып тора, – дип, Наталья Юрьевна чемпионатка карата үз фикерләрен белдерә. – Самбочылар ярышып киттеләр, аннан соң башка районга барып караганнар, әмма янәдән безгә кайттылар – комплекслар бердәй булса да, сездә яхшырак, диләр. Хикмәте нәрсәдәдер, белмибез: әллә баннерларыгыз башка, әллә кешеләрегез, диләр алар…

Урман эчендә заманча, иркен итеп төзелгән «Олимп», һичшиксез, ярыш оештыручыларны үзенә җәлеп итә. Әмма сере, мөгаен, уңай энергия ташып торган биредәге кешеләрдәдер.

БӨТЕН ҖЫРЛАР ДА – МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА

– Яулыгым кардан да аграк, яңакларым алмадан да кызылрак, күлмәгем агачлардан да яшелрәк… – сәхнәдән удмурт телендәге җыр яңгырый. Красная Слобода авылы клубында Спас районы территориясендә яшәүче халыклар иҗатына багышланган этник фестивальгә әзерлек бара. Фестиваль биредәге башка бик күп уникаль чаралар һәм акцияләр кебек үк, район башлыгы Камил Нугаев башлангычы белән 9 ел элек барлыкка килгән. Хәзер ел саен Халыклар бердәмлеге көне алдыннан рус, татар, чуваш,

«Без бүген ия булган байлыкларга шушы кешеләр кулы белән нигез салынган. Без аларга чиксез рәхмәтле…», – халык хуҗалыгының алдынгылар слетында катнашучылар турында Спас районы башлыгы Камил Нугаев шулай диде. Нәкъ менә аның тырышлыгы белән районда иң яхшы комбайнчыларны, механизаторларны, машина йөртүчеләрне, терлекчеләрне һәм авыл хуҗалыгы тармагы ветераннарын, табибларны, укытучыларны һәм спортчыларны олылау традициясе бүген дә сакланып калган.

удмурт, әрмән, башкорт коллективлары тамашачылар игътибарына үзләренең иң яхшы җыр һәм биюләрен тәкъдим итәләр.

– Мин монда туган авылым Алнаштан 17 яшемдә килдем, – дип сөйли кызларның үз-үзен мактавына корылган удмурт җырын башкаручы Валентина Гыйниятуллина. – Удмурт телендә биредә аралашыр кешем юк, тел дә онытылып бара. Менә хәзер фестивальләргә, бәйрәмнәргә әзерләнеп, туган ягымда җырлаган удмурт халык җырларын әкренләп искә төшерә башладым.

– Удмурт халык җырлары нәрсә турында соң?

Әңгәмәдәшем елмая:

– Тормыш турында, мәхәббәт… Барысы да мәхәббәт турында!

ТАМЫРЛАР КИТАБЫ

«Иске Куйбышев шәһәрлеге, археологик һәйкәл, имәнкискә чорының ныгытылган җирлеге (IV-VII гасырлар) һәм болгар шәһәренең кремль калдыклары (XI-XIII гасырлар). Куралово авылыннан 3,5 чакрымда, Куйбышев шәһәренең элекке урынына якын җирдә Бизнә елгасы борылмасында урнашкан», – дип укыйбыз «Болгар шәһәре һәм Спас районы энциклопедиясе»нең очраклы гына ачылган битеннән. Басманы уникаль дияргә дә була. Аның уникальлеге, беренче чиратта, шунда: китапка районның барлык торак пунктлары, аларның бүгенге көнгә кадәрге тарихы, тарихларга кергән кешеләр язмышы турында тәфсилле мәгълүмат тупланган. Икенчедән, китап энциклопедия нормаларына туры китереп эшләнгән, димәк ки, ноктасына кадәр дөрес һәм тулы.

– Энциклопедия өч ел дәвамында эшләнде, аны төзү эшендә дистәләрчә якташыбыз – тарихчылар, икътисадчылар, коммерцияле һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре, мәдәният эшлекләләре, шагыйрьләр һәм язучылар катнашты, – дип сөйли энциклопедия мөхәррирләренең берсе, этнограф, тарихчы һәм туган якны өйрәнү белгече Җәмил Мөхәммәтшин. – Спас районы һәм без, Спас районы кешеләре, турындагы иң мөһим, иң яхшы мәгълүматлар шушы китапка кертелде.

Чит кешеләр – район кунаклары өчен, мөгаен, бу төбәктә бүген Бөек Болгар дип атала торган урта гасырлар шәһәре барлыкка килүгә этәргән торак пунктларның кайчан, ничек һәм нинди яулар, ландшафтта нинди кискен үзгәрешләр кичерүен белү кызыклы булыр.

– XVII-XVIII гасырларны гына үз эченә алган бик күп чыганаклардан аермалы буларак, безнең энциклопедия Болгар тарихының Казан ханлыгы чорына һәм хәтта иртәрәк чорга – Идел буе Болгар дәүләтенең чәчәк ату вакытына да күз салырга мөмкинлек бирә, – ди Җәмил Мөхәммәтшин. – Шул рәвешле без төрле җирдә таралып яткан тарихи фрагментларны бергә җыеп, туган ягыбызның күпгасырлы тарихының масштаблы, җете төсләр белән яктыртылган картинасын тудырдык.

«Кол Гали» кунакханәсенең монументаль бинасы территориясендә яфраклы агачларның үсентеләре тамыр җибәргән инде. Кунакханәдә 152 уңайлы кунак номеры, конференц-зал, велосипед юллары, теннис кортлары һәм ачык һавадагы бассейннан тыш, Болгар чорындагы Ак пулат (XIV гасыр) үрнәгендә мунча комплексы да булачак. Төзелүче икенче бер масштаблы объект – Болгар Ислам академиясенең алгы өлешен матурлый башлаганнар инде. Кунакханә һәм Академия 2017 елның җәендә ачылыр, дип планлаштырыла.

Фото: Ната Смирнова, tatfrontu.ru, artinrussia.org

Биредәге күренекле урыннарның берсе – Антоновка авылындагы Мусин-Пушкиннар утарындагы бина. Бина төзелгәнгә 200 елдан артыграк вакыт үткән, шуның 100 елы дәвамында биредә мәктәп урнашкан. Элекке кунак бүлмәсе тәрәзәләреннән бакча һәм Бизнә елгасы күренеп тора. Авыл да элек шушы исемне йөрткән. Ни өчен авылга Антоновка исеме бирелүен сезгә мәктәп музеенда сөйләрләр. Бинадагы баскычлар (берсе – әфәнделәр, икенчесе хезмәтчеләр өчен) һәм ике көзге граф утарыннан калган. Имештәр, әлеге көзгеләргә беренче тапкыр караганда теләнгән теләк, һичшиксез, үтәләчәк икән.

PRESSA.RU



Камил Әсгать улы Нугаев
1956 елда Кузнечиха районының Старый Баран авылында (хәзер – Спас районы Иске Рәҗәп авылы) туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетына укырга керә. 1980 елдан – Куйбышев районының Чапаев исемендәге колхозында баш агроном. 1985 елның февраленнән – илнең иң күптәнге авыл хуҗалыгы предприятиеләренең берсе булган «КИМ» нәсел заводы директоры. Катлаулы җитештерү проблемаларын хәл итә белүен эштә күрсәткән җитәкче буларак, Камил Нугаев 1988 елның гыйнварында Куйбышев районы башкарма комитетының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы итеп билгеләнә. Үз потенциалын, эшләнмәләрен һәм уй-ниятләрен тормышка ашыру омтылышы аны 1995 елда үз кандидатурасын ТР Югары Советына депутатлыкка тәкъдим итү фикеренә китерә. ТР Югары Советы депутаты, Спас район советы рәисе, аннары район хакимият башлыгы булгач, Камил Нугаев инвесторлар җәлеп итүгә, фермерлыкны, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә басым ясый. Район башлыгы урынында 22 ел эшләү дәверендә барлык авыл җирлекләре газлаштырылган, барлык торак пунктларга каты өслекле юллар үткәрелгән, республика президент программалары кысаларында күпсанлы социаль объектлар салынган. «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» проектын тормышка ашыру шәһәр һәм район яшәешендә тамырдан үзгәрешләргә китергән. Сайлаучыларның даими хуплавы – Камил Нугаев эшенең нәтиҗәлелеге турында сөйләп торучы төп дәлилләрнең берсе. Камил Нугаевның дус, тату гаиләсе – хатыны Мәйсәрә Мансуровна, буй җиткән ике улы, биш оныгы бар.

КАМИЛ НУГАЕВ: «РАЙОННЫ АЛГА ТАБА ҮСТЕРҮ ӨЧЕН БАРЫСЫН ДА ЭШЛӘЯЧӘКБЕЗ!»

Декабрь аенда Спас районы башлыгы Камил Нугаев 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк. «Районнар буйлап!» проектының Спас чыгарылышын әзерләгәндә, без сөйләшкән һәрбер кеше аны бөтен көчен үзенә тапшырылган территорияне үстерүгә юнәлткән гаҗәеп энергияле, максатчан, ярдәмчел шәхес буларак телгә алды. Шуңа да Камил әфәнде белән Спас районының бүгенге яшәеше турында әңгәмә кору икеләтә кызыклы булды.

– Камил Әсгатович, сезнең «зур» проектларыгызның беренчесе Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгын – башта республика, аннары – Россия, хәзер инде халыкара дәрәҗәдә үк танытуда катнашу булды. Бу объект сезнең өчен нинди мәгънәгә ия?

– Борынгы Болгар, һәр мөселман өчен кадерле булгандай, миңа да – изге урын. Минем бабам да, әтием дә мулла булган кешеләр. Шуңа күрә Болгарның тарихына да, аның рухи һәм мәдәни мирасына да бар күңелемне биреп, зур җылылык белән карыйм.

– 2010 елда «Яңарыш» Республика фонды оештырылды һәм «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» комплекслы проекты тормышка ашырыла башлады. Бөтен Татарстан өчен әһәмиятле бу вакыйга Спас районы язмышында нинди чагылыш тапты?

– Моңа кадәр үк мин үзем дә, коллегаларым да нәкъ менә Болгар музей-тыюлыгын үстерүнең районыбызны тулаем алга җибәрәчәк юнәлешләрнең берсе булырга мөмкин икәнлеген күзаллый идек. Шулай булып чыкты да. Бу проект башланганнан бирле булган уңай үзгәрешләр район тормышының бөтен өлкәләрендә дә күзәтелә диярлек.

– Республика президент программаларында катнашу – үзенә күрә район потенциалының күрсәткече дә бит...

– Бу яктан караганда, без шактый эшләр башкардык. Шунысын да әйтим: мондый күләмле эшләрне башкару өчен үз ресурсларыбыз гына җитмәс иде. Шулай булгач, президент программалары безнең өчен үсеш инструменты да, шул ук вакытта стимулы да булды. Без барысында да диярлек катнашабыз.

– Спас районы өчен нинди программалар аеруча актуаль?

– Беренче чиратта, бу, әлбәттә, торак белән бәйле программалар. 2011 елдан 2015 елга кадәр районда Бөек Ватан сугышында катнашканнар һәм аларның тол хатыннары өчен күпфатирлы биш йорт, шулай ук тузган торактан күчерү программасы буенча күпфатир-

лы – бер һәм азфатирлы дүрт йорт төзелде. Тыюлык территориясеннән күчерү программасы буенча 107 гаилә Идел буе бистәсенә шәхси торак йортларга күчерелде, ятим балалар өчен ике йорт төзелде. Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү программасы актив тормышка ашырыла – биш елда 27 объектта эшләр башкарылды.

– Биш еллап элек Болгарда яңа су җыю корылмасы төзелгән иде. Хәтта Идел ярында торган шәһәрнең дә суның сыйфатына бәйле проблемалары бар идемени?

– Әйе, бар иде, әле нинди генә. Эш шунда ки, су үткәрү челтәрләренең бер өлеше узган гасырның 50–60нчы елларында ук төзелгән. Ул вакыттан бирле торбаларга юшкын утырып өлгергән, һәм ул, беренче чиратта, суны пычратса, икенчедән, аның йөрешенә комачаулый. Шуңа күрә гомуми бәясе 148 миллионга якын булган яңа су җыю корылмасын төзү турында карар кабул ителде. Моннан тыш, без авылларны су белән тәэмин итү программасында катнашуыбызны да дәвам итәбез. Ел саен моның өчен 10 миллионга якын акча бүлеп бирелә.

– Су темасын дәвам итеп... Узган ел Болгарда бик затлы «Дулкын» бассейны ачылды. Бу районда бердәнбер киң колачлы спорт объектымы?

– Юк, бердәнбер түгел. Гомумән, Спас районы өчен спортның традиция булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Татарстанда һәм Россиядә танылган спортчылар арасында безнең якташлар күп. Спорт белән балалар да, өлкәннәр дә актив шөгыльләнә. Шуңа күрә бездә федераль максатчан программа кысаларында һәм «Бердәм Россия» партиясе ярдәме белән төзелгән искиткеч «Олимп» физкультура-сәламәтләндерү комплексына бик тә шатландык. Нәтиҗәдә бу ике объектның төзелеше якынча 250 миллион сумга төште. Моннан тыш, без дүртенче ел инде урам спорт мәйданчыкларын төзү программасында да катнашабыз. Район буенча алар бездә 10 га җитте инде. Бу мәйданчыкларның берсе ТР Дәүләт Советы депутаты, «Алексеевскдорстрой»ның генераль директоры Фоат Вәлиевнең спонсорлык акчасына төзелде.

– Районда инде берничә ел дәвамында кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләре эшчәнлегенең керемнәре арта. Бу хәзер, кагыйдә буларак, бигрәк, искәрмәдер, мөгаен. Әлеге үсешкә нәрсә хисабына ирешелә?

– Беренчедән, Болгар музей-тыюлыгын үзгәртеп кору проектын тормышка ашыру һәм, шуның белән бәйле рәвештә, туристлар агымының гаять нык артуы зур роль уйнады. Узган ел безгә 350 мең турист килгән иде, быел – 450 меңгә якын. Ваклап сату һәм җәмәгать туклануы нокталарының саны артты. Эшкуарларда перспективалы юнәлеш белән кызыксыну барлыкка килде. Икенчедән, КУЭ ярдәм программалары, аеруча «Лизинг-грант» программасы нык булышты. Аның буенча берничә эшкуар – икмәк пешерү предприятиесе, теплица, төзелеш материаллары бизнесы хуҗалары үз җитештерүләрен яңартып кора алды. Өченчедән, биредә тарихи үсеш барышында формалашкан көчле аграр сектор бар.

– Районда крестьян-фермер хуҗалыкларының күп булуы һәм аларның саны арта баруы хакмы?

– Әйе. Бездә барлыгы 70 КФХ теркәлгән, һәм безнең Спас кебек кечкенә район өчен бу бик әйбәт сан. Игътибар яңа югары технологияле гаилә фермалары булдыруга юнәлтелә. Шул уңайдан авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү дә киңәя. «Болгар ИКП», «Спас икмәге» уңышлы эшли, ит эшкәртү буенча җитештерүне – «Спас казылыклары» ҖЧҖне ачу күздә тотыла.

– Спас районы уңышлы рәвештә үсеп килә, дип әйтә аласызмы?

– Әлбәттә. Берничә ел дәвамында без барлык социаль-икътисадый күрсәткечләрне теркәп барабыз. Тулай территориаль продуктта кече эшкуарлык өлеше арта, тәэпозатылган товарлар, күрсәтелгән хезмәтләр күләме, сәнәгать җитештерүе индексы, ваклап сатудагы товар әйләнеше – барысы да. Әмма иң мөһиме – шәһәр халкының гына түгел, авыл кешеләренең дә тормыш шартлары яхшыра бара. Ел саен безнең икешәр авыл җирлеге үзләренә туры килгән республика программасы буенча бер миллион сум күләмендәге грантларга ия була. Без алга таба бу уңышларны саклап калу юнәлешендә генә түгел, ә арттыру буенча да эшләячәкбез.

СПАС РАЙОНЫ

Административ үзәк:
Болгар шәһәре

Оешкан вакыты:
10.08.1930

Район башлыгы:
Камил Әсгать улы Нугаев

Башкарма комитет җитәкчесе:
Валерий Александрович Осокин

Халык саны:
19 563 кеше

Милли составы:
татарлар, руслар

Район икътисадының әйдәп баручы тармагы – авыл хуҗалыгы. Районда сабан бодае,көнбагыш, кукуруз, арпа, солы, тары, борчак игелә. Терлекчелекнең төп тармаклары – ит-сөт терлекчелеге, дуңгызчылык, атчылык. Авыл хуҗалыгы җитештерүендә 934 кеше мәшгуль (шәхси ярдәмче хуҗалыкларда эшләүчеләрне исәпкә алмаганда), алар 108 мең гектар авыл хуҗалыгы җирләрен, шул исәптән 93,3 гектар сөрүлек җирләрне эшкәртә. Халыкның күпчелек өлеше крестьян-фермер хуҗалыкларында эшли.

Районның аеруча эре предприятиеләре:
- «Спас опторгы» Кулланучылар җәмгыяте,
- «Сувар Б» ҖЧҖ,
- «Болгар ИКП» ҖЧҖ,
- «Спас икмәге» ҖЧҖ,
- «Болгар» сәнәгать мәйданчыгы (5 резидент),
- «Булгар Арыш» ЯАҖ,
- «Регионстрой» ҖЧҖ,
- «Бункер-Трейд» ҖЧҖ филиалы,
- «Спас коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ,
- «Татнефтепродукт» ХК «Нурлатнефтепродукт» филиалының Спас участогы.
- Киләчәктә «Спас казылыклары» ҖЧҖ ачу күздә тотыла.

Районда 473 эшкуар **теркәлгән.**

Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә Идел буе Болгар дәүләте һәм борынгы Болгар шәһәре (XIII – XIV гасырлар) һәйкәлләре урнашкан, ул ел саен үзенә меңнәрчә туристны җәлеп итә. ЮНЕСКО объектлары исемлегенә кертелгән.

PRESSA.RU

ДӨНЬЯГА АЧЫЛГАН **БОЛГАР**

1722 елда Петр I Казанга килә, аннан соң Болгарга бара. Биредә рус патшасын Кадыйр-Мөхәммәт Сүнчәләй мулла җитәкчелегендәге делегация Иске Рәҗәп авылыннан бөтен шартын туры китереп каршы ала һәм сәяхәтчеләрне хөрмәтләп урнаштыра. Тагын өч йөз елдан соң Иске Рәҗәпнең икенче бер кешесе – Камил Нугаев борынгы бөек шәһәрнең данын бөтен дөньяга тарату өстендә эшли.

– XX гасырда Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы бүгенге кебек үк танылмаган иде әле, гәрчә ул республикада беренчеләрдән булып – 1969 елда барлыкка килгән. Камил Әсгатович район башлыгы булгач, әлеге күренекле урынның потенциалын бәяләп, галимнәр белән бергәләп чиновникларны проектка игътибар иттерә һәм аңа масштаблы ярдәм кирәклегенә ышандыра башлады, – дип сөйли **тыюлык директоры Фәргать Мөхәмматов.**

2004 елда Татарстанның Министрлар Кабинеты музей-тыюлыкны үстерү турында яңа программа кабул итте, 2009 елда Болгарда киңәйтелгән киңәшмә узды – анда Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасының Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу буенча республика фондын («Яңарыш» – «Возрождение») булдыру турында хәлиткеч карар кабул итте. «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» комплексы проекты эшләнде.

– «Яңарыш» фонды масштаблы бурычларны хәл итә, алар монда, урыннарда, тормышка ашырыла. 1998 елдан башлап, ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә керту өчен язылган гаризабыз чиратта торды, һәм, бу вакыйга тормышка ашсын өчен, җирле хакимият мөмкин булганның барысын да эшләде. Бу тырышлыкларның нәтиҗәсен 2014 елда – Катарда ЮНЕСКОның 38 нче сессиясендә күрдек. Россия делегациясенең составында Камил Әсгатович та бар иде, – дип дәвам итә сүзен Фәргать Вагыйзович.

Проектка старт бирелгән көннән алып алты ел үтте. Бүген музей-тыюлыкның инфраструктурасы тулысынча яңартылган. Һәйкәлләргә масштаблы реконструкция ясалган, реставрация эшләре бүген дә дәвам иттерелә, чөнки 600–800 ел элек төзелгән объектлар даими рәвештә карап торуны таләп итә.

– Алты ел эчендә тыюлык фондларына 100 меңнән артыграк археология предметлары керде. Чагыштыру өчен: музей-тыюлыкның моңа кадәрге 50 ел эшчәнлеге вакытында 70 мең предмет тупланган булган, – ди директорның фән буенча урынбасары Андрей Фәсхетдинов. – Аэрофотолар ясау, геофизик тикшеренүләр, иярчен ярдәмендә сканлаштыру кебек технологияләрне кулланып, шәһәрлекнең төгәл топографик чикләре билгеләнде. Шәһәрнең образы торгызылды, һәм бу мөселманнар өчен аеруча изге санала торган урын үзенең чын төсмерен ала бара, дияргә дә була.

Узган сезонда Бөек Болгарга 450 мең турист килгән. Туристлар агымы елдан-ел үсә, шуңа да музей-тыюлык бер урында гына таптана алмый.

Комплексы проектны тормышка ашыру кысаларында музей-тыюлык территориясендә урнашкан йөздән артык йортта яшәүче кешеләр Болгарның уңайлы фатирларына һәм йортларына күчерелгән. Бушап калган биналарның бер өлеше реставрацияләнгән, коммуникацияләр үткәрелә, музейлаштыруга әзерлек эшләре алып барыла. Тиздән биредә бик кызыклы туган якны өйрәнү-этнография комплексы урнашачак.

Быел яр буйларын төзекләндерү буенча эшләрнең беренче этабы төгәлләнгән – ял итү зонасы әзер, ачык һавада төрки-татар язмасы музее эшләнгән. Алга таба төзелеп килүче «Кол Гали» кунакханәсе юнәлешендәге яр буйлары төзекләндереләчәк.

XIV–XV гасырлар үрнәгендәге болгар мунчалары комплексын да (Ак һәм Кызыл пулатлар) үз эченә алган кунакханә төзелеше 2017 елның җәенә тәмамланырга тиеш. Шулай ук Ак мәчет янәшәсендә, музей комплексыннан көньяктарак урнашачак Болгар ислам академиясе төзелеше кызу темплар белән бара.

Музей-тыюлык үсеше Болгар шәһәренең дә үсешенә этәргеч булган. Җирле халык өчен социаль, торак һәм юл төзелеше өлкәсендә яңа проектлар, яңа программалар, яңа мөмкинлекләр гамәлгә ашырыла. Аларның бу эшләрдә катнашуы – Спас районының потенциалын тагын да үстерүгә китерәчәк, ә бу исә алга таба үзенең татлы җимешләрен бирәчәк әле.

Хөрмәтле Камил Әсгатович!
Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы коллективы исеменнән Сезне 60 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Бөек Болгарны реконструкцияләү һәм яңарту проекты кысаларында без Сезнең белән инде озак еллар дәвамында тыгыз хезмәттәшлектә торабыз. Туган ягының мәдәни-тарихи байлыгын бик сирәкләр генә шулай күңелен биреп кайгыртып яши. Көч-егәрегез саекмасын, оптимистик кәеф Сезне беркайчан да ташламасын, барлык проектларыгыз да тормышка ашсын, дип телисе килә! Сәламәтлек һәм озын гомер Сезгә!

Реклама

Ак мәчет.

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ генераль директоры.

МИРАСНЫ САКЛЫЙБЫЗ, КИЛӘЧӘКНЕ ТӨЗИБЕЗ

«Грань» төзелеш компаниясе – Татарстанда иң эреләрнең берсе. Компаниягә нигез салучы Леонид Анисимов сүзләренә караганда, Татарстан Республикасының Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу буенча республика фонды проектларында катнашу – аның өчен бик зур горурлык.

2014 елның 23 июнендә Татарстан Республикасының Спас районында урнашкан Болгар тарихи-археология комплексы ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары исемлегенә керде.

«Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» проекты кысаларында «Грань» компаниясе борынгы Болгар территориясендә төрле пландагы объектлар төзелешен алып барды, алар арасында Ак мәчет комплексы, ислам динен кабул итү хөрмәтенә куелган Истәлек билгесе, Габдрахман коесы, ТР Фәннәр академиясе Тарих институтының Халыкара археологик тикшеренүләр үзәге һәм фестиваль-вакыйгалар комплексы бар.

«Ак мәчет» – хәзерге заман ислам мәдәнияте һәйкәле, ул үзенең гүзәллеге һәм затлылыгы белән таң калдыра, бизәү эшләрендә тышкы яктан да, эчке яктан да Италиядән махсус кайтартылган фил сөяге төсендәге уникаль Bottichino Semiclassico мәрмәре кулланылган. Әлеге мәрмәрне Миланның атаклы «Ла Скала» опера театрының да тышкы ягын бизәүдә файдаланганнар.

«Ак мәчет» комплексы мәчет, мөфти резиденциясе, мәдрәсә һәм гыйбадәт кылу мәйданыннан гыйбарәт. Паркны яшелләндерү өчен, елның төрле фасылында бары тик ак төстә генә чәчәк ата торган үсемлекләр сайлап алынган.

Мәчет белән бер үк вакыта 922 елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итү хөрмәтенә Истәлек билгесе төзелеше дә алып барылган. Бина борынгы Болгар архитектурасы үрнәгендә төзелгән: сигез кырлы, очына ярымай куелган гөмбәзе бар. Истәлек билгесе гөмбәзе астындагы люстра да үзенең зурлыгы белән таң калдыра: аның авырлыгы – 1,5 тонна, биеклеге – 18 метр.

Хәзерге вакытта «Грань» ҖЧҖ Болгар Ислам академиясен, шулай ук мунча комплексы булган кунакханәне (XIV гасырда Болгардагы тарихи Ак пулат бинасының аналогы) төзү белән мәшгуль.

Леонид Анисимов сүзләренә караганда, проект барышында күтәрелгән төзелеш объектлары – заказчылар, проектлаучылар, генераль подрядчы һәм субподряд оешмаларының бер команда булып эшләүләре нәтиҗәсендә уңышлы башкарылган катлаулы да, кызыклы да эшләр.

«Моңа ачык мисалларның берсе – кыска гына вакыт эчендә – нибары 1 ел да 8 айда төзелгән Ак мәчет проекты. Монда район башлыгы Камил Нугаевның өлеше дә зур. Камил Әсгатовичның оештыру сәләте, һөнәри осталыгы һәм яңача фикерле белүе нәтиҗәсендә район Татарстан Республикасында алдынгылар рәтенә чыкты, мәдәни төбәк дигән данын саклап калды.

Камил Әсгатовичның юбилее уңаеннан шәхсән үз исемемнән һәм «Грань» ҖЧҖ коллективы исеменнән ихлас котлау сүзләрен җиткерәсем килә. Юбилярга чын күңелдән алга таба да шундый ук уңышлар, бетмәс-төкәнмәс энергия, күңел көрлеге һәм алга куйган максатларына ирешүен телим!



Ислам динен кабул итү хөрмәтенә төзелгән Истәлек билгесе.

Истәлек билгесе бинасындагы люстра.

* Bottichino Semiclassico – Ботичино Семиклассико.

Реклама

РЕСТАВРАТОРЛАРГА ИҢ КЫЙММӘТЛЕСЕН ЫШАНЫП ТАПШЫРАЛАР

Җәмигъ мәчете, Төньяк төрбә, Хан сарае, Көнчыгыш пулат. Символга әйләнеп, Спас районын гына түгел, бөтен Татарстанны дөньяга таныткан бу һәм башка уникаль объектлар үз тармагында иң тәҗрибәлеләрдән саналган оешма – «Татарстан махсус фәнни-реставрацияләү идарәсе» АҖ тырышлыгы белән торгызыла.

«Татарстан махсус фәнни-реставрацияләү идарәсе» АҖ – зур һәм бай тәҗрибәгә ия оешма – 65 ел элек төзелгән һәм башта «Махсус фәнни-реставрацияләү җитештерү остаханәсе» дип аталган. Идарә коллективына һәрвакыт җирле генә түгел, федераль, ә ул вакытта союз әһәмиятендәге иң кыйммәтле, уникаль объектларны ышанып тапшырганнар. Реставрацияләүнең беренче объектлары булып Казан Кремле диварлары һәм манаралары, Казансудагы һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәл, Болгар шәһәрлеге һәйкәлләре торган. Предприятиенең 65 еллык эшчәнлеге дәвамында гаять зур тәҗрибә тупланган, бик бай архив булдырылган. Коллектив тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрдә ремонтлау-торгызу һәм реставрацияләү проектларын эшләү, фәнни-техник һәм автор күзәтчелеге кебек эшләрнең тулы циклын тормышка ашырган. Бүгенге көндә «ТатМФРИ» АҖ Спас районында «Яңарыш» республика фонды химаясе астында уза торган ТР мәдәни мирас объектларын реставрацияләү буенча генераль подрядчы булып тора. Эшләр Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы объектларында алып барыла. Бу – Җәмигъ мәчет, Ханнар төрбәсе, Кече манара, Ак пулат, Кара пулат, Көнчыгыш төрбә, Кече шәһәрчек, Кызыл пулат, Хан мунчасы, Хан сарае, төрбәләр комплексы, халык өчен төзелгән объектлар…

Үткәннәр хакында тирәнтен уйлап, белем һәм тәҗрибәне кушып эш итү «ТатМФРИ» АҖен башкалардан аерып тора. Компания проектлау-тикшеренү, ремонт-реставрацияләү һәм төзү-монтажлау эшләрен алып бару өчен кирәк булган барлык төр лицензияләргә, җитештерү базасына ия. Транспорт һәм агач эшкәртү цехы, тимерчелек цехы бар. Архитекторлар, конструкторлар, инженер-техник персонал, реставрацияләү белгечлеге булган эшчеләрдән торган тәҗрибәле коллектив исә компаниянең аерым горурлыгы булып тора. «ТатМФРИ» АҖ составында РФ Мәдәният министрлыгы аттестациясен узган 50дән артык хезмәткәр эшләп килә. Коллектив исәбендә, мәдәни һәм тарихи кыйммәткә ия булып, реставрация узган йөздән артык объект бар, алар арасына ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары да керә.

Әлеге форсаттан файдаланып, «ТатМФРИ» АҖ җитәкчелеге ТР Спас районы башлыгы Камил Әсгатович Нугаевны якынлашып килүче юбилее белән тәбрик итә. Югары дәрәҗәдәге һөнәрилек, максатчанлык, җаваплылык хас җитәкче буларак, Камил Әсгатович хезмәттәшләре һәм район халкы арасында зур ышаныч һәм тирән ихтирам казанды. Компания коллективы аңа чын күңелдән эшендә зур уңышлар, уй-ниятләренең тормышка ашуын, бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман, ныклы сәламәтлек, күтәренке кәеф, гаилә иминлеге тели. Һәрвакытта да ярдәм кулы сузарлык дуслар, ышанычлы фикердәшләр юлдаш булсын!

Реклама

PRESSA.RU

ЮЛ САЛУЧЫ КЕШЕЛӘР

Югары тизлекләр һәм заманча технологияләр гасырында юлчылар үзләренең алдына яңа бурычлар куя. Республикадагы зур масштаблы юл төзелеше нәтиҗәдә меңнәрчә кешеләрнең тормышын яхшы якка үзгәртә.

Менә берничә ел инде «Алексеевскдорстрой» ААҖ, эшләренең географиясен киңәйтеп, ел дәвамында Татарстанның алты районында төбәк һәм федераль әһәмияттәге юлларны тәртиптә тота. Элеккегечә үк ул өч район: Алексеевск, Әлки һәм Спас районнары өчен бюджет булдыручы предприятие булып тора.

2007 елда Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нугаевның инициативасы һәм турыдан-туры булышлыгы белән «Татавтодор» ПРТБнең Спас филиалы базасында «Алексеевскдорстрой» ААҖнең Спас участогы төзелде. Аның төп функцияләре шул ук кала – төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары төзелеше, аларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту.

Спас участогының эшли башлавына әле дистә ел үтмәсә дә, бик зур эш башкарылган инде. Автомобиль юллары техникасы һәм җиһазларының кирәкле паркы булдырылган. Юлчыларның үз асфальт-бетон заводы, җылытылган туктап алу урыны һәм автомастерскойлары бар. Бүген Спас участогы хезмәт күрсәтә торган өлкәгә керә торган юлларның озынлыгы 300 километр чамасы. Ышанычлы җитештерү базасы булдыру, чаралар һәм персонал белән идарә итү системасын модернизацияләү бүгенге көндә әлеге участокка үз эшендә салкын регенерация методы, полимер-битум беркеткеч материал куллану, грунтны органик һәм неорганик беркеткеч материаллар белән ныгыту кебек заманча методлар һәм технологияләр кулланырга мөмкинлек бирә…

«Алексеевскдорстрой» ААҖнең Спас участогы «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре», Казанда уздырылган 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиада һәм 2015 елгы Су спорт төрләре чемпионаты кебек республика өчен глобаль проектларны тормышка ашыруда катнашты.

«Алексеевскдорстрой» ААҖнең Спас участогында заманча технологияләрне һәм методларны бик хаклы рәвештә предприятие ышанычлылыгы чылбырының бары тик бер буыны гына дип саныйлар. Биредә кадрлар белән эшкә бик зур игътибар бирелә. Компетентлы хезмәткәрләрнең никадәр мөһим булуын аңлап, участок җитәкчелеге үз вакытында булачак кадрлар – студентларны укыту турында карар кабул итә. Бүген егетләрнең алтысы, укуларын тәмамлап, участокта мастерлар һәм белгечләр булып хезмәт итә, өчесе әлегә белем алуларын дәвам итә.

Буыннар алмашының көчле үсеше дә предприятие коллективының ныклы булуы турында сөйли. Еш кына әти-әниләр бергә үзләренең улларын алып килә, бүген Спас участогында биш хезмәт династиясе хезмәт куя. Кадрларның даимилеге, тотрыклылыгы, әлбәттә, буш урында барлыкка килмәгән – хезмәткәрләренең эш һәм көнкүреш шартлары, хезмәт хакы дәрәҗәсе, эшләүчеләрнең һөнәри үсеше турында кайгыртуны җитәкчелек үз эшчәнлегендәге өстенлекле юнәлешләренең берсе, дип саный.

Юл тармагында эш җиңелләрдән түгел, заманалар да катлаулы тора. Әмма район хакимияте башлыгы ярдәм итеп торганда, «Алексеевскдорстрой» ААҖнең Спас участогында предприятие алдында торган һәр бурычны үтәргә тырышалар. Әйтергә кирәк, алар моны булдыралар да.

Хөрмәтле Камил Әсгатович!

Сезне чын күңелдән олы юбилеегыз – 60 яшьлегегез белән тәбрик итәбез. Менә 22 ел инде Сез Спас районы белән җитәкчелек итәсез, бу сан үзе үк якташларыгызның Сезгә ышанычы һәм хөрмәте турында сөйли. Әлеге вакыт эчендә районның барлык йортларына газ керде, һәр авылга, иң ерактагысына да, каты өслекле юллар алып бара. Ә Сезнең турыдан-туры катнашлыгыгыз нәтиҗәсендә «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» проектын тормышка ашыру шәһәр һәм район тормышында уңай үзгәрешләргә китерде. Уртак максатларыбызны чишүгә зур өлеш кертүегез өчен без Сезгә бик рәхмәтле.

Сез туган ягыгыз язмышына чыннан да битараф түгел. Әлеге мөмкинлектән файдаланып, Камил Әсгатович, Сезне юбилеегыз белән котлыйбыз, ныклы сәламәтлек һәм Спас районын алга таба да үстерү юнәлешендә нәтиҗәле хезмәт кую өчен җитәрлек көч-дәрман телибез.

Реклама

PRESSA.RU

«РЕГИОНСТРОЙ» ҖЧҖ: «СЫЙФАТНЫ ГАРАНТИЯЛИБЕЗ»

«РегионСтрой» ҖЧҖ Спас муниципаль районы үсешендә актив катнаша. Әһәмиятле дәүләт заказларын тормышка ашырганда подрядчының профессиональлеге һәм намуслылыгы беренче планга чыга, шуңа күрә төп, катлаулы объектлардагы эшне әлеге компаниягә ышанып тапшыралар. Предприятиенең өстенлекләре арасында – эшләрнең югары сыйфатлы булуы. Бу «ТР БИТИ» ДКУ, «ТР ТКХ Фонды» Коммерциячел булмаган оешмасы кебек төп заказчылар тарафыннан раслана.

2012 елда Болгарда оештырылган «РегионСтрой» ҖЧҖ – Татарстанның Спас районында хезмәт күрсәтүләрнең киң спектрын тәкъдим итә торган иң эре подряд оешмаларының берсе. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып канализация, сууткәргеч, җылыту һәм газ үткәрү системаларына капиталь ремонт ясау тора. Шулай ук түбә һәм фасадларны төзү, эчке биналарны реконструкцияләү һәм капиталь ремонт эшләре дә башкарыла. 2013 елдан «РегионСтрой» ҖЧҖ «ТР Төзүчеләр берләшмәсе» үзкөйләнешле оешма әгъзасы булып тора.

Үз предприятиесенең көндәшлекле өстенлекләре турындагы сорауга җавап биреп, генераль директор Артём Тюнев болай диде: «Безгә тапшырылган һәр эшне намус белән башкарабыз». Шундый профессиональ коллектив белән эшләгәндә моңа гаҗәпләнәсе дә юк. Предприятиедә инженер-техник хезмәткәрләрнең составы тотрыклы, бу – бүгенге көндә төзелеш тармагы өчен бик сирәк күренеш. «РегионСтрой» ҖЧҖндә һәркем (ә биредә 38 кеше эшли) – үз эшенең остасы.

Эшчәнлек дәверендә «РегионСтрой» үзен федераль һәм республика дәүләт программаларын тормышка ашыруда ышанычлы подрядчы итеп таныытты. Мәсәлән, компания торак йортларны капиталь ремонтлау белән шөгыльләнә. Шулай ук мәктәпләргә капиталь төзекләндерү үткәрү буенча да уңышлы тәҗрибәсе бар. Генераль подрядчы булып торган «РегионСтрой» көче белән Спас муниципаль районындагы Полянка урта гомуми белем бирү мәктәбе ремонтланды:

– Бу объект – 1983 елда төзелгән тузган бина, һәм биредәге шартларда белем алу бик авыр. Ремонтланган мәктәп Белем көне уңаеннан Полянка авылы балаларына зур бүләк булды. 1 сентябрьдә укучылар укуга әзер, матур сыйныф бүлмәләренә килделәр. Үз эшеңнең нәтиҗәләрен күреп, күңел сөенә! – ди Артём Тюнев.

Компания уңышларга иреште, тармак буенча хезмәттәшләренең ихтирамын яулады, әмма хезмәткәрләренең квалификациясен күтәреп, эшчәнлегенең юнәлешләрен киңәйтеп, үз үсешен дәвам итә. Шундый юнәлешләрнең берсе – җитештерү базасын булдыру һәм камилләштерү.

– Без үзебезнең тимер-бетон эшләнмәләр ясау юнәлешен үстерәбез, кое боҗралары, фундамент блоклары, керамогранит блоклар, брусчатка, поребриклар ясыйбыз. Кирәкле җиһаз яисә төзелеш материалын сайлап, заказчы барысыннан да элек җитештерүченең абруена карый. Ә ул, үз чиратында, сыйфат, бәяләр дәрәҗәсе кебек факторлардан тора. Без һәрвакыт кирәкле балансны сакларга тырышабыз, – дип сөйли генераль директор.

Аның сүзләренчә, дәүләт заказы белән эшләү һәрвакытта да җиңел түгел: башкару вакыты тар, ә эшнең сыйфатына таләпләр югары. Әмма муниципаль хакимият сөйләшүгә әзер икән, барысына да ирешергә мөмкин.

– Спас муниципаль районы башлыгы – профессиональ, җаваплы һәм хөрмәтле җитәкче. Үзем һәм «РегионСтрой» ҖЧҖ хезмәткәрләре исеменнән Камил Әсгатовичны юбилее белән котлыйм. Аңа нык сәламәтлек, гаилә һәм хезмәттәшләренең ышанычлы тыл булуын, тормыш дәрте һәм барлык башлангычларында да уңышлар телим.

Реклама

КҮПЕРЛӘР
ҺӘМ ДУСЛЫК

Без Болгарның бер урамыннан үтеп барабыз. Сары кирпечтән төзелгән ике йорт сүрән октябрь фонында җылылык сирпеп тора.

– Бу йортларны «Сувар Б» компаниясе Дәүләт торак фонды проектында каралган ятим балаларны торак белән тәэмин итү программасы буенча төзеде. Җылылык, электр, су – барысы да бар, – ди шәһәр хакимиятеннән безне озатып йөрүче вәкил. – Ә гомумән алганда, «Сувар Б» – шәһәр буенча «кизү торучы» кебек. Юлларны, күперләрне карап тоту, суүткәргеч челтәрен тиз арада ремонтлау – барысы да алар өстендә.

Компаниянең зур булмаган офисында фирма җитәкчесе Арутюн Багдасарян белән очрашабыз. Ул «Сувар Б» компаниясенең 50 хезмәткәренә эш даими рәвештә, хәтта тәүлек әйләнәсе табылып торуы турында сөйли. Тик беркем дә зарланмый – хезмәт хаклары яхшы, вакытында түләнә, аннары үз шәһәреңне чисталыкта һәм тәртиптә тотасы да килә бит.

Кайчандыр компания «Татавтодор»ның филиалы булган, район территориясендә юллар төзү һәм аларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнгән. 2005 елда мөстәкыйльлек алган. Матди-техник базасыннан һәм белгечләреннән штатыннан башлап, бу предприятиене Арутюн Багдасарянга һәм баш инженер Сергей Князевка чынлыкта нульдән башлап төзергә туры килгән.

– Тора-бара, юлларны һәм күперләрне (алар районда 17) ремонтлау һәм яхшыртудан тыш, республика һәм федераль программалар кысаларында торак һәм җәмәгать объектларын ремонтлау эшләренә күчтек. Бүген Болгардагы бер генә шундый проект та безнең катнашыбыздан башка үткәрелми, – ди «Сувар Б» директоры.

Соңгы өч елда районда фельдшер-акушерлык пунктлары гына да дистәдән артык төзелгән, модульле ветеринария пунктлары – беркадәр кимрәк. Социаль сфера: балалар бакчалары, мәктәп объектларына капиталь ремонт, урам спорт мәйданчыкларын төзү һәм җиһазландыру – болары да «Сувар Б» эше.

– Истә калган берәр объектыгыз бармы?

– Гомумән алганда, бу, әлбәттә, иске эш, әмма, чыннан да, яхшы гына түгел, җаныңны бирердәй тырышып эшләгән эшләр дә була, – ди Арутюн Хачикович. Һәм исенә төшерә: дүрт еллап элек Антоновка (кайчандыр Бизнә булган) авылында мәктәп ремонтлаганнар.

– Мәктәп – Мусин-Пушкиннар утары бинасы, XIX гасырның беренче яртысына караган архитектура һәйкәле. Эшләр алып бару түгел, атлап йөрергә дә куркыныч: саксызлык аркасында берәр нәрсәгә зыян китерергә мөмкин бит. Мондагы ишек уемы 2,7 метр булып чыкты, һәм кечерәйтергә ярамый! – дип искә ала «Сувар Б» директоры. – Нәтиҗәдә ишекне махсус заказ белән алып килдек. Тәрәзәләрне, идәнне, түбәне алыштырдык. Бинага зыян китермәс өчен, бик тырыштык. Катлаулы, әмма бик кызыклы эш булып чыкты. Бу йортка 200 ел диярлек, бик яхшы төзелгән. Әле тагын озак торачак!

Хәзер предприятиедә кышны көтәләр, башка бик күп шәһәрләрдән аермалы буларак, ул Болгар урамнарына көтелмәгән бәла булып килми. Кешеләр дә, техника да, беренче кардан арыну өчен кирәкле катнашмалар да алдан ук әзер. Кар күп яуганда да урамнар вакытында чистартыла.

– Шәһәр кечкенә, барысы да күз алдында. Начар эшләргә гомумән ярамый – аннары кешеләрнең күзләренә ничек карыйсың? – дип, үз фирмасы хезмәткәрләренең намуслы хезмәтен бәяли Арутюн Хачикович.

Сүз уңаеннан, октябрь аенда Болгарда аның өчен һәм бөтен әрмән җәмгыяте өчен әһәмиятле вакыйга була – шәһәрдә Арутюн Хачикович Әрмәнстаннан махсус алып кайткан хачкар – иман символы саналган уеп ясалган стела-тәре урнаштырыла. Бу урында озакламый чын әрмән кәшәнәсе төзеләчәк.

– Әрмән җәмгыяте монда бик ерак заманнарда ук оешкан. Без бу як халыклары белән һәрвакыт дус һәм тату яшәдек, – дип сөйли «Сувар Б» директоры. – Һәм мин чын күңелдән Спас районы башлыгы Камил Нугаевка, ризалык биреп, кәшәнә төзү планнарыбызны хуплавы өчен рәхмәтлемен. Бу биредә, Татарстанда, төрле халыкларның дуслыгы һәм үзара хөрмәте турындагы сүзләр артында чын эшләр һәм казанышлар торуын раслый.

Хөрмәтле Камил Әсгатович!
Сезне чын күңелемнән юбилеегыз белән котлыйм! Мәнә 20 елдан артык инде без Сезнең белән янәшә эшлибез, һәм мин, курыкмыйча, Спас районы үзенең җитәкчесеннән бик уңды, дип әйтә алам. Сез әлеге вазыйфада эшләгән елларда күп, хәтта бик күп эшләр башкарылды. Районның соңгы еллардагы барлык казанышлары – күбесенчә Сезнең хезмәтегез нәтиҗәсе. Шул ук вакытта Сез намуслы, ачык һәм бик тыйнак кеше, хөрмәткә лаек шәхес булып каласыз. Йортыгызда һәрвакыт тынычлык һәм иминлек хөкем сөрсен, барлык проектларыгыз да тормышка аша барсын. Чын күңелдән сәламәтлек, уңышлар һәм иминлек телим!

Реклама

«СТРАТЕГИК» ОРЛЫК **САКЧЫЛАРЫ**

Лаборант Галина Александровна орлыкларны сканер пыяласына тарата. Берничә минуттан Болгар икмәк кабул итү пунктында кабул ителгән ашлыкның ГОСТка туры килү-килмәвен һәм яңа партиядә күпме чүп һәм орлык кушылмалары булуын беләчәкләр.

– Бу сканер – без тыгыз хезмәттәшлек итә торган Санкт-Петербург фирмасының тест үрнәге, – дип аңлата предприятие директоры Юрий Костин. – Мондыйлар нибары өч-дүрт Россия компаниясендә генә бар. Берникадәр вакыт элек безнең компания тулысынча техниканың соңгы сүзе буенча яңартып җиһазландырылды. Шулай булгач, без анализларны бик тиз һәм сыйфатлы итеп үткәрә алабыз.

«Болгар ИКП» ҖЧҖ бүгенге көндә «Татархлебопродукт» ААҖнең кайчандыр шактый зур системасыннан аерылып чыккан. 2013 елда предприятие шәхси кулларга күчкән, шуннан соң нигезеннән үзгәртеп корылган.

– Бүгенге көндә безнең Спас, Әлки, Алексеевск районнарыннан, һәм шулай ук Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районыннан 60лап тәэминатчыбыз бар. Авыл хуҗалыгы – район икътисадының төп өлешләреннән берсе. Ашлыкны күп үстерәләр, шулай булгач, сезонында безнең складларның барысы да диярлек тула – әйтик, быел җәй сыйдырышлыгы 32,2 мең тонна булган складлардан 30 мең тонна ашлык төяп-озаттык, – дип сөйли Юрий Сергеевич.

Директор шуны да билгеләп үтә: соңгы елларда фермерларның маркетинг ягыннан белемнәре дә арткан. Шәхси затлар тапшыра торган ашлык ГОСТка туры килә һәм өстәмә эшкәртүне таләп итми.

Кабул иткәннән һәм экспертиза ясаганнан соң, ашлыкны киптерәләр һәм складларга урнаштыралар, аннан соң сатып алучыларга җибәрәләр. Фураж ашлыгын, мәсәлән, – Санкт-Петербург, Кострома, Рыбинск һәм башка Россия шәһәрләренә комбиазык җитештерүче өчен. Азык-төлек өчен, Казанга, Яр Чаллыга, Пермьгә озаталар.

Моннан тыш, Болгар ИКП, инде берничә ел дәвамында аккредитациясен раслап, федераль интервенция фондының ашлык запасын саклаучы ике йөздән артык предприятиесе исемлегенә керә. Ил базарында ашлык һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясенә кытлык булу очрагына, оешма складында мең тонна ашлык саклана.

Күптән түгел предприятиедә чистартылмаган көнбагыш мае җитештерүне үзләштергәннәр. Чиста, иркен цехта чималны Россиядә җитештерелгән агрегатлар бер ритмда эшкәртә. Биредә, эшкәртүнең берничә этабын үткәч, көнбагыш орлыгы массасы хуш исле алтынсу майга һәм пластмасса кисәкләре сыман прессланган түпләргә әверелә. Анысын да, монысын да комбиазык җитештерүчеләр сатып ала.

– Италиянең зәйтүн мае җитештерүчеләре беренче – салкын сыгу ысулы белән алынган майны экологик яктан иң чистасы һәм файдалысы дип саный. Без нәкъ менә шундыйны алабыз, димәк, теоретик яктан аны ризык өчен дә кулланырга мөмкин, – дип сөйли директор.

Әлеге продукциягә ихтыяҗ үсә бара, планнарында – тагын бер җитештерү линиясен урнаштыру, нәтиҗәдә май җитештерү күләме ике тапкырга диярлек артыр, дип көтелә.

– Узган берничә елның корылык ягыннан катлаулы булуына карамастан, безнең тәэминатчыларыбызның саны кимемәде. Район җитәкчелеге җирле фермерларга актив ярдәм итә. Һәм безнең предприятиедә игенчеләр уңышларын үз вакытында һәм яхшы бәягә тапшыра алсын өчен, барысы да эшләнә. Район икътисады һәм гомумән республиканың авыл хуҗалыгы тармагы үсешенә үз өлешебезне кертү – безнең төп бурычыбыз, – ди, сүзен йомгаклап Юрий Костин.

Хөрмәтле Камил Әсгатович!

«Болгар ИКП» ҖЧҖ коллективы исеменнән Сезне 60 яшегез тулу белән ихластан котлыйбыз! Бу күркәм юбилей белән котлап, Сезнең оста җитәкче генә түгел, ә туган ягызының чын патриоты булуыгызны да билгеләп үтәсебез килә. Профессиональлегегез чын хөрмәт һәм соклану хисләре уята. Сез район белән җитәкчелек итеп кенә калмыйсыз, ә бәлки анда күптөрле социаль-икътисадый тармаклар динамик үсештә булган уникаль климат та тудырасыз, әлеге үсешнең чын алгарыш көче булып торасыз. Юбилеегыз алдыннан без Сезгә чын күңелдән шундый ук энергияле, максатчан, үз идеяләрегез белән башкаларны илһамландыручы һәм дәртләндерүче булып калуыгызны телибез! Сәламәтлек, уңышлар, бәхет Сезгә!

Реклама

АВЫЛ ЯШӘСЕН!

Авыл йортының капка төбендә өч әби басып тора. Юлга караганнар, ни өчендер борчылалар. Ә, бәлки, килмәс? Һәм менә машина күренә. Бу – автолавка, Спас районы авылларының берсендә өчәү генә яшәп калган әбигә кирәк-ярак – шикәр, чәй, май, кәнфит алып килүе. Кайчакта әбиләр бәйләм җепләре, нинди дә булса дарулар алып килүне дә сорыйлар. Автолавка әбиләрнең гозерләрен кире какмый.

– Автолавкалар системасын саклау – табышлы эш түгел. Шуңа да карамастан, бу бик мөһим социаль бурыч. Хәтта безнең районда да яшәүчеләр саны иллегә дә җитмәгән авыллар күп. Халык көндәлек куллану товарларын һәм азык-төлекне, шәһәргә бармыйча, безнең аша гына алырга мөмкиннәр, – дип сөйли «Спас опторгы» Кулланучылар җәмгыяте директоры Марина Андриянова. – Кечкенә авылларны үстерә алмасак та, без аларны яшәтүгә шул рәвешле үз өлешебезне кертергә тырышабыз.

– Кайчандыр кулланучылар кооперативлары бик популяр иде. Бүгенге көндә әлеге система республика җитәкчелеге ярдәме белән, зур тырышлык исәбенә саклана. Конкуренция бик югары. Шул ук вакытта мин сатып алучыларның безнең цехларда җитештерелгән продукцияне сайлауларын күрәм. Алар безгә ышаналар, – ди Марина Николаевна.

«Спас опторгы»ның шәһәрдә 4 сәүдә ноктасы һәм 4 гомуми туклану урыны һәм районда 26 кибете бар. Оешма тулысынча үз акчасына көн күрә. Ай саен чыгарыла торган продукциянең күләме тонналар белән исәпләнә, шул ук вакытта аны нибары 28 кеше җитештерә. Пилмән цехында, мәсәлән, өч хатын-кыз эшли. Бер айда алар кулдан тонна ярым пилмән бөгә!

– Безнең төп ассортимент – камыр ризыклары һәм кондитер эшләнмәләре. Барысын да үзебез җитештерәбез. Билгеле инде, традицион ысул белән, сөттә һәм йомыркада әзерлибез, синтетик катнашмаларда түгел. Кабып карагыз – үзегез дә күрерсез! – ди опторг директоры.

РАЙПОда каралганча, оешма авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү белән шөгыльләнә. Аны районда яшәүчеләрдән сатып ала. Быел, ит һәм йомыркадан тыш, каен бөресе, зәңгәр мәтрүшкә, сары мәтрүшкә кебек үләннәр дә сатып алганнар.

– Даими рәвештә башка шәһәрләрдәге төрле чараларга – бәйрәмнәргә, тантаналарга, ярминкәләргә дә чыгабыз. Безне һәрвакыт чакырып торалар, һәм без сынатмыйбыз. Казанга традицион авыл хуҗалыгы ярминкәләренә барабыз. Һәм ни өчендер елдан-ел безнең төп товар карабодай ярмасы булып чыга. Спас карабодаена хәтта чират тезелә. Менә шундый феномен! – дип елмая Марина Николаевна.

Предприятие хезмәткәрләре – Болгардагы ярминкәләр булсынмы, иҗади хисапламы – даими рәвештә үз проектларын да тормышка ашыралар. Берничә ел элек хәйриячелек аерым юнәлешкә әверелгән.

– Егерме ел элек Спас районының хәзерге башлыгы Камил Нугаев искиткеч традиция – хәйрия марафонын булдырды. Ел саен февраль аеның бер көнендә без махсус хәйрия фондына актив рәвештә акча җыябыз. Эре оешмалар да, кечеләре дә катнаша. Бу акчалар инвалидларга, ятимнәргә һәм аз керемле гражданнарның башка категорияләренә юнәлтелә, – дип сөйли Марина Андриянова. – «Мәктәпкә җыенырга булыш!» еллык акциясе яхшы нәтиҗәләр белән узды. Һәм без үзебез, Спас опторгы да, зур булмаган хәйрия эшләре башкарабыз. Безнең шундый мөмкинлегебез булуына бик шатбыз.

Хөрмәтле Камил Әсгатович!
Җайлы итеп җитәкчелек итә алыр өчен, һәрчак эш башында тора белү, идарәче сәләте, һәм тагын әллә никадәр күркәм сыйфатларга ия булу кирәк! Сезгә оештыру сәләте, лидерлык таланты хас!
Камил Әсгатович, бүген Сезне юбилеегыз белән котлау форсаты туганга бик шатбыз. Уңышлар, иминлек, тотрыклылык һәм бәхет телибез. Җан тынычлыгы һәм сәламәтлек юлдаш булсын Сезгә!

Реклама

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА ЭЛЕКТРОН ЮЛ БЕЛӘН ЯЗЫЛУ

PRESSA.RU САЙТЫНДА ОНЛАЙН ЯЗЫЛУ:



1. »ЖУРНАЛЫ» төймәсенә БАС



2. «ОБЩЕСТВО И ПОЛИТИКА» бүлегенә КЕР

3. «ТАТАРСТАН» журналына КЕР

4. «КУПИТЬ» төймәсенә БАС

Реклама 16+

ТИЗ / ҖИҢЕЛ / АРЗАН

МАХСУС ПРОЕКТ

17нче чыгарылыш

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

ТҮБӘН КАМА – ТОРМЫШЫНЫҢ БӨТЕН МӘГЪНӘСЕ

Хезмәт биографиясен үз коллективында иң «түбәннән» башлаган җитәкчеләр әллә ни күп түгелдер. Күз алдына гына китерегез: әле мыегы да чыкмаган яшүсмер, оешмага килеп, өйрәнчек булып эшли башлый да, тора-бара, хезмәт баскычы буйлап күтәрелә-күтәрелә, коллективның беренче кешесенә әверелә. Мәхмүт Миңгалим улы Гатин, «Татэлектромонтаж»ның Түбән Кама монтаж идарәсе җитәкчесе, – әнә шундый сирәк кешеләрнең берсе.

Мәхмүт Миңгалимович Гатин сугыштан соңгы беренче елның 7 ноябрендә Татарстан АССРның Чирмешән районы Бәркәтә авылында туа. Бөек Ватан сугышыннан соң килгән беренче унъеллык – бөтен ил өчен авыр чор. Мәхмүт Миңгалимович үзен белә-белгәннән бирле гел хезмәттә. Нәрсәгә дә булса ирешергә телисең икән, укырга кирәклеген ул бала чагыннан ук яхшы аңлый. Әмма башта үзен тикшереп карарга уйлый – нәрсә үзенә туры килә, нәрсә кызыклырак. 1964 елда, ун классны тәмамлагач, «Татэлектромонтаж» трестының Әлмәт монтаж идарәсенә электромонтёр өйрәнчеге булып эшкә урнаша. Һәм аңлый: бу «фән» – аныкы. Шуннан 1965 елда Казан химия-технология институтының кичке бүлегенә укырга керә. Эш белән укуны бергә алып барып, 1971 елда инженер-технолог дипломына ия була.

1972–1973 елларда армиядә хезмәт итә һәм Түбән Кама ТКМИга инде мастер булып кайта. Аннары инде хезмәт баскычлары буйлап күтәрелә: мастер, прораб, өлкән прораб, җитәкче.

Түбән Кама монтаж идарәсе Мәхмүт Миңгалимович өчен тормышының аерылгысыз бер өлешенә әверелә. Язмышына шулай язылган инде: 52 елын ул шушы оешмага багышлый, аларның 34ендә коллективка җитәкчелек итә. Бу озак еллар арасында ниләр генә кичерелмәгән дә, күпме генә проблемалар хәл ителмәгән!

Мәхмүт Миңгалимович идарәнең Мактау грамоталары (1973, 1980 еллар), «Намуслы хезмәт өчен» медале (1970 ел) белән бүләкләнгән. Аңа «Идарәнең кадр хезмәткәре» исеме бирелгән. Ул «1979 елның социалистик ярышы җиңүчесе», «Главэлектромонтаж»ның Мактау грамотасы (1982 ел), «В.И. Ленинның 100 еллыгы уңаеннан намуслы хезмәт өчен», «Хезмәт ветераны» (1989 ел), «Россия профсоюзларына 100 ел» (2005 ел), «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» (2005 ел) медальләре белән бүләкләнгән. Мәхмүт Миңгалимовичка Татарстан Республикасы Премьер-министрының Рәхмәт хаты («Түбән Кама Нефтехим» ААҖнең бензиннар заводын сафка бастырган өчен, 2005 ел), Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты (күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен, 2006 ел) тапшырылган, РФ Төбәкара үсеш министрлыгының Мактау грамотасы (2007 ел), ЭМОНның «Алтын билге» дип аталган Мактау билгесе белән бүләкләнгән ул. Татарстан АССРның атказанган төзүчесе (1990 ел), РФнең Мактаулы төзүчесе (2009 ел). Шәһәрнең Мактау тактасына куелган. Түбән Каманың мактаулы гражданины.

Кадерле Мәхмүт Миңгалимович!

70 яшьлек юбилеегыз уңаеннан ихлас йөрәктән чыккан котлауларыбызны кабул итеп алыгыз! Сез иң югары квалификацияле профессионал, оста җитәкче, һәм бу Сезнең тормышыгызның төп мәгънәсе. Сез – Түбән Кама монтажлау идарәсенең йөзе. Озак еллар дәвамында компаниянең барлык хезмәткәрләре өчен хезмәт сөючәнлек һәм фидакарьлек үрнәге булып торасыз. Абруегызның чыганагы – чын һөнәри осталык, кешеләрне туплый, эш белән мавыктыра һәм аларны фикердәшләрегез итә белүегез.

Сез күңелегез белән яшь, дәрт-дәрманыгыз ташып тора! Алга таба да игелекле эшләр, яңа казанышлар юлдаш булсын, уй-ниятләрегезнең тормышка ашуын телибез!

Иң яхшы теләкләр белән, Юрий Солуянов,
«ТАТЭЛЕКТРОМОНТАЖ» АҖнең
генераль директоры.

Реклама

Мәхмүт Гатин

52 ЕЛ БУЕ БЕР ПРЕДПРИЯТИЕДӘ!

Ярты гасырдан артык гомере яраткан предприятиесенә бирелгән. Җитди һәм сокландыргыч сан, гаҗәеп зур тәҗрибә. Өйрәнчек, электр монтажчысы, участок мастеры, эшләрнең өлкән җитештерүчесе, предприятие җитәкчесе, Директорлар советы рәисе. «Татэлектромонтаж»ның Түбән Кама монтаж идарәсе башлыгы Мәхмүт Гатин нәкъ менә шундый мактаулы юл үткән.

Мәхмүт Миңгалимович Түбән Камадагы һәр объект төзелешенең чишмә башында торган һәм аларда үзе дә актив катнашкан. Бу «Түбән Кама Нефтехим» да, шиннар заводы да, ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2 дә, техуглерод заводы да, Түбән Кама НЭЗ, торак йортлар, социаль һәм мәдәни объектлар, чиркәү һәм мәчетләр, боз сарае да... Түбән Кама монтаж идарәсе шулай ук КАМАЗ, «Россельмаш» заводы, «Алабуга» МИЗ, Түбән Кама НЭЗ, Мәскәү һәм Казан метрополитеннары һәм башка бик күп объектларны торгызуга үз өлешен керткән.

Мәхмүт Гатинның дөрес җитәкчелеге нәтиҗәсендә, Түбән Кама монтаж идарәсе хаклы рәвештә базарда әйдәп баручы санала, бу турыда күпсанлы бүләкләре дә сөйләп тора. 2004 елда ТКМИ Россиянең иң яхшы 150 төзелеш оешмасы рейтингына* кергән. Предприятиенең эшчәнлеге иң яхшы төзелеш оешмасын, төзелеш материаллары һәм төзелеш индустриясе предприятиесен ачыклау буенча үткәрелгән Бөтенроссия конкурсында – төзелештә һәм төзелеш материаллары сәнәгатендә югары нәтиҗәлелеккә һәм көндәшлелеккә ирешкән өчен – биш тапкыр җиңүче дипломы белән билгеләп үтелгән. Идарә «Европа сыйфаты» алтын медале белән бүләкләнгән, 2005, 2006 һәм 2009 елларда «Ел предприятиесе» премиясе лауреаты. 2009 елда иң яхшы төзелеш оешмасына XIII Бөтенроссия конкурсы нәтиҗәләре буенча ТКМИ «Россия төзелеш комплексы элитасы»на кертелә һәм берничә ел рәттән әлеге югары исемне раслап килә.

Мәхмүт Миңгалимович – иң югары дәрәҗәдәге профессионал, күпсанлы титулларга һәм исемнәргә ия: Татарстан АССРның атказанган төзүчесе, Россиянең мактаулы төзүчесе, хезмәт ветераны, Россия төзүчеләре профсоюзы премиясе лауреаты. Әмма ул «Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданины» дигән исемне үзе өчен иң кадерлесе дип саный. Бу исемне ул үзенең хатыны Алла Алексеевна белән бүлешә. Алар тормышта күп еллар буе бер-берсе белән янәшә атлый – бергә, бер төркемдә укыганнар, бер бригадада эшләгәннәр, бер ул һәм ике кыз үстергәннәр, ә хәзер дүрт оныкһәм ике оныкчыкны иркәли һәм тәрбиялиләр.

Хөрмәтле Мәхмүт Миңгалимович!

Безнең иң җылы һәм ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз. Һөнәри осталыгыгыз, максатчанлыгыгыз, коллегаларыгыз һәм клиентларыгызга игътибарлы мөнәсәбәтегез, югары хезмәт мөмкинлекләрегез һәм креативлыгыгыз Сезне талантлы һәм абруйлы җитәкче буларак башкалардан аерып тора. Тупланган тормыш тәҗрибәгез һәм зирәклегегез Сезгә яңа биеклекләр яуларга булышсын! Күңел түрегездәге теләкләрегез һәм омтылышларыгыз гамәлгә ашсын, тормышыгызда булган бар яхшы нәрсәләр саклансын, шатлык, мәхәббәт һәм күңел күтәренкелеге күп тапкырларга артсын. Уңыш, бәхет һәм илһам – Сезнең барлык башлангычларыгызда, ә сәламәтлек һәм иминлек көндәлек тормышыгызда тугры юлдаш булсын.

Җитештерүчән актив хезмәт, яңа иҗади идеяләр, отышлы гамәлләр, киң мөмкинлекләр һәм перспективалы проектлар, ышанычлы партнёрлар һәм намуслы коллегалар, уңышлы эшләр һәм барлык уйланганнарның тормышка ашуын телибез.

Иң изге теләкләр белән,
***Роман Чигарьков**, «ТСНХМ» ИК» ҖЧҖ генераль директоры,*
***Василий Носов**, МТМЛ КТ генераль директоры, «ТСНХМ» ИК» ҖЧҖ гамәлгә куючылар советы рәисе.*

Реклама

* Россия төзүчеләр берлеге версиясе буенча рейтинг.

Рифгать Вәлиев,
«Термостепс» ТКМИ» ААҖнең генераль директоры

Сез бик күп искиткеч проектларны тормышка ашырдыгыз

Хөрмәтле Мәхмүт Миңгалимович!

Сезне 70 яшьлек юбилеегызга бәйле гаҗәеп матур дата белән ихлас котлыйм. Озак еллар хезмәттәшлек итү дәверендә миңа Сезне гел яхшы яктан гына белергә насыйп булды. Нинди генә уртак проект эшләсәк тә, Сезнең кулыгыз җиңел булгангадыр, мөгаен, ул эш тиз һәм уңышлы бара.

Инде 35 елга якын Сез Түбән Кама монтаж идарәсенә җитәкчелек итәсез. Сез эш процессын уңайлы һәм нәтиҗәле итеп оештырып кына калмыйсыз, ә һәрбер мәсьәләгә – җитештерүгә кагылышлымы ул, аерым хезмәткәрнең проблемасымы – игътибарлы мөнәсәбәт күрсәтә беләсез. Яныгыздагы кешеләр Сезнең кешелекле булуыгызны һәм дустанә мөнәсәбәтегезне югары бәяли. Шулай булгач, идарәгә эшкә яшь, перспективалы белгечләрнең килүе, ә предприятие партнёрларының елдан-ел арта баруы бер дә гаҗәп түгел.

Сез гади электромонтер өйрәнчеге булудан башлап, Татарстанның иң эре сәнагать объектларында эшләр башкаручы электромонтаж предприятиесе җитәкчесе дәрәҗәсенә кадәр зур профессиональ юл үттегез. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ, «Түбән Кама Нефть эшкәртү заводы» ААҖ, «КамГэсТеплоэнергострой» ҖЧҖ, «Торак-Инвестиция Компаниясе» ҖЧҖ – Татарстанда Түбән Кама монтаж идарәсен күп еллар буена үзенең даими һәм ышанычлы партнёры санаган төп компанияләрнең кайберләре генә.

Сезнең җитәкчелектәге оешма динамик үсештә һәм даими рәвештә алга – яңа максатларга, киң колачлы уңышлы проектларга таба хәрәкәт итә. Мөгаен, бу сыйфатлар Сезнең үзегезгә дә хастыр: энергия, максатчанлык, тормышны сөю, туган шәһәребез һәм республикабыз иминлеге хакына намуслы хезмәт.

Чын профессионал ул, барыннан да бигрәк, хыялллана һәм үз хыялларын тормышка ашыра белә торган зат, диләр. Сез бик күп искиткеч проектларны тормышка ашырдыгыз, һәм юбилеегыз алдыннан мин Сезгә хыялларыгызның киләчәктә дә тормышка аша баруын телим. Бәхет, сәламәтлек, уңышлар юлдаш булсын!

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА
ТАТАРСТАН
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:
тел: (843) 222-06-05

Реклама 16+

ТАТАРСТАН

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә

Индекс **П 2381** – татар телендә: алты айга язылу бәясе **864 сум 24 тиен**
Индекс **П 2378** – рус телендә: алты айга язылу бәясе **864 сум 24 тиен**



Ф.СП-1

Почта России

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал | П 2381 (индекс издания)

Татарстан
(наименование издания) | количество комплектов:

на 2017 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

ПВ | место | литер

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

на ~~газету~~ журнал | П 2381 (индекс издания)

Татарстан
(наименование издания)

Стоимость	подписки	864 руб. 24 коп.	количество комплектов:
	переадресовки	___руб.___коп.	

на 2017 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

Реклама 16+

Шулай ук электрон почта аша да язылырга мөмкин:
milyaushanb@tatmedia.com
Дистрибуция бүлеге хезмәткәрләре, шалтыратып, кызыксындырган сорауларыгызга җавап бирерләр.

Яки түбәндәге телефон буенча тарату бүлеге җитәкчесе Миләүшә Байрашевага үзегез шалтырата аласыз: **тел. +7 (843) 222 09 79**

PRESSA.RU

Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылы халкы арасында бик күп риваятьләр яши. Аларның кайберләре чагыштырмача гына, ә кайберләре ачыктан-ачык һәммәбезгә яхшы мәгълүм әкиятләрне хәтерләтә. Кем белә, бәлки, алар ул әкиятләрнең беренче үрнәкләредер дә?

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: КУРА ҖИЛӘГЕ БАЗЫ

Олы Солтанда күпләр тылсымлы урын дип саный торган йорт бар. Аны бер хатынның тиктормас теле аркасында шундыйга әйләнгән дип сөйлиләр.

Бу хәл бик күптән була. Әлеге йортта бер ир һәм аның көмәнле хатыны яши икән. Бервакыт кышның зәмһәрир суыгында хатынның кура җиләге ашыйсы килгән – бала көткән хатыннар белән дә, «Унике ай» әкиятендә сурәтләнгән үги аналар белән дә була торган хәл бу. «Теләсә каян тап, әмма кура җиләге алып кайт, – ди икән хатын. – Мондый хәлемдә кура җиләксез бер көн дә яши алмаячакмын. Кайнатмасы түгел, куагыннан яңа өзеп алынганы кирәк!»

Аңлыйсыздыр инде: кышның бер ае, авыл җире, XVIII, әллә XVII гасыр – ул чорда шәһәрләрдә дә супермаркетларның ни икәнен белмиләр әле. Хатын, чиктән тыш хәлдән таеп, эченә ябыша, күзләрен акайта – җәйге җиләкне татып карау теләге шулкадәр көчле була инде менә! Сөйләп тә торасы юк: әүвәл заманнан ук ирләр мондый күренешне бик авыр кичерә, сөеклеләренең теләкләрен үтәү өченниләр генә эшләми!

Һәм, уйламаганда-көтмәгәндә, теге ир хатынына әйтә икән: «Беркемгә дә сөйләмәсәң, табып бирәм мин сиңа кура җиләге». Яшь хатын, билгеле, шунда ук бу хакта авыз да ачмаска дип ант итә. Һәм ир аны базга алып төшә – ә анда очсыз-кырыйсыз кура җиләге куаклары үсеп утыра икән. Моны күргәч, хатын, гадәтенчә: «Хәзер бу җиләк кирәк түгел инде, ананас ашыйсым килә!» – дип әйтмәкче булса да, тыелып кала, чөнки бу күренеш аны тәмам гаҗәпкә калдыра. Шуңа күрә, җиләк ашап туйгач, биргән сүзен дә онытып, күршесенә кереп китә һәм баздагы хикмәтләр турында сөйләп бирә. Шул мизгелдә коточкыч хәл була – көтмәгәндә теге ир үлеп китә. Билгеле, бу бер дә гадел булмый: хатынының тиктормас телле булуында ирнең гаебе юк бит!

Тол калгач, теге хатын моннан соң бервакытта да авыз ачып сүз әйтмәскә ант итә. Аның сүзендә тору-тормавы хакында солтанлыларда мәгълүмат юк. Тылсымлы йортның базында кура җиләге үсәме-юкмы икәнен дә белмиләр. Кемнәрдер үсә, ди, тик кереп карарга куркалар. Ә кайберәүләр үсми, ди, алары да барып караудан шикләнә. Белмәссең, карарсың да, онытылып китеп, бүтәннәргә сөйләп ташларсың…

Фото: Александр Эшкинин

АЙ КӘЕФЕ: БАЛЛАР ҺӘМ ТУРНИРЛАР ВАКЫТЫ

Яңа ел якыная барган саен, татарстанлыларның һәм республика кунакларының кәефе көннән-көн әкияттәгечәрәк була бара. Хәер, алар монда әкият артыннан киләләр дә бит инде. Һәм менә кырыс ноябрьне фантазерлар, толкиенистлар һәм рольле уеннарны яратучылар чып-чын бәйрәмгә әйләндерде дә. Россиядән 1000 гә якын кеше «Зиланткон» халыкара фестиваленә Казанга җыелды.



Ел саен әлеге фестиваль үзенең гаҗәеп фантазиягә бай тарихи тамашалары: фехтование турнирлары, урта гасыр сугышлары, шулай ук аждаһалар, принцессалар, рыцарьлар һәм башка әкият геройлары башкаруында чын бал биюләре белән кунакларны һәм катнашучыларны үзенә җәлеп итеп тора. Костюмнар һәм образларның төрлелеге белән таң калдырган, ел саен ноябрь аенда фикердәшләрен Казанга җыя торган бөтенләй башка тормышка тулысынча чуму бит бу.

Александра Лесик, Мәскәү шәһәре:
– Фестиваль үзгәрә, әмма барысы да – яхшы якка, тагын да кызыклырак, җанга якынрак була бара. Казанга без туган гаиләбезгә кайткан кебек киләбез.

Борис Фетисов, «Зиланткон» конвенты җитәкчесе, Казан шәһәре:
– Кризис безне дә читләтеп узмады, быел башка шәһәрләрдән катнашучылар әзрәк. Әмма фестивальдә казанлылар саны артканнан арта бара. Без барыбыз да бер рухи берләшмә, бер мәгънәви төркем кешеләре, безгә бер мавыгу хас.

www.protatarstan.ru
Реклама 16+
ТАТАРСТАН
Сәяхәт итәргә яратучы фестиваль
сайттагы яңалык
яңалыклар
WWW.PROTATRSTAN.RU